А. С. ПЧЁЛКО һәм Г. Б. ПОЛЯК

АРИФМЕТИКА

4нче КЛАСС ӨЧЕН

ТАТКНИГОИЗДАТ · 1956

А. С. ПЧЁЛКО һәм Г. Б. ПОЛЯК

АРИФМЕТИКА

БАШЛАНГЫЧ МӘКТӘПНЕН 4 нче КЛАССЫ ӨЧЕН ДӘРЕСЛЕК

РСФСР Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган

Тәрҗемәсен Татарстан Мәгариф министрлыгы раслады

ТАТАРЧА БЕРЕНЧЕ БАСМА

ТАТКНИГОИЗДАТ
УКЫТУ-ПЕДАГОГИК ӘДӘБИЯТ РЕДАКЦИЯСЕ
КАЗАН 1956

III класста узганнарны кабатлау.

1. Саннарны укып чыгарга.

1) Безнең илебез көнбатыштан көнчыгышка 11 000 *км* га һәм төньяктан көньякка 4 500 *км* га сузылган. Безнең Ватанымызның чикләре озынлыгы — 60 000 *км*.

2) Атаклы рус сәяхәтчесе Н. М. Пржевальский Азиядә җәяү һәм атка атланып 32 000 *км* юл узган.

3) Океанның иң тирән урыны — 10 863 *м*.

2. Түбәндәге саннарны цифралар белән язарга.

1) 1954 елга безнең илебездә балалар өчен бер мең тугыз йөз унике дворец һәм пионерлар йорты төзелде.

2) Москвадагы Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсен көненә йөз меңнән артык кеше карый.

3) Рекордчы сыер елга унөч мең биш йөз җитмеш ике литр сөт бирде.

3. Саннарны укып чыгарга: 58 000; 72 800; 17 950; 90 276; 40 873; 20 097, 30 084; 900 005; 500 000; 114 892; 40 500; 608 602; 700 090; 820 004.

4. $1\,268 + 5\,476$ $\quad 42\,786 + 2\,085$ $\quad 698 + 4\,728 + 14\,008$
$9\,076 + 734$ $\quad 63\,070 + 12\,090$ $\quad 954 + 1\,096 + 97\,237$

5 $4\,096 + 975 + 608\,789 + 46\,875$ $\quad 5\,718 + 906 + 18\,068$
$78\,635 + 496 + 20\,976 + 8\,976$ $\quad 2\,806 + 94\,596 + 705$

6. Бер атна эчендә Москвага 856 *т* слива, сливага караганда 408 *т* га артыграк груша, ә грушага караганда 950 *т* га артыграк алма китерелгән. Бер атнада Москвага барлыгы ничә тонна фрукт китерелгән?

7. Москвадан Свердловскига кадәр тимер юл белән 1 822 *км*, Свердловскидан Новосибирскига кадәр 1 359 *км*, Новосибирскидан Иркутскига кадәр 1 851 *км* һәм Иркутскидан Владивостокка кадәрге ераклык Свердловскидан Иркутскига кадәрге арадан 931 *км* га артыграк. Москвадан Владивостокка кадәр ничә километр? (1 нче рәсем.)

1 нче рәсем.

8. Элеваторга беренче көнне 8 900 *ц*, икенче көнне, беренче көнгә караганда, 1 780 *ц* га артыграк, ә өченче көнне, беренче һәм икенче көндәгенең икесенә караганда, 932 *ц* га артыграк бодай китерделәр. Өч көндә элеваторга барлыгы ничә центнер бодай китергәннәр?

9. (Телдән.) Бер районда 117 трактор бар иде, хәзер инде анда 155 трактор булды. Бу районда тракторлар саны күпмегә арткан?

10. (Телдән.) Пионерларның өч отряды җәй көне 64 *кг* дару үләннәре җыйган. Беренче отряд 24 *кг*, икенче отряд аннан 8 *кг* га кимрәк җыйган. Өченче отряд ничә килограмм дару үләннәре җыйган?

11. (Телдән.) Түбәндәге саннарның һәрберсен 25 кә киметергә:

70; 95; 115; 160; 200.

12. 2 842 — 1 756 7 068 — 3 498 45 008 — 14 829
3 453 — 2 187 3 004 — 1 825 24 105 — 18 096

13. 275 026 + 308 724 — 49 678 100 000 — 90 728
800 000 — (50 345 + 168 724) 10 100 — (2 724 + 376)

14. Түбәндәге бирелмәләр буенча бер елда колхозда савым сыерлар саны һәм сөт савымы күпмегә артуын белергә:

Еллар	Сыерлар саны	Савылган сөт (литрлар белән)
1953	356	676 400
1954	412	993 920

15. А. П. Чеховның Ялтадагы музеена килүчеләр саны елдан-ел арта. Мәсәлән, 1925 елда Чехов музеенда 2 726 кеше, 1935 елда 22 500 кеше, ә 1954 елда 87 036 кеше булган. 1954 елда музейга килүчеләр саны, 1925 ел белән чагыштырганда, күпмегә арткан? 1935 ел белән чагыштырганда?

16. (Телдән.) Бәрәнге утырту машинасы 38 кешенең кул хезмәтен алмаштыра. Совхозда шундый 5 машина эшли. Алар ничә эшчене алмаштыралар?

17. (Телдән.) Кәгазь, картон һәм тукыма ябыштыру өчен клей хәзерләгәндә, балалар 10 г столярлык клее алдылар һәм аңа бу клейга караганда 6 тапкыр артыграк он һәм 24 тапкыр артыграк су өстәделәр. Балалар ничә грамм клей хәзерләгәннәр?

18. (Телдән.) Түбәндәге саннарның һәрберсен 7 тапкыр зурайтырга:

12; 70; 85; 100; 130; 500.

19.	5 489 × 6	7 008 × 5	786 × 10	364 × 26
	6 704 × 8	3 960 × 7	359 × 90	850 × 47

20.	6 195 × 7	6 235 × 18	638 × 10	6 008 × 70
	5 703 × 4	7 054 × 60	308 × 78	4 062 × 95
	8 005 × 9	8 600 × 54	900 × 86	7 050 × 48

21. Тегермәнгә һәрберсе 60 *кг* авырлыкта 68 капчык арыш һәм һәрберсе 70 *кг* авырлыкта 75 капчык бодай китерделәр. Беренче көнне 5 400 *кг* ашлыкны тарттылар. Икенче көнгә ничә килограмм ашлык тартасы калган?

22. Фабрика комитеты һәрберсе 850 сум тора торган 45 данә санаторий путёвкалары һәм һәрберсе 480 сумлык 25 данә ял йорты путёвкалары алды. Путёвкалар өчен барысы күпме акча тотылган?

23. (Телдән.) Түбәндәге саннарның һәрберсен 6 тапкыр; 10 тапкыр; 100 тапкыр зурайтырга:

15; 60; 75; 90; 160; 500; 2 000.

24.	568 × 400	736 × 258	724 × 403	700 × 532
	697 × 580	308 × 715	306 × 504	815 × 104

25.	7 856 × 96	458 × 400	(1 986 — 1 214) × 485
	3 080 × 68	906 × 608	(5 000 — 4 028) × 368
	9 600 × 74	704 × 584	(7 010 — 6 156) × 904

26. Саклык кассасы 25 000 әр сумлык 2 отыш, 5 000 сумлык 13 отыш, 1 000 әр сумлык 205 отыш түләгән. Бу отышларны түләү өчен күпме акча бирелгән?

27. 200 колхозчы мамык җыялар. Эш көне бетүгә 85 кешенең 90 шар килограмм, 76 кешенең 80 шәр килограмм һәм

калганнарының һәрберсе 65 әр килограмм мамык җыюлары беленә. Барлык колхозчылар көнгә күпме мамык җыйганнар?

28. (Телдән.) 1) Лачын 170 ел яши, ә миләш чыпчыгының (дрозд) гомере, лачынга караганда, 17 тапкыр кыскарак. Миләш чыпчыгы ничә ел яши?

2) 8 әйләнеш ясаганда винт 72 *мм* га батты. 12 әйләнеш ясаганда ул ничә миллиметрга батар?

29. (Телдән.) Түбәндәге саннарның һәрберсен 6 га бүләргә

72; 96; 120; 180; 360; 720; 900.

30.	5 748 : 4	14 760 : 9	2 750 : 10	3 640 : 20
	5 874 : 6	67 900 : 7	7 500 : 10	7 680 : 40

31.	6 136 : 4	27 360 : 8	2 816 : 2	34 600 : 10
	1 950 : 6	43 500 : 5	9 156 : 3	14 220 : 60
	3 759 : 7	27 000 : 3	4 828 : 4	36 800 : 80

32. Көн саен 3 киносеанс бирә торган кинотеатрда 6 көн эчендә фильмнарны 3 600 кеше караган. Һәр сеанста да урыннар тулы булган булсалар, бу кинотеатр ничә урынга исәпләнгән?

33. Поезд 10 сәгатьтә 400 *км*, ә самолёт 8 сәгатьтә 2 560 *км* узган. Самолётның сәгатьлек тизлеге поездныкыннан ничә тапкыр артык?

34. (Телдән.) 1 *кг* мамыкны эшкәрткәндә 8 *м* бәз, яки 20 *м* батист, яки 50 данә кулъяулыгы, яки 125 кәтүк җеп хәзерләп була. 1 *м* бәзгә ничә грамм мамык китә? 1 *м* батистка? 1 кулъяулыгына? 1 кәтүк җепкә?

35. (Телдән.) Музыка мәктәбендә 180 бала укый. Алардан яртысы рояльдә, өчтән бер өлеше скрипкада, алтыдан бер өлеше баянда уйнарга өйрәнәләр. Һәр инструментта уйнарга ничәшәр бала өйрәнә?

36. (Телдән.) Табарга:

1) 84 нең, 96 ның, 210 ның, 360 ның, 960 ның өчтән бер өлешен;

2) 60 ның, 72 нең, 108 нең, 240 ның, 320 нең, 440 ның дүрттән бер өлешен.

37.	5 875 : 25	1 512 : 24	5 474 : 238	11 752 : 226
	8 988 : 28	2 392 : 46	9 672 : 312	26 368 : 412

38.	2 772 : 21	2 240 : 35	5 712 : 136	16 380 : 468
	4 392 : 36	2 576 : 46	8 944 : 208	23 976 : 648

39. Автомобильләр паркында йөк машиналары бер көнгә 6 750 *л*, ә җиңел машиналар аннан 9 тапкыр кимрәк бензин бетергәннәр. Йөк машинасы көнгә 75 *л*, ә җиңел машина 30 *л* бензин бетергән. Теге һәм бу төр машиналар ничәшәр булган?

40. 8 сәгатьтә ике станок белән 144 000 данә торф-черемә чүлмәкләр хәзерләп була. Бер станокта 1 сәгатьтә ничә чүлмәк хәзерләп була?

41. Мисалларны, гамәлләр эшләүнең кабул ителгән тәртибен күзәтеп, чишәргә:

1)	$360+140-250$	$120\times5:4$	$320:10\times20$
	$600-180+580$	$480:6\times9$	$200-54+48$
2)	$230+90\times3$	$360-180:2$	$720:8\times5+150$
	$180+60\times7$	$540-320:4$	$640:8\times4+180$
	$650+70\times5$	$800-360:3$	$600:5\times3-200$

42. 1)

$125\times3+15\times5$	$720:90+450:90$
$72\times5-12\times5$	$240:30+350:70$
$48\times5-30\times4$	$350:50-420:60$

2)

$(150-25)\times3$	$18\times(36+64)$	$(500-340)\times5$
$(360+120):4$	$87:(100-71)$	$75\times(1\,000-900)$

3)

$27\,540:255+21\,060:135$	$(30\,000-2\,160):174+5\,608$
$(4\,590:18+7\,017):24$	$(10\,800+5\,604)\times30-29\,624$

43. Түбәндәге мәсьәләләрнең һәрберсен чишү өчен саннар өстендә нинди гамәлләр эшләргә кирәген юллап язарга; исәпләүләрне телдән эшләргә.

1) Укучы һәрберсе 14 әр тиеннән 5 дәфтәр һәм 28 тиенгә бер карандаш сатып алган. Сатып алынган әйберләр барысы бергә күпме тора?

2) Бәрәңге алганда 6 малай һәрберсе 14 әр корзинка, ә 5 малай 16 шар корзинка бәрәңге җыйганнар. Барлык балалар ничә корзинка бәрәңге җыйганнар?

3) Поезд 3 сәгатьтә 180 *км* юл узган. Шул ук тизлек белән барса, поезд 5 сәгатьтә ничә километр юл узар?

4) 4 карта өчен 96 сум, ә 3 глобус өчен 45 сум түләгәннәр. Карта глобустан күпмегә кыйбатрак?

44. Поезд 12 сәгатьтә 504 *км* узган. Соңыннан ул тизлеген сәгатькә 4 *км* га арттырган һәм калган араны 6 сәгатьтә узган. Поезд барысы ничә километр юл узган?

45. Беренче 8 көндә мастерской библиотека өчен 688 китап төпләде, ә соңыннан көнгә 12 китап артыграк төпли башлады һәм калган эшне 6 көндә эшләп бетерде. Мастерской барысы ничә китап төпләгән?

46. Дәфтәрләргә язарга:

1) озынлык үлчәүлекләре таблицасын;

2) авырлык үлчәүлекләре таблицасын.

47. 1) Эре үлчәүлекләрне ваграк үлчәүлекләр белән аңлатырга:

2 *км* = 2 000 *м*	3 *м* = 300 *см*	4 *т* = 4 000 *кг*	2 *ц* = 200 *кг*
6 *км* =	7 *м* =	5 *т* =	7 *ц* =
8 *км* =	9 *м* =	8 *т* =	5 *ц* =

2) Вак үлчәүлекләрне эрерәк үлчәүлекләр белән аңлатырга

80 *мм* = 8 *см*	90 *дм* = 9 *м*	5 000 *г* = 5 *кг*	300 *кг* = 3 ц
60 *мм* =	70 *дм* =	8 000 *г* =	700 *кг* =
40 *мм* =	50 *дм* =	4 000 *г* =	900 *кг* =

48. Күз белән чамалап класс бүлмәсенең, мәктәп коридорының, мәктәп бинасының буен, иңен һәм биеклеген билгеләргә. Үзеңнең күзүлчәм билгеләүләреңнең дөреслеген үлчәү юлы белән тикшерергә.

49. Күз белән чамалап түбәндәге кисемтәләрнең озынлыгын билгеләргә (2 нче рәсем). Үлчәү юлы белән дөреслеген тикшерергә.

2 нче рәсем.

50. Күз белән чамалап 15 *см*, 10 *см*, 5 *мм* озынлыгындагы кисемтәләр сызарга. Үлчәү юлы белән дөреслеген тикшерергә.

51. (Телдән.) Мәче башлы ябалак җәй буена мең тычканны бетерә. Бу вакыт эчендә бер тычкан 1 *кг* бөртекне бетерә. Җәй буена ябалак күпме бөртекне саклый?

52. Ике йөк машинасында 8 *т* бәрәңге китерделәр. Әгәр бер ат белән 500 *кг* авырлыктагы йөкне китерергә мөмкин булса, бу йөкне китерү өчен ничә ат кирәк булыр иде?

53. 1) Метрлар белән аңлатырга: 10 *км*; 12 *км*; 18 *км*; 25 *км*.

2) Килограммнар белән аңлатырга: 6 *т*, 10 *т*, 14 *т*, 7 *ц*, 15 *ц*, 20 *ц*.

54. Туры почмак; турыдан зуррак почмак; турыдан кечерәк почмак төзергә.

55. Ягы 6 *см* лы квадрат сызарга.

56. (Телдән.) 1) Квадратның бер ягы 12 *см* озынлыкта. Аның барлык якларының озынлыгы ничә сантиметр?

2) Квадратның барлык яклары суммасы 36 *см*. Аның ягы нинди озынлыкта?

57. Буе 7 *см*, иңе 4 *см* лы турыпочмаклык сызарга. Аның яклары суммасын исәпләргә.

58. Рулетка яки кыр циркуленнән файдаланып, мәктәп участогының буен һәм иңен үлчәргә.

59. Җир өстендә 15 *м*, 25 *м*, 100 *м* озынлыгындагы туры сызыклар уздырырга.

60. 1) Җир өстендә, ягын 10 *м* итеп алып, квадрат формасындагы участок билгеләргә. Бу — ар.

2) Җир өстендә, ягын 100 *м* итеп алып, квадрат формасындагы участок билгеләргә. Бу — гектар.

Ар һәм гектар турыпочмаклык формасында да була алалар.

61. 1) Колхозда 1 гектар җиргә яңа сорт бодай чәчкәннәр. Барысы 150 *кг* бодай чәчеп, чәчкәнгә караганда 18 тапкыр артыграк уңыш җыеп алганнар. Гектардан күпме бодай җыеп алганнар?

2) Турыпочмаклык формасындагы яшелчә бакчасын киртә белән әйләндереп алырга кирәк. Бакчаның буе 50 *м*, иңе аннан 12 *м* га кимрәк. Киртә нинди озынлыкта булыр?

3) Турыпочмаклык формасындагы бакча койма белән әйләндерелеп алынган. Бакчаның иңе 45 *м*, буе 15 *м* га озынрак. Койманың озынлыгын исәпләргә.

62.

$1\,664 : 32 + 1\,640 : 82$ $\qquad$ $28\,196 : 266 + 21\,060 : 156$

$804 \times 75 - 406 \times 54$ $\qquad$ $4\,758 \times 64 - 34\,398 : 54$

$467 \times 785 - 395 \times 648$ $\qquad$ $802 \times 403 - 81\,612 : 12$

63. $(242\,530 + 18\,350) : 60$ $(9\,180 : 36 + 7\,401) : 24$
$(23\,285 - 12\,279) \times 38$ $(30\,000 - 2\,160) : 174 + 5\,608$
$749 \times 88 - 71\,592 : 76$ $(5\,088 + 2\,010) : (1\,020 - 978)$

64. Самолёт 3 сәгать эчендә 894 *км* очкан. Әгәр тизлеге сәгатькә 20 *км* га артса, семолёт 5 сәгатьтә ничә километр очар?

65. Пароход 9 сәгать эчендә агым уңаена 216 *км* юл үтте. Әгәр пароходның агымга каршы тизлеге сәгатькә 6 *км* га кимрәк булса, ул бу араны кире кайту өчен күпме вакыт уздырыр?

66. Кышкы каникулларның 5 көнендә Пионерлар дворецындагы яңа ел ёлкасында барысы 1 250 бала булды. Әгәр ёлкага килүчеләрнең көндәлек саны уртача шундый ук булса, 12 көнлек каникуллар вакытында ёлкада барысы ничә бала булган?

67. (Телдән.) Бер агачтан 4 корзинка, икенче агачтан шундый 6 корзинка, ә барысы бергә 150 *кг* алма җыеп алганнар. Һәр агачтан ничә килограмм алма җыеп алганнар?

68. Ике мастер балалар костюмы теккән өчен бергә 765 сум акча алганнар. Беренче мастер 5 костюм, икенчесе шундый 4 костюм теккән. Һәр мастер ничә сум акча алган?

69. Самолёт 3 көндә 7 700 *км* очкан. Беренче көнне ул 9 сәгать, икенче көнне 8 сәгать, өченче көнне 11 сәгать һавада булган. Әгәр тизлеге бер үк булса, самолёт һәр көнне нинди араны очкан?

70. (Телдән.) Ике кисәк тукымадан бер үк үлчәмдәге костюмнар теккәннәр. Бер кисәктә 36 *м*, ә икенчесендә 27 *м* тукыма булган. Беренче кисәктән, икенчегә караганда, 3 костюм артыграк теккәннәр. Һәр кисәктән ничәшәр костюм теккәннәр?

71. Колхозга бәрәңге җыюда булышу өчен пионерлар ике бригадага бүленгәннәр. Беренче бригада 36 капчык, икенче бригада шундый ук 40 капчык бәрәңге җыйган. Икенче бригада, беренчегә караганда, 208 *кг* артыграк җыйган. Ике бригада бергә ничә килограмм бәрәңге җыйган?

72. Машина-трактор станциясе өчен, бер үк зурлыктагы мичкәләргә салып, бер машинада 2 100 *л*, икенче машинада 1 500 *л* ягулык китерделәр. Икенче машинада, беренчегә караганда, 6 мичкә кимрәк булган. Һәр машинада ничә мичкә ягулык булган?

73. Бер үк вакытта Москвадан һәм Ленинградтан бер-беренә каршы ике поезд чыга. Москва поезды сәгатькә 68 *км*, Ленинград поезды 62 *км* бара. 5 сәгатьтән соң поездлар очрашалар. Москвадан Ленинградка кадәрге араның ераклыгын (3 нче рәсем) исәпләргә. (Ике гамәл белән чишәргә.)



3 нче рәсем.

74. Бер үк вакытта ике шәһәрдән бер-беренә каршы ике автомобиль чыга. Берсе сәгатькә 42 *км*, икенчесе 46 *км* бара. Автомобильләр 7 сәгатьтән соң очрашалар. Бу ике шәһәр арасындагы ераклыкны табарга. (Ике гамәл белән чишәргә.)

75. Аралары 570 *км* булган ике шәһәрдән бер үк вакытта бер-беренә каршы ике автомобиль чыга. Беренчесе сәгатькә 45 *км*, икенчесе 50 *км* бара. Автомобильләр ничә сәгатьтән соң очрашырлар?

76. Аралары 168 *км* булган ике пристаньнан бер үк вакытта бер-беренә каршы ике пароход чыга. Берсе сәгатькә 24 *км*, икенчесе сәгатькә 18 *км* тизлек белән бара. Пароходлар ничә сәгатьтән соң очрашырлар?

77. Аралары 116 *км* булган ике пункттан бер үк вакытта бер-беренә каршы ике велосипедист чыккан. 4 сәгатьтән соң алар очрашканнар. Аларның берсе сәгатькә 15 *км* барган. Икенче велосипедист сәгатькә ничә километр барган? (Ике гамәл белән чишәргә.)

78. Ике бригада 1 800 *м* озынлыгындагы юлга асфальт җәйде. Алар эшне ике очтан башладылар һәм бер-беренә каршы эшләп килделәр. 12 көн эшләгәч, бригадалар очраштылар. Беренче бригада көнгә 80 *м* юлга асфальт җәйде. Икенче бригада көнгә ничә метр юлга асфальт җәйгән? (Ике гамәл белән чишәргә.)

79. Әгәр бәрәңгене 35 әр центнердан 6 машинага төясән, 70 *ц* бәрәңге кала. Әгәр һәр машинага 40 ар центнер төясән, барлык бәрәңгене берьюлы илтү өчен ничә машина кирәк булыр?

80. Китапханәдә олы яшьтәге балалар өчен 576, урта яшьтәге балалар өчен аннан 98 гә кимрәк, ә кече яшьтәге бала-

лар өчен, олы һәм урта яшьтәге балалар китапларына карағанда, ике тапкыр кимрәк китап булган. Җәй көне олы яшьтәге балалар өчен тагы 118 китап, урта һәм кече яшьтәге балалар өчен өч тапкыр артыграк китап алдылар. Хәзер китапханәдә ничә китап бар?

81. Укучы, көн саен 20 шәр бит укып, китапның бер өлешен 6 көндә укыды. Шуннан соң аңа тагы китапның ике бүлеген укыйсы калды: бер бүлеге моңарчы укыганның яртысы, ә икенче бүлеге өчтән бере кадәр. Әгәр көнгә 25 әр бит укылса, китапның калган өлешен ничә көндә укып бетереп булыр?

82. 1) $887\,904 + 20\,796 - 900\,789 + 103\,089$
$200\,100 - 30\,724 + 906\,318 - 452\,987$

2) $3\,080 \times 79 + 327\,008 - 90\,827$
$4\,008 \times 96 - 16\,826 + 19\,798$

3) $31\,098 : 73 \times 508 - 215\,408$ $306 \times 75 : 25 - 918$
$34\,020 : 36 \times 640 + 295\,200$ $840 \times 36 : 48 + 630$

Күбурынлы саннар өстендә нумерация һәм дүрт гамәл.

Күбурынлы саннар нумерациясе.

Әйберләрнең ничә икәнен белергә кирәк булса, аларны санныйлар. Санаганда саннар килеп чыга: бер, ике, өч, дүрт һ. а. ш., ул саннар **бөтен саннар** дип аталалар.

Иң кечкенә бөтен сан — берәмлек. Аннан соң килә торган бөтен саннар алдагысына берәр берәмлекне өстәү юлы белән ясалалар. Берәр берәмлек өстәүне чиксез эшләп була, шуңа күрә иң зур бөтен сан юк.

Әйберләрне берәмләп кенә түгел, бәлки дистәләп, йөзләп, меңләп, дистә меңләп, йөз меңләп һ. а. ш. санап була.

Простой берәмлекләрне 1 нче разряд берәмлекләре дип атыйлар.

Дистәләрне 2 нче разряд берәмлекләре дип атыйлар.

Йөзләрне 3 нче разряд берәмлекләре дип атыйлар.

Меңнәрне 4 нче разряд берәмлекләре дип атыйлар.

Дистә меңнәрне 5 нче разряд берәмлекләре дип атыйлар.

Йөз меңнәрне 6 нчы разряд берәмлекләре дип атыйлар.

Теләсә нинди разрядның ун берәмлеге киләчәк югары разрядның бер берәмлеген төзи.

Һәр класста өч разряд. Берәмлекләр, дистәләр һәм йөзләр берәмлекләр классын яки беренче классны төзиләр. Меңнәр, дистә меңнәр һәм йөз меңнәр меңнәр классын яки икенче классны төзиләр.

Саннар аерым билгеләр — **цифралар** белән тамгаланалар.

Цифралар барысы ун: 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7, 8, 9, 0.

Нуль цифрасы нинди дә булса разрядның берәмлекләре юк икәнне күрсәтә.

83. Счётка сала барып, берәмлекләр белән 10 га кадәр, дистәләр белән 100 гә кадәр, йөзләр белән 1 000 гә кадәр, меңнәр белән 10 000 гә кадәр, дистә меңнәр белән 100 000 гә кадәр, йөз меңнәр белән 1 000 000 га кадәр санагыз.

84. Түбәндәге таблицаны тикшереп карап чыгыгыз.

Икенче класс — меңнәр классы			Беренче класс — берәмлекләр классы		
йөзләр	дистәләр	берәмлекләр	йөзләр	дистәләр	берәмлекләр
3	2	6	7	0	6

Таблицада язылган санны укып чыгыгыз.

Берәмлектән башлап йөз меңнәргә кадәрге разрядларны тәртибе белән әйтеп чыгыгыз.

Беренче классның барлык разряд берәмлекләрен әйтеп чыгыгыз; икенче классның разрядларын әйтегез.

Берәмлекләр уң кулдан ничәнче урында язылалар? дистәләр? йөзләр? меңнәр? дистә меңнәр? йөз меңнәр?

85. Счётта: ун миллионга тулганчы берәр миллионлап; йөз миллионга тулганчы дистә миллионлап; мең миллионга тулганчы йөзәр миллионлап өсти барыгыз.

10 йөз мең 1 миллионны төзи.
10 миллион 1 дистә миллионны төзи.
10 дистә миллион 1 йөз миллионны төзи.

86. Түбәндәге таблицаны тикшереп карап чыгыгыз.

Өченче класс — миллионнар классы			Икенче класс — меңнәр классы			Беренче класс — берәмлекләр классы		
йөзләр	дистәләр	берәмлекләр	йөзләр	дистәләр	берәмлекләр	йөзләр	дистәләр	берәмлекләр
		5	3	6	4	8	2	4
	6	3	5	0	6	4	0	5
2	4	6	0	3	5	0	3	5

Түбәндәге сорауларга җавап бирегез:

Өченче класс нинди разрядларны үз эченә ала? Миллионнарның берәмлекләре уңнан ничәнче урында тора? миллионнарның дистәләре? миллионнарның йөзләре?

Уннан жиденче урында торган цифра нәрсәне аңлата? сигезенче урында торган цифра? тугызынчы урында торган цифра?

Жиденче разрядның 5 берәмлеге нинди санны төзи? сигезенче разрядның 3 берәмлеге? тугызынчы разрядның 6 берәмлеге?

Таблицаның юлларында язылган саннарны укыгыз һәм аларны счётка салыгыз.

87. Дәфтәрләрегезгә класслар һәм разрядлар таблицасын сызыгыз. Карточкаларга берәр цифра языгыз. Төрле саннар килеп чыгарлык итеп, карточкаларны таблицага урнаштырыгыз.

88 Текстларны укып чыгыгыз һәм аларда бирелгән саннарны счётларга салыгыз:

1) Революциягә кадәрге Россиядә Пушкин әсәрләре 30 ел эчендә 10 711 000 экземпляр, ә Советлар Союзында 35 ел эчендә 62 738 000 экземпляр басылган.

2) Соңгы 20 ел эчендә безнең илебездә балалар өчен 20 600 исемдә 911 000 000 экземпляр китап басылды.

89. Түбәндәге саннарны цифралар белән язарга:

1) Җирдән Кояшка кадәрге ераклык йөз кырык тугыз миллион биш йөз мең километр, ә Җирдән Айга кадәрге ераклык өч йөз сиксән дүрт мең километр.

2) 1954 елда Кытайда алты йөз бер миллион тугыз йөз мең кеше булган.

90. Түбәндәге саннарны укып чыгарга һәм счётта салырга:

1) 1 000 000; 8 000 000; 32 000 000; 564 000 000; 40 000 000; 500 000 000; 604 000 000;

2) 325 800 000; 486 720 000; 513 482 000; 8 126 738; 644 317 982; 999 845 736; 725 308 701;

3) 5 026 340; 4 078 056; 20 105 068; 100 060 030; 3 006 003; 700 700 700; 90 090 090; 101 001 001;

4) 426 000 318; 360 000 650; 800 000 700; 90 723 000.

91. Түбәндәге саннарны цифралар белән язарга:

1) өч йөз егерме биш миллион; алты йөз өч миллион; биш йөз миллион;

2) дүрт йөз сиксән ике миллион җиде йөз мең; ике миллион алты йөз унике мең; кырык өч миллион сигез йөз тугыз мең;

3) өч йөз кырык бер миллион дүрт йөз туксан мең биш йөз уналты; егерме сигез миллион биш йөз җиде мең сиксән әч; бер миллион кырык мең илле; алтмыш миллион алтмыш мең туксан; дүрт миллион дүрт мең дүрт;

4) җиде йөз утыз дүрт миллион биш йөз егерме алты; утыз миллион кырык; унҗиде миллион егерме.

92. 1) 999 997 саны артыннан килә торган биш санны язарга.

2) 1 000 004 саныннан берәмлекләп 6 тапкыр киметергә һәм килеп чыккан саннарны язарга.

93. 54 млн. + 18 млн.	90 млн. — 36 млн.	12 млн. × 7
19 млн. + 81 млн.	68 млн. — 25 млн.	80 млн. × 9
70 млн. + 60 млн.	72 млн. — 18 млн.	60 млн. × 8

Миллионнар 7 нче разряд берәмлекләре дип аталалар.

Дистә миллионнар 8 нче разряд берәмлекләре дип аталалар.

Йөз миллионнар 9 нчы разряд берәмлекләре дип аталалар.

Берәмлек, дистә һәм йөз миллионнар миллионнар классын яки өченче классны төзиләр.

Миллионнар уң кулдан җиденче урында, дистә миллионнар сигезенче урында, йөз миллионнар тугызынчы урында язылалар.

94. Дистә миллиардка тулганчы берәр миллиардлап; йөз миллиардка тулганчы дистә миллиардлап; мең миллиардка тулганчы йөзәр миллиардлап өсти барыгыз.

10 йөз миллион 1 миллиардны төзи.

10 миллиард 1 дистә миллиардны төзи.

10 дистә миллиард 1 йөз миллиардны төзи.

95. Түбәндәге таблицаны тикшереп карап чыгыгыз.

Дүртенче класс — миллиардлар классы			Өченче класс — миллионнар классы			Икенче класс — меңнәр классы			Беренче класс — берәмлекләр классы		
йөзләр	дистәләр	берәмлекләр	йөзләр	дистәләр	берәмлекләр	йөзләр	дистәләр	берәмлекләр	йөзләр	дистәләр	берәмлекләр
1	2 4	4 6 9	3 5 0	5 0 7	8 2 5	7 3 5	2 4 0	6 0 0	3 0 0	6 2 0	9 8 4

Түбәндәге сорауларга җавап бирегез:

Дүртенче класс нинди разрядларны үз эченә ала?

Миллиардлар уң кулдан ничәнче урында торалар?

Счётта миллиардларны кайсы чыбыкта салырга кирәк? дистә миллиардларны? йөз миллиардларны?

Таблицада язылган саннарны укып чыгыгыз.

96. 1) Уңнан унынчы урында торган цифра нәрсәне аңлата? унберенче урында торган цифра? уникенче урындагы цифра?

2) Унынчы разрядның 5 берәмлеге нинди санны аңлата? унберенче разрядның 8 берәмлеге? уникенче разрядның 3 берәмлеге? дүртенче классның 28 берәмлеге? дүртенче классның 145 берәмлеге?

3) Берәмлектән башлап йөз миллиардка кадәрге барлык разрядларны тәртибе белән әйтеп чыгыгыз.

97. Дәфтәрләрегездә класслар һәм разрядлар таблицасын сызыгыз һәм аның өстендә цифралар язылган карточкаларны шулай урнаштырыгыз, анда: 125 миллиард; 300 миллиард; 48 миллиард; 732 миллиард 368 миллион 514 берәмлекне күрсәткән саннар килеп чыксын.

98. Түбәндәге саннарны укыгыз:

1) 1954 елда бөтен җир шарында 2 500 000 000 кеше булган.

2) 1960 елга безнең илебез елына 10 000 000 000 пот бөртекле ашлык алырга тиеш.

99. Саннарны цифралар белән языгыз:

1) Бәяләр төшерү нәтиҗәсендә безнең илебез халкы 1954 елда егерме миллиард сум табыш алды.

2) СССРда урманнар бер миллиард йөз миллион гектар мәйдан алып торалар.

100. Түбәндәге саннарны укып чыгарга:

1) 1 000 000 000; 9 000 000 000; 36 000 000 000; 548 000 000 000; 704 000 000; 40 000 000; 600 000 000 000;

2) 2 728 324 115; 84 625 328 965; 784 318 495 186; 6 804 300 730; 208 600 430; 12 500 680 706; 111 111 222 333;

3) 400 700 800 300; 56 080 070 140; 60 003 005 006; 500 070 004; 1 001 010 001; 604 500 050.

101. Саннарны укып чыгарга һәм аларның һәрберсендә разрядларны һәм классларны әйтергә. Кайсы разряд һәм класслар юк?

23 000 612 384; 5 475 000 720; 635 000 000 319;
8 000 000 060; 1 000 120 000; 45 000 685 000.

102. Түбәндәге саннарны цифралар белән язарга:

1) өч йөз алтмыш сигез миллиард; дүрт йөз миллиард; кырык сигез миллиард алты йөз миллион; ике миллиард биш йөз сигез миллион; бер миллиард ике йөз алтмыш сигез миллион өч йөз егерме биш мең; ике миллиард биш йөз егерме миллион җиде йөз мең;

2) кырык өч миллиард сигез йөз миллион дүрт йөз биш мең йөз кырык сигез; йөз сигез миллиард тугыз йөз дүрт миллион җиде йөз кырык мең ике йөз егерме; илле миллиард илле миллион сиксән мең бер йөз;

3) ике йөз өч миллиард сигез йөз мең ике йөз унбиш; йөз миллиард сигез йөз ике миллион җиде йөз егерме; бер миллиард биш йөз туксан өч; егерме ике миллиард сиксән.

103. Җиденче разрядның 5 берәмлегеннән торган санны; тугызынчы разрядның 8 берәмлегеннән торган санны; униkенче разрядның 6 берәмлегеннән торган санны; икенче классның 256 берәмлегеннән торган санны; дүртенче классның 300 берәмлегеннән торган санны; өченче классның 708 берәмлегеннән торган санны әйтергә һәм язарга.

104. 1) 999 999 997 саны артыннан килә торган 5 сан язарга.

2) 8 000 000 002 саныннан 4 тапкыр берәр берәмлекне киметергә һәм килеп чыккан саннарны язарга.

3) Түбәндәге саннарның һәрберсеннән 6 га зуррак булган саннарны әйтергә:

20 998; 100 999; 999 996; 610 994.

105. Дүртурынлы иң зур санны; дүртурынлы иң кечкенә санны; җидеурынлы иң кечкенә санны; тугызурынлы иң зур санны әйтергә һәм язарга.

106. Саннарны укып чыгарга һәм алардагы разряд һәм классларны әйтергә:

20 006; 100 100 100; 80 080 080; 1 000 635 000;
45 007 050 300; 536 000 000 004.

Миллиардлар 10 нчы разряд берәмлекләре дип аталалар.

Дистә миллиардлар 11 нче разряд берәмлекләре дип аталалар.

Йөз миллиардлар 12 нче разряд берәмлекләре дип аталалар.

Берәмлек, дистә һәм йөз миллиардлар миллиардлар классын яки дүртенче классны төзиләр.

Миллиардлар уң яктан унынчы урында, дистә миллиардлар унберенче урында, йөз миллиардлар уникенче урында язылалар.

Түбәндәге саннарда барысы ничә берәмлек:

107.	68 дистә = 680	125 йөз =	12 мең =
	364 дистә =	718 йөз =	536 мең =
	586 дистә =	864 йөз =	871 мең =

108.	45 дистә мең =	14 млн. =	24 млрд. =
	86 дистә мең =	8 дистә млн. =	39 дистә млрд. =
	238 дистә мең =	6 йөз млн. =	7 йөз млрд. =

109. Түбәндәге саннарның һәрберсендә барысы ничә дистә бар: 320; 480; 2 600; 5 750; 15 000; 725; 936; 2 317; 3 604; 51 076.

110. Түбәндәге саннарның һәрберсендә барысы ничә йөз бар: 700; 240; 16 200; 25 000; 162 000; 834; 4 638; 60 896; 375 026.

111. Түбәндәге саннарның һәрберсендә барысы ничә мең бар: 26 000; 345 000; 1 318 000; 55 370 000; 12 768; 2 300 614; 12 040 697; 180 180 180.

Бу саннарның һәрберсендә барысы ничә дистә мең бар?

112. Түбәндәге саннарның һәрберсендә барысы ничә дистә, барысы ничә йөз, барысы ничә мең, барысы ничә дистә мең бар икәнен әйтергә: 32 010; 504 308; 1 000 000; 34 008 008.

Санда барысы ничә дистә, ничә йөз, ничә мең һ. а. ш. бар икәнен белү өчен, ул санда түбән разрядларның барлык берәмлекләрен ташларга һәм калган санны укырга кирәк.

113. 1) Әгәр уң ягына бер нуль өстәп язсаң, 832 саны ничек үзгәрер? ике нуль өстәп язсаң? өч нуль өстәп язсаң?

2) Әгәр уң ягыннан бер нульне ташласаң, 1 000 000 саны ничек үзгәрер? ике нульне ташласаң? өч нульне? дүрт нульне?

114. 62 725 саны ничә цифра белән язылган? Алар арасында төрле цифралар ничә? 1 000 000 саны ничә цифра белән язылган? Алар арасында төрле цифралар ничә? Унике урынлы санны бер үк төрле цифраны ике тапкыр файдаланмыйча язып буламы?

115. 1, 2, 3 цифралары ярдәмендә берничә өчурынлы сан языгыз, ләкин һәрбер санда бер үк цифра бары тик бер генә тапкыр очрасын. Шундый ничә сан язарга мөмкин?

116. Иң кечкенә берурынлы, иң кечкенә икеурынлы, иң кечкенә өчурынлы һәм иң кечкенә дүртурынлы саннарны кушсаң, суммада ничә килеп чыга?

Күбурынлы саннарны кушу һәм алу.

117. Болында 86 сыер йөри иде. Алар янына тагы 9 сыер куып китерделәр. Болында барысы ничә сыер булды?

Бу мәсьәләне чишү өчен 86 га 9 ны өстәргә кирәк, 95 килеп чыга. 95 саны беренче санның барлык берәмлекләрен (86) һәм икенче санның барлык берәмлекләрен (9) үз эченә ала. 95 — ике санның суммасы.

Ике яки берничә санның суммасы дип, кушыла торган саннарның барлык берәмлекләрен үз эченә алган санны атыйлар.

Кушыла торган саннар кушылучылар дип аталалар.

Ике яки берничә кушылучының суммасын табу гамәле кушу гамәле дип атала.

Кушуның тамгасы + (плюс).

118. 1) Бер кушылучы 16 427, икенчесе 8 697. Аларның суммасын табарга.

2) Өч кушылучының суммасын табарга: 9786, 395 һәм 4 006.

3) Беренче кушылучы 9 668, икенчесе аннан 397 гә зуррак, ә өченчесе беренче ике кушылучы суммасына тигез. Өч кушылучының суммасы күпмегә тигез?

4) 13 708 һәм 6 075 саннарының суммасын 10 970 кә зурайтырга.

119. Төрле тәртиптә кушып, өч кушылучының суммасын исәпләргә: 7 428, 974 һәм 1 936.

Кушуның урын алмаштыру үзлеге.

Кушылучыларның урыннарын алмаштырудан сумма үзгәрми.

Бу үзлектән кушуның дөреслеген тикшерү өчен файдаланалар.

Кушуның дөреслеген тикшерү өчен, кушылучыларны икенче тәртиптә кушалар. Әгәр гамәл дөрес эшләнгән булса, шул ук сумма килеп чыга.

120. Кушарга һәм дөреслеген тикшерергә:

1) 4 458 891 + 7 650 209 + 987 540
2) 1 167 502 + 554 630 + 6 086 010 + 30 456
3) 30 478 + 137 + 590 + 100 789 + 90 396 168

121. (Телдән.) Кушуның иң уңай юлыннан файдаланып, чишәргә:

54 + 97 + 46	63 + 75 + 27 + 25
16 + 48 + 84	18 + 62 + 35 + 55
76 + 35 + 65	180 + 450 + 120 + 150

122. Ленинградтагы М. Е. Салтыков-Щедрин исемендәге китапханәдә 1949 елда 10 000 000, ә Москвадагы В. И. Ленин исемендәге китапханәдә, аңа караганда, 3 000 000 га артыграк китап булган. Бу ике китапханәдә ничә китап булган?

123. Европада 600 000 000, Америкада 325 000 000, Африкада 200 000 000, Австралиядә 13 000 000, ә Азиядә, деньяның башка кисәкләрендәге барлык халыкка караганда, 262 000 000 га артыграк кеше яши. Бөтен җир шарында күпме кеше яши?

124. Бер районның хезмәт ияләре сентябрь аенда саклык кассасына 5 735 600 сум, ә октябрьда, сентябрьгә караганда, 486 195 сумга артыграк, ә ноябрьда сентябрь белән октябрьдагының икесеннән 100 200 сумга артыграк акча керттеләр. Өч айда саклык кассасына ничә сум акча кертелгән?

125. Түбәндәге мәсьәләләрнең чишелешен языгыз:

1) Участокта беренче көндә 60 төп, ә икенче көнне 80 төп агач утырттылар. Ике көндә ничә төп агач утыртканнар?

2) Ике көндә 140 төп агач утырттылар, шулардан беренче көнне 60 төп утырттылар. Икенче көнне ничә төп агач утыртканнар?

3) Ике көндә 140 төп агач утыртканнар, шулардан икенче көнне 80 төп утырттылар. Беренче көнне ничә төп агач утыртканнар?

Беренче мәсьәләдә бирелгән кушылучылар икенче һәм өченче мәсьәләләрдә нинди гамәл белән табылалар?

126. Узган мәсьәләләр үрнәгендә өч мәсьәлә төзегез һәм чишегез. Сумма һәм бер кушылучы буенча икенче кушылучыны ничек табарга икәне турында нәтиҗә ясагыз.

127. 1) Ике кушылучының суммасы 2 360, аларның берсе 970. Икенче кушылучыны табарга.

2) Ике кушылучының суммасы 1 060, беренче кушылучы 979. Икенче кушылучыны табарга.

Һәрбер кушылучы сан суммадан икенче кушылучыны алгач чыккан санга тигез. Шуңа күрә, билгесез кушылучыны табу өчен суммадан билгеле кушылучыны алырга кирәк.

128. Билгесез кушылучыны (x) табарга:

$x+625=1\,200$	$730+x=1\,430$	$x+60+80=400$
$x+960=1\,800$	$685+x=2\,772$	$50+x+70=800$
$x+560=1\,500$	$496+x=3\,185$	$90+60+x=900$

Ике кушылучыны кушу дөреслеген тикшерү өчен, суммадан бер кушылучыны алу җитә. Әгәр кушу дөрес эшләнгән булса, калдыкта икенче кушылучы килеп чыгарга тиеш.

129 Кушарга һәм алу юлы белән дөреслеген тикшерергә:

$734\,508+345\,782$	$5\,806+19\,048+504\,637$
$547\,208+1\,362\,869$	$8\,700+90\,059+600\,702$

130. Колхоз кышка печән хәзерләгән. 3 780 *ц* печәнне тоткач, тотылганга караганда 1 804 *ц* артыграк печән калган. Ничә центнер печән хәзерләнгән булган? (4 нче рәсем).

131. Колхоз хәзерләнгән сиюстан 1 882 *ц* ын тоткан. Бу — калган силоска караганда 283 *ц* га кимрәк. Барысы ничә центнер силос хәзерләнгән булган?



4 нче рәсем.

132. Колхоз бакчачылыктан 138 720 сум доход алган. Бу — кырчылыктан алынган доходтан 659 400 сумга кимрәк. Колхозның кырчылыктан һәм бакчачылыктан алган гомуми доходын исәпләргә.

133. Мисалларны, кушылучыларны түгәрәкләүдән файдаланып, чишәргә:

99 + 56	89 + 49	199 + 45	399 + 260
98 + 76	39 + 58	298 + 64	299 + 198

134. Мисалларны, кушылучыларның урыннарын алмаштырудан файдаланып, чишәргә:

67 + 55 + 23	380 + 57 + 20	66 + 85 + 34 + 15
64 + 78 + 36	518 + 96 + 82	89 + 75 + 11 + 25

135. 1) Түгәрәкләү алымын, 2) кушылучыларның урыннарын алмаштыру алымын файдаланып чишү уңайрак булган өч мисал уйлап табарга.

136. Счётта кушарга:

45 + 49	352 + 245	1 709 + 1 205
54 + 29	243 + 617	2 304 + 2 508
65 + 58	425 + 945	4 740 + 1 260
37 + 85	564 + 136	5 354 + 7 646


5 нче рәсем.

137. $x + 2\,689 = 52\,035$

$x + 1\,592 = 30\,100$

$1\,236 + x = 8\,000$ $\quad$ $x + 3\,240 = 90\,208$

$2\,040 + x = 7\,504$ $\quad$ $9\,408 + x = 70\,326$

138. x ны табарга:

Беренче кушылучы	Икенче кушылучы	Сумма
79	x	115
x	80	700
135	x	135
x	584	584

139. Өч амбарда 2 400 *ц* арыш бар. Беренче һәм икенче амбарда 2 000 *ц*, икенче һәм өченче амбарда 1 000 *ц*. Һәр амбарда ничә центнер арыш бар?

140. Әгәр СССРдагы өч елганың — Обь, Лена һәм Амур елгаларының озынлыкларын кушсаң, 12 634 *км* була. Обь һәм Лена икесе бергә 8 280 *км*, ә Лена һәм Амур бергә 8 618 *км*. Бу елгаларның һәрберсенең озынлыгын табарга. Чишелешнең дөреслеген тикшерергә.

141. Өч санның суммасы 16 336. Әгәр беренче һәм өченче санны кушсаң, 10 702 чыга; әгәр икенче белән өченче санны кушсаң, 6 712 чыга. Өч санның һәркайсын табарга.

142. Кушуга ике простой мәсьәлә төзергә: 1) ике санның суммасын табуга; 2) санны берничә берәмлеккә арттыруга.

143. Түбәндәгечә чишелә торган мәсьәлә уйлап табарга:

1) 64 *кг* + 16 *кг* = 80 *кг*;

2) 64 *кг* + 80 *кг* = 144 *кг*.

Җавап. Ике агачтан 144 *кг* алма җыеп алганнар.

144. Ике санның суммасы ул саннарның берсенә тигез булуы мөмкинме? Бу нинди очракта мөмкин? Мисал китерергә.

145. Ике кушылучының суммасы 1 690; аларның берсе 1 218. Икенче кушылучыны табарга.

Билгесез кушылучы нинди гамәл белән табылган?

Ике кушылучының суммасы һәм ул кушылучыларның берсе буенча икенче кушылучыны табу өчен кулланыла торган арифметик гамәл **алу** гамәле дип атала.

Нинди саннан алсалар, ул сан кимүче дип атала.

Нинди сан алынса, ул сан киметүче дип атала.

Алу нәтиҗәсендә килеп чыккан сан аерма дип атала.

Алуның тамгасы — (минус).

146. 1) Кимүче 1 080, киметүче 675. Аерманы табарга.

2) Кимүче 2 765, киметүче 1 096. Аерманы табарга.

3) 5 600 һәм 3 785 саннарының аермасын табарга.

147. (Телдән.) 1) 85 тән 25 не алсаң, күпме кала? 96 ны 24 кә киметсәң?

2) 76 саны 36 дан күпмегә зуррак? 17 саны 80 нән күпмегә кимрәк?

Бу сорауларның һәркайсы нинди гамәл белән чишелә?

148. (Телдән.)

76 — 24	48 — 48	120 — 56	560 — 180	6 — 0
45 — 28	132 — 17	150 — 78	475 — 475	0 — 0

149.

15 276 300 — 9 386 412	1 325 436 547 — 33 906 858
28 000 107 — 8 515 298	2 704 500 106 — 9 421 096
4 560 110 — 3 904 506	6 000 101 540 — 1 736 832

150.

14 160 510 — 13 904 602	2 460 245 + 940 759 — 630 278
6 100 101 540 — 1 736 834	1 001 050 — 803 264 + 102 214

151. Түбәндәге биремнәр буенча, план белән билгеләнгәнгә караганда, күпмегә артык доход алынганын исәпләргә:

План белән билгеләнгән (сумнар белән)	Алынган (сумнар белән)
Кырчылыктан 310 675	Кырчылыктан 396 750
Терлекчелектән 194 330	Терлекчелектән 269 800
Башка доходлар 56 350	Башка доходлар 68 765

152. Баржада такталар китерделәр: нарат такталар 30 210, каен такталар, наратка караганда, 7 294 кә кимрәк. Бер көн эчендә 26 084 нарат такта, аннан 9 126 га кимрәк каен такта бушаттылар. Баржада нинди такталар кимрәк калды һәм күпмегә кимрәк?

153. Түбәндәге мәсьәләләрнең чишелешен языгыз:

1) Китапханәдә 2 000 китап бар. 500 китапны биргәннәр. Күпме китап калган?

2) Китапханәдән 500 китап биргәч, анда 1 500 китап калган. Китапханәдә күпме китап булган?

Беренче мәсьәләдә бирелгән кимүче икенче мәсьәләдә нинди гамәл белән табыла?

154. 153 нче мәсьәлә үрнәгендә ике мәсьәлә төзегез һәм чишегез. Бирелгән киметүче һәм аерма буенча кимүчене ничек табарга мөмкин икәне турында нәтиҗә ясагыз.

Кимүче киметүчегә аерманы кушудан чыккан санга тигез.

Шуңа күрә, билгесез кимүчене табу өчен киметүче белән аерманы кушарга кирәк.

155. Билгесез кимүчене (x) табарга:

$x - 642 = 1\,821$	$x - 3\,706 = 50\,408$
$x - 809 = 1\,034$	$x - 4\,085 = 7\,065$
$x - 936 = 1\,804$	$x - 6\,230 = 33\,032$

Алуның дөреслеген тикшерү өчен, киметүче белән калдыкны кушу җитә. Әгәр гамәл дөрес эшләнгән булса, кимүче килеп чыгарга тиеш.

156. Алырга һәм дөреслеген тикшерергә:

3 600 000 — 1 756 482	32 800 300 — 2 997 456
1 000 000 — 734 005	56 346 000 — 8 800 304
2 000 014 — 906 098	10 100 200 — 9 306 705

157. Дүрт басудан 10 000 *ц* бөртекле ашлык җыеп алдылар: беренче басудан 2 776 *ц*, икенче басудан, беренчегә караганда, 1 230 *ц* га артыграк, ә өченче басудан, икенчегә караганда, 2 718 *ц* га кимрәк. Дүртенче басудан ничә тонна ашлык җыеп алганнар?

158. Пионерларның ике отряды колхоз бакчасындагы агачларны кышка хәзерләргә өсләренә алдылар. Беренче отряд 158 агач, ә икенче отряд 174 агач хәзерләде. Шуннан соң беренче отрядка тагы 76 агач, ә икенче отрядка 68 агач хәзерлисе калды. Кайсы отряд агачны кышка күбрәк хәзерләргә өстенә алган һәм күпмегә артыграк?

159. (Телдән.) Кимүчене түгәрәкләү юлы белән исәпләргә:

101 — 75	201 — 30	304 — 26	505 — 48
102 — 75	203 — 30	408 — 50	707 — 82

160. Счётта исәпләргә:

78 — 25	54 — 29	356 — 132	800 — 508
96 — 46	76 — 28	892 — 206	400 — 175
42 — 14	90 — 43	508 — 375	1 900 — 405
63 — 35	80 — 54	604 — 309	1 200 — 304

161. Түбәндәге мәсьәләләрнең чишелешен языгыз:

1) Ташчы көнгә 2 400 кирпеч салырга тиеш. Обедка кадәр ул 1 300 кирпеч салган. Аның тагы ничә кирпеч саласы калган?

2) Ташчы көнгә 2 400 кирпеч салырга тиеш. Обедка кадәр эшенең бер өлешен үтәгәч, аның тагы 1 100 кирпеч саласы калган. Обедка кадәр ул ничә кирпеч салган?

Беренче мәсьәләдә бирелгән киметүче икенче мәсьәләдә нинди гамәл белән табыла?

162. 161 нче мәсьәлә үрнәгендә ике мәсьәлә төзегез һәм чишегез. Бирелгән кимүче һәм аерма буенча киметүчене ничек табарга кирәк икәне турында нәтиҗә ясагыз.

Киметүче кимүчедән аерманы алудан чыккан санга тигез.

Шуңа күрә, билгесез киметүчене табу өчен, кимүчедән аерманы алырга кирәк.

163. Билгесез киметүчене (x) табарга:

$240 - x = 100$	$3\,175 - x = 697$	$25\,754 - x = 18\,876$
$400 - x = 360$	$9\,232 - x = 1\,068$	$10\,000 - x = 9\,999$
$896 - x = 208$	$6\,010 - x = 2\,086$	$20\,010 - x = 10\,102$

Алуның дөреслеген тикшерү өчен, кимүчедән аерманы алу җитә. Әгәр гамәл дөрес эшләнгән булса, нәтиҗәдә киметүче килеп чыгарга тиеш.

164. Мисалларны чишәргә һәм алу юлы белән дөреслеген тикшерергә:

$10\,000 - 4\,062$	$364\,825 - 260\,087$	$820\,000 - 76\,598$
$401\,520 - 295\,092$	$604\,020 - 584\,635$	$100\,000 - 79\,295$

165. (Телдән.) Китапта 276 бит. Укучы китапның бер өлешен укыгач, аның тагы 80 бит укыйсы калган. Калганга караганда ничә бит артыграк укылган?

166. Кул хезмәте дәресләре өчен ел башында мәктәп 1 250 табак газета кәгазе һәм 1 100 табак альбом кәгазе хәзерләгән. Ел азагына 175 табак газета кәгазе һәм 158 табак альбом кәгазе калган. Бер ел эчендә теге һәм бу сорттан ничәшәр табак кәгазь тотылган?

167. Кирпеч заводында алдынгы эшчеләр кирпеч яндыруның срогын 168 сәгатьтән 38 сәгатькә кадәр кыскарттылар,

ә мең кирпечне яндыру өчен ягулык расходын 160 *кг* нан 115 *кг* га кадәр киметтеләр. Алдынгы эшчеләр күпме вакытка һәм күпме ягулыкка экономия ясадылар?

168. Элек токарь бер сменада норма буенча каралган 150 божра урынына 270 божра эшли иде. Хәзер ул норма белән каралган 210 божра урынына 400 божра эшли. Элек эшче норманы ничә божрага арттырып үтәгән? Хәзер ул норманы ничә божрага арттырып үти?

169. (Телдән.) Киметүчене табарга:

1) кимүче 380, аерма 240 булганда;

2) кимүче 1 000, аерма 520 булганда.

170. (Телдән.) Кимүчене табарга:

1) киметүче 730, аерма 270 булганда;

2) киметүче 87, аерма 63 булганда.

171. $7\,536 - x = 4\,280$ $\quad x - 20\,375 = 20\,375$

$76\,082 - x = 36\,745$ $\quad 1\,280 + x = 4\,765$

$x - 65\,012 = 3\,800$ $\quad x - 9\,007 = 1\,038$

Соңгы мисаллар үрнәгендә ике мисал төзергә һәм аларны чишәргә.

172. Фабрикадагы иң яхшы бригадаларның берсе көн саен 16 800 *м* тукыма эшләп чыгара. Бу — нормадан 4 016 *м* га артыграк, ә норма бригада алган йөкләмәдән 1 640 *м* га кимрәк. Бригаданың йөкләмәсе ничә метр? (6 нчы рәсем.)



6 нчы рәсем.

173. Быел совхоз бер гектардан 420 *ц* чөгендер уңышы җыеп алды. Бу, узган елдагыга караганда, 45 *ц* га артыграк, ә киләчәк ел планына караганда, 35 *ц* га кимрәк. Узган ел бер гектардан ничә центнер чөгендер җыйганнар? Киләсе елда гектардан ничә центнер чөгендер алу планлаштырылган?

174. Лена елгасы Днепрдан 1 979 *км* га озынрак, Днепр Волгадан 1 403 *км* га кыскарак. Әгәр Лenaның озынлыгы 4 264 *км* булса, Волга һәм Днепрның озынлыгын табарга.

175. x ны табарга:

Кимүче	Киметүче	Аерма
x	64	96
500	x	280
x	20 039	10 088
83	x	83

176. 1) Кимүче 1 000 386, аерма 82 485. Киметүчене табарга.

2) Киметүче 20 039, аерма 10 038. Кимүчене табарга.

177. 1) 6 328 һәм 4 126 саннарының аермасына аларның суммасын кушарга.

2) 10 132 һәм 896 саннарының суммасыннан аларның аермасын алырга.

178. $64\,872 : 68 \times 506 + 108\,277 - 200\,326$

$(30\,450\,000 + 12\,350\,000) - (8\,750\,000 + 4\,850\,000)$

$(30\,450\,000 - 8\,750\,000) + (12\,350\,000 - 4\,850\,000)$

179. Укучылар бакчада барысы 350 төп крыжовник, кура җиләге һәм карлыган утыртырга тиешләр. Барлык крыжовникларны утырткач, тагы 190 төп кура җиләге һәм аннан ике тапкыр кимрәк карлыган утыртасы калган. Укучылар ничә төп крыжовник утыртканнар?

180. Складта яшелчә запасы булган. Һәрберсенә 1 900 *кг* төяп, 3 машина һәм һәрберсенә 2 100 *кг* төяп, 5 машина белән магазиннарга җибәргәч, складта, җибәргәнгә караганда, 4 тапкыр артыграк яшелчә калган. Магазиннарга җибәргәнче складта ничә тонна яшелчә булган?

181. Түбәндәге биремнәр буенча алуга мәсьәләләр төзергә һәм чишәргә:

1) Бер посёлокта радио буенча иртәнге гимнастиканы ел башында 96, ә ел азагында 200 бала ясаган.

2) Илдар картон папканы 58 минутта ясаган, ә Илдус шундый ук папканы ясау өчен 12 минут кимрәк вакыт үткәргән.

3) „Булдыклы куллар“ түгәрәге өчен 480 табак картон хәзерләнгән. Бер айда 320 табак картон тотканнар.

182. 1) Аерма кимүчегә тигез була аламы? Бу нинди очракта мөмкин? Мисаллар китерергә.

2) Аерма киметүчегә тигез була аламы? Мисаллар китерергә.

Кабатлау өчен сораулар.

1) Ике яки берничә санның суммасы нинди гамәл белән табыла?

2) Кушканда саннар ничек аталалар?

3) Кушуның урын алмаштыру үзлеге нәрсәдән тора?

4) Исәпләүләрдә кушуның урын алмаштыру үзлеген файдалану кайчан уңай?

5) Билгесез кушылучыны ничек табарга?

6) Кушуның дөреслеген ничек тикшерергә?

7) Сумма һәм бер кушылучы буенча ике кушылучының берсе нинди гамәл белән табыла?

8) Алганда саннар ничек атала?

9) Билгесез кимүчене ничек табарга? билгесез киметүчене?

10) Алуның дөреслеген ничек тикшерергә?

Һәр җавапны мисаллар белән аңлатып бирергә.

Арифметик урта исәпләүгә мәсьәләләр.

183. Бер гектардан 18 *ц*, икенче гектардан 20 *ц* арыш җыеп алдылар. Һәр гектардан уртача ничә центнер арыш җыеп алдылар?

184. Велосипедист беренче сәгатьтә 17 *км*, икенче сәгатьтә 15 *км* юл үтте. Велосипедистның уртача сәгатьлек хәрәкәт тизлеген табарга.

185. Вәли иртәнге аш өчен бер көнне 70 тиен, икенче көнне 90 тиен тотты. Вәли иртәнге аш өчен һәр көнне уртача ничә тиен акча тотты?

186. Илдус ике йомырканы аерым-аерым үлчәде; берсе 60 *г*, икенчесе 70 *г* килде. Һәр йомырка уртача ничә грамм авырлыкта килә?

187. Һаваның температурасын күзәтеп, укучы һава календарена иртән 9°, көндез 16°, кичен 11° җылылык булуын язды. Бу көннең уртача һава температурасын табарга.

188. Укучы кыз 4 көн буена һава температурасын күзәтеп барды һәм һәр көннең уртача температурасын таблицага язды.

Число	Температура
20.IX	12° җылылык
21.IX	16° „
22.IX	12° „
23.IX	8° „

Бу көннәрдә һаваның уртача температурасы нинди булган?

189. Мәктәптә алып барыла торган күзәтүләр буенча һәр көннең уртача температурасын, ә аннан соң берничә көннең уртача температурасын табарга.

190. Трактор бригадалары беренче көнне 69 *га*, икенче көнне 74 *га*, өченче көнне 75 *га*, дүртенче көнне 70 *га* чирәм җирне сөрделәр. Трактор бригадалары 1 көнгә уртача ничә гектар чирәм җирне сөргәннәр?

191. Бер китапханәдә соңгы 7 ел эчендә укучылар саны 480 нән 1 376 кешегә кадәр арткан. Бу китапханәдә ел саен уртача ничә укучы арткан?

192. Ташчыларның алдынгы звеносы беренче көнне 14 500 данә кирпеч, икенче көнне 15 300, өченче көнне 20 150, ә дүртенче көнне, өченче көнгә караганда, 2 800 кирпеч артыграк салган. Звено көнгә уртача күпме кирпеч салган?

Берничә санның арифметик уртасын табу өчен, бу саннарның суммасын табарга һәм аны кушылучылар санына бүләргә кирәк.

193. Саннарның арифметик уртасын табарга:

1) 45 һәм 27	5) 207, 185, 300 һәм 264
2) 90, 100 һәм 110	6) 485, 516, 706 һәм 689
3) 84, 133 һәм 128	7) 1 070, 1 001, 986 һәм 1 015
4) 390, 350, 280	8) 110, 478, 915, 1 070 һәм 2 832

194. Поезд сәгатькә 45 *км* тизлек белән 2 сәгать һәм сәгатькә 50 *км* тизлек белән 3 сәгать барды. Поезд сәгатькә уртача ничә километр барды?

195. Ике шәһәр арасын поезд 15 сәгатьтә узды. Беренче 9 сәгатьтә ул сәгатькә 40 *км* тизлек белән, ә калган вакытта сәгатькә 45 *км* тизлек белән барды. Барлык араны ул уртача нинди тизлек белән узган?

196. Бригада 15 *га* дан 18 әр центнер, 10 *га* дан 20 шәр центнер һәм 20 *га* дан 26 шар центнер арыш уңышы алды. 1 гектардан алынган уртача уңышны табарга.

197. Совхозда 150 баш савым сыер бар. 36 сыерның һәрберсе елга 4 100 *л*, 58 сыер 3 900 *л*, калган сыерлар 3 000 *л* сөт бирделәр. Бер сыердан алынган уртача еллык савымны табарга.

198. 1) Үз адымының үлчәмен белү өчен, Наил җир өстендә 48 *м* озынлыктагы араны билгеләде һәм аны өч тап-

кыр үтте. Беренче тапкыр ул 81 адым, икенче тапкыр 79 адым һәм өченче тапкыр 80 адым ясавын санады. 48 *м* арада Наил уртача ничә адым ясый? Аның адымы нинди озынлыкта?

Искәрмә. 48 *м* = 4 800 *см*.

2) Өеннән мәктәпкә кадәр араның ераклыгын белү өчен, Наил бу араны өч тапкыр узган һәм уртача зурлыкны алган. Беренче тапкырда ул 200 адым, икенче тапкыр 208 адым, өченче тапкыр 207 адым ясаган. Өйдән мәктәпкә кадәр араның ераклыгы күпмегә тигез?

199. Түбәндәгечә чишелә торган мәсьәлә уйлап табарга:

$$(40\ кг + 48\ кг + 50\ кг) : 3 = 46\ кг.$$

200. Ике яки өч санның арифметик уртасын табу соралган мәсьәлә уйлап табарга.

201. Бирелгән ике кисемтәнең уртача озынлыгын табарга (7 нче рәсем).



7 нче рәсем.

Күбурынлы саннарны тапкырлау һәм бүлү.

202. Самолёт сәгатькә 326 *км* тизлек белән оча. Шул ук тизлек белән очса, 6 сәгатьтә ул ничә километр араны очып узар?

Бу мәсьәләне чишү өчен 326 санын 6 тапкыр кушылучы итеп кабатларга кирәк.

$$326 + 326 + 326 + 326 + 326 + 326 = 1\,956.$$

Без сумманы кушу юлы белән таптык. Бу — озын итеп язуны һәм зур исәпләүләрне сорады. Язылыш һәм исәпләүләрне простойлаштыру өчен, бертөрле кушылучыларны кушуны тапкырлау белән алмаштырыйк:

$$\begin{array}{r} 326 \\ \times 6 \\ \hline 1\,956 \end{array}$$

Һәрберсе 326 га тигез булган бертигез алты кушылучының әле генә табылган суммасы 326 ның 6 га тапкырчыгышы диеп атала.

Тапкырчыгыш дип тигез кушылучыларның суммасы атала

Кушылучы булып кабатлана (тапкырлана) торган сан тапкырланучы дип атала.

Бертөрле кушылучыларның ничә тапкыр алынуын күрсәткән сан тапкырлаучы дип атала.

Тапкырланучы һәм тапкырлаучының уртак исемнәре бар — тапкырлашучылар.

Ике яки берничә санның тапкырчыгышын табу гамәле тапкырлау гамәле дип атала.

Тапкырлау тамгасы $\times$ (кыек крест) яки . (нокта).

203. 1) Тапкырланучы 94, тапкырлаучы 27. Тапкырчыгышны исәпләргә.

2) Тапкырлашучыларның берсе 18, икенчесе 15. Тапкырчыгышны табарга.

3) 284 санын 36 тапкыр зурайтырга.

4) 280 не 6 га тапкырлагач, 1 680 чыга дигәнне, гамәл тамгасы һәм тигезлек тамгасы ярдәмендә язарга.

204. Түбәндәге тигезлекләрнең дөреслеген тикшерергә:

1) $86 \times 47 = 47 \times 86$; 2) $100 \times 54 = 54 \times 100$.

Тапкырлауның урын алмаштыру үзлеге.

Тапкырлашучыларның урыннарын алмаштырып куюдан тапкырчыгыш үзгәрми.

Бу үзлекне тапкырлауның дөреслеген тикшерү өчен файдаланырга мөмкин.

Тапкырлауның дөреслеген тикшерү өчен, саннарны икенче тәртиптә тапкырлыйлар. Әгәр гамәл дөрес эшләнгән булса, шул ук тапкырчыгыш килеп чыгарга тиеш.

205. Тапкырларга һәм дөреслеген тикшерергә:

86×28	530×47	608×824	265×187
49×36	790×58	407×652	346×428

206. Тапкырлауны иң уңай тәртиптә эшләргә:

$5 \times 6\,483$	72×498	300×746	735×36
$8 \times 3\,069$	56×279	800×903	504×68

207. $6\,268 \times 483$ $\quad 806 \times 217$ $\quad 764 \times 802$ $\quad 106 \times 105$

$2\,068 \times 145$ $\quad 309 \times 457$ $\quad 618 \times 205$ $\quad 204 \times 503$

$1\,705 \times 378$ $\quad 507 \times 691$ $\quad 569 \times 304$ $\quad 707 \times 409$

Һәр баганадагы соңгы мисалның дөреслеген тикшерергә.

208. 1×9 $\quad 0 \times 6$ $\quad 86 \times 4$ $\quad 36 \times 8$ $\quad 97 \times 8$

7×1 $\quad 0 \times 8$ $\quad 72 \times 5$ $\quad 48 \times 6$ $\quad 65 \times 4$

209. (Телдән.) 1) Төзелештә җир казучы өч машина эшли. Аларның һәрберсе 25 000 җир казучының хезмәтен алмаштыра. Бу машиналар ничә җир казучыны алмаштыралар?

2) Колхоз элеваторга 120 *ц* солы, солыдан 5 тапкыр артыграк арыш, арышка караганда өч тапкыр артык бодай илткән. Элеваторга ничә центнер бодай илтелгән?

3) Москвадан Тбилисигә кадәр тимер юл белән 2516 *км*. Бу, Москвадан Иркутскига караганда, 2 тапкыр якынрак. Москвадан Иркутскига кадәрге ераклыкны табарга.

4) Поездның тизлеге сәгатькә 50 *км*. Бу, пассажир самолёты тизлегенә караганда, 6 тапкыр кимрәк. Самолётның сәгатьлек тизлеген табарга.

210. Күке бер сәгатьтә 100 данә гусеница (күбәләк корты) ашый ала. Күке бездә елга 135 көн тора һәм көн саен 16 сәгать буена азык эзли дип алынса, ул җәй буена ничә гусеницаны бетерә?

211. Бер гектар җир уртача уңыш биргәндә, арыш туфрактан 161 *кг*, ә солы 208 *кг* туклыклы матдәләр ала. Колхоз 136 *га* җирдән арыш, ә 75 *га* мәйданнан солы уңышы җыеп алды. Арыш һәм солы бу мәйдандагы туфрактан күпме туклыклы матдәләр алган?

212. (Телдән.)

10×6 $\quad 30 \times 4$ $\quad 80 \times 3$ $\quad 100 \times 7$ $\quad 100 \times 9$

10×60 $\quad 30 \times 40$ $\quad 80 \times 30$ $\quad 100 \times 70$ $\quad 100 \times 90$

10×600 $\quad 30 \times 400$ $\quad 80 \times 300$ $\quad 100 \times 700$ $\quad 100 \times 900$

213. Пальто 520 сум тора. Шундый 6 пальто күпме тора? Шундый 60 пальто күпме тора? 600 пальто?

214. 370×8 $\quad 560 \times 9$ $\quad 800 \times 700$ $\quad 7\,500 \times 200$

370×80 $\quad 560 \times 90$ $\quad 900 \times 600$ $\quad 4\,900 \times 360$

370×800 $\quad 560 \times 900$ $\quad 400 \times 800$ $\quad 6\,000 \times 750$

215. 70×60	680×70	300×400	$5\,000 \times 360$
90×50	460×90	450×700	$6\,900 \times 400$
30×80	970×60	800×800	$8\,720 \times 350$

Әгәр тапкырланучы һәм тапкырлаучы нульләргә бетсәләр, тапкырлауны, нульләргә игътибар итмичә, эшлиләр һәм соңыннан, тапкырланучы һәм тапкырлаучының икесендә ничә нуль булса, тапкырчыгышның уң ягына шулкадәр нуль өстәп язалар.

216. Туку фабрикасы бер айда 2 124 720 *м* сатин һәм аннан икеләтә артык ситсы эшләп чыгарды. Моннан, һәрберсенә 95 500 *м* материя төяп, 60 вагон тукыманы төрле шәһәрләргә, ә калганын тегү фабрикаларына җибәрделәр. Тегү фабрикаларына күпме материя җибәрелгән?

217. Совхозда виноград җыярга 70 эшче чыккан. Алардан 20 кеше көнгә 300 әр килограмм, 30 кеше 400 әр килограмм, ә калганнары 340 ар килограмм виноград җыйганнар. Барлык эшчеләр көнгә ничә килограмм виноград җыйганнар?

218. Түбәндәге мәсьәләләрнең чишелешен язызыз:

1) Укучы 14 әр тиеннән 5 дәфтәр сатып алган. Барлык дәфтәрләр күпме тора?

2) Укучы 5 дәфтәр өчен 70 тиен түләгән. Бер дәфтәр күпме тора?

3) Укучы 70 тиенгә 14 әр тиенлек дәфтәрләр сатып алган. Ничә дәфтәр сатып алынган?

Беренче мәсьәләдә бирелгән тапкырлашучылар икенче һәм өченче мәсьәләләрдә нинди гамәлләр белән табыла?

219. 218 нче мәсьәлә үрнәгендә өч мәсьәлә төзегез. Бирелгән тапкырчыгыш һәм бер тапкырлашучы буенча икенче тапкырлашучыны табу турында нәтиҗә ясагыз.

220. 1) Тапкырланучы 75, тапкырчыгыш 750. Тапкырлаучыны табарга.

2) Тапкырлаучы 90, тапкырчыгыш 540. Тапкырланучыны табарга.

3) Тапкырлашучыларның берсе 80, тапкырчыгыш 3 600. Икенче тапкырлашучыны табарга.

4) Ике санның тапкырчыгышы 3 240. Бу саннарның берсе 72. Икенче санны табарга.

Һәр тапкырлашучы тапкырчыгышны икенче тапкырлашучыга бүлүдән чыккан санга тигез.

Шуңа күрә, билгесез тапкырлашучыны табу өчен, тапкырчыгышны билгеле тапкырлашучыга бүләргә кирәк.

221. Билгесез тапкырлашучыны (x) табарга:

1) $x \times 6 = 72$	$x \times 9 = 567$	$46 \times x = 690$
$x \times 4 = 96$	$x \times 5 = 965$	$32 \times x = 384$
2) $x \times 24 = 1\,320$	$x \times 45 = 3\,780$	$32 \times x = 2\,560$
$x \times 54 = 1\,512$	$x \times 50 = 5\,750$	$25 \times x = 3\,250$

222. Тапкырларга һәм бүлү белән дәреслеген тикшерергә:

87×25	426×312	256×300
76×46	532×124	728×500
54×79	246×513	514×420

223. Тере сыерның авырлыгын (килограммнар белән) табу өчен, сантиметрлар белән аның арка озынлыгын (җилкә калкымыннан койрыкка кадәр) һәм калак сөякләре яныннан юанлыгын үлчиләр. Килеп чыккан саннарны бер-беренә тапкырлыйлар һәм тапкырчыгышны 50 гә бүләләр.



8 нче рәсем.

Тере сыерларның авырлыкларын табарга:

1) арка озынлыгы 125 *см*, ә юанлыгы 170 *см*; 2) арка озынлыгы 128 *см*, ә юанлыгы 175 *см*.

224. Өч пекарняга бер үк авырлыктагы капчыкларда 6 400 *кг* он җибәрелгән: бер пекарняга 20 капчык, икенчесенә 25, өченчесенә 35 капчык. Һәр пекарняга ничә килограмм он җибәрелгән?

225. (Телдән.) Иң уңай тәртиптә тапкырларга:

$4 \times 17 \times 25$	$9 \times 4 \times 15$	$87 \times 5 \times 2$
$4 \times 28 \times 25$	$2 \times 7 \times 45$	$72 \times 2 \times 5$
$5 \times 15 \times 20$	$6 \times 12 \times 5$	$26 \times 15 \times 2$

226. $738 \times 2\,050$ $2\,600 \times 406$ 802×607 $7\,004 \times 503$
$450 \times 5\,060$ $4\,570 \times 305$ 106×109 $9\,006 \times 408$

227. $1\,000\,000 - 356 \times 406$ $2\,007 \times 305 + 162\,708$
$900\,186 + 973 \times 308$ $3\,400 \times 501 - 85\,607$
$500\,100 - 708 \times 607$ $568 \times 370 - 99\,235$

228. Эшче көнгә 4 *т* торф хәзерли ала. Торф хәзерләүче бер машина 60 эшченең хезмәтен алмаштыра. 3 машина 125 көндә ничә тонна торф хәзерли ала?

229. 1) Пионерлар яз көне 40 *га* зурлыктагы мәйданның һәр гектарыннан уртача 17 шәр йомран ауладылар. Җәй буена бер йомран уртача 12 *кг* ашлыкны әрәм итә. Пионерлар колхозның күпме ашлыгын саклаганнар?

2) Акчарлак үзенең балаларына көнгә өч тапкыр азык китергән, ул һәр тапкырда уртача 50 шәр грамм төрле бөҗәкләр алып кайткан. Балаларны туйдыру 50 көн дәвам иткән. Бу вакыт эчендә бер пар акчарлак ничә килограмм бөҗәкне бетергән?

230. (Телдән.)

1) $2 \times 2 \times 2 \times 5 \times 5 \times 5$ $2 \times 2 \times 2 \times 3 \times 5 \times 10$
$2 \times 3 \times 3 \times 3 \times 5 \times 5$ $2 \times 2 \times 2 \times 5 \times 13$

2) 16×12 12×12 15×12 17×11 12×14
18×12 11×11 15×15 18×14 11×16

3) 0×6 375×1 1×836 0×36

231. 1) Бер тапкырлашучы 60, икенчесе 40. Тапкырчыгышны табарга.

2) Ике санның тапкырчыгышы 490. Тапкырлашучыларның берсе 70. Икенче тапкырлашучыны табарга.

232. $3\,600 \times 640$ $960 \times 8\,200$ $5\,030 \times 360$ $4\,030 \times 6\,280$
$8\,400 \times 930$ $430 \times 4\,400$ $4\,080 \times 670$ $7\,080 \times 4\,060$
$7\,800 \times 540$ $780 \times 6\,100$ $9\,040 \times 465$ $6\,004 \times 2\,030$

233. $530 \times 706 + 804 \times 280$ $8\,240\,002 - 5\,200 \times 501$
$608 \times 509 - 503 \times 400$ $300\,804 + 390 \times 800$
$496 \times 679 + 600 \times 800$ $6\,000\,100 - 2\,060 \times 826$

234. (Телдән.) 1) Поезд Москвадан иртән сәгать 10 да чыга һәм, сәгатькә 56 *км* тизлек белән барып, көндез 1 дә Калинин шәһәренә килеп житә. Москвадан Калинин шәһәренә кадәр араның ераклыгын табарга.

2) Ике пункттан бер үк вакытта бер-беренә каршы ике автомобиль чыга. Берсе сәгатькә 45 *км*, икенчесе 55 *км* бара. 10 сәгатьтән соң автомобильләр очрашалар. Бу пунктларның арасын табарга.

3) Пионерлар йортында драма түгәрәгендә 24 кеше, туристлар түгәрәгендә, драма түгәрәгендәгегә караганда, 18 кеше артыграк, ә техника түгәрәгендә, туристлар түгәрәгендәгегә караганда, 2 тапкыр артыграк кеше шөгыльләнә. Барлык түгәрәкләрдә бөтенесе ничә пионер катнаша?

235. Тапкырлау белән чишелә торган ике простой мәсьәлә төзергә.

236. Аучылар 3 көндә 76 шар тиен, 3 көндә 82 әр тиен һәм 2 көндә 91 әр тиен алып кайттылар. Аучылар көнгә уртача ничә тиен аулаганнар?

237. Пионерларның бер звеносында бер ел эчендә 6 пионер 20 шәр китап һәм 4 пионер 15 әр китап укып чыккан. Икенче звенода 5 пионер 21 әр китап һәм 5 пионер 17 шәр китап укыган. Кайсы звенода уртача бер пионер укып чыккан китаплар саны күбрәк һәм күпмегә артык?

238. Мебель фабрикасыннан мәктәпкә бирелгән счётның дөреслеген тикшерергә:

164 нче мәктәпкә счёт

Ел, ай, число	Җибәрелгән	Ничә	Бәя		Сумма	
			сум	тиен	сум	тиен
16 август 1955 ел	Парталар	200	120	—	24 000	—
	Өстәлләр	30	100	—	3 000	—
	Урындыклар	75	30	—	2 250	—
Барысы					29 250 сум	

239. „Победа“ совхозында 1952 елда 30 мең тавыкның һәрберсеннән уртача 174 йомырка, 1953 елда 187 йомырка, 1954 елда 200 йомырка алганнар. Совхозда бу тавыклардан алынган йомырка саны ел саен күпмегә арта барган?

240. 1) Тапкырчыгыш тапкырланучыга тигез була аламы? Бу кайчан мөмкин? Мисаллар китерергә.

2) Тапкырчыгыш тапкырлаучыга тигез була аламы? Бу кайчан мөмкин?

3) Ике санны тапкырлаудан нуль чыгарга мөмкинме? Мисаллар китерергә.

241. 1) Мәсьәләдә сатып алынган парталар саны һәм бер партаның бәясе бирелгән. Бу бирелмәләр буенча нәрсә белергә мөмкин һәм нинди гамәл белән?

2) Мәсьәләдә поездның хәрәкәт тизлеге һәм хәрәкәт вакыты билгеле. Бу бирелмәләр буенча нәрсә белергә мөмкин һәм нинди гамәл белән?

3) Мәсьәләдә онның капчыклар саны һәм бер капчык онның авырлыгы билгеле. Бу бирелмәләр буенча нәрсә белергә мөмкин һәм нинди гамәл белән?

---

242. Ике тапкырлашучының тапкырчыгышы 3 312. Тапкырлашучыларның берсе 72. Икенче тапкырлашучыны табарга.

Билгесез тапкырлашучы нинди гамәл белән табылды?

Бирелгән тапкырчыгыш һәм бер тапкырлашучы буенча икенче тапкырлашучыны табу өчен кулланыла торган арифметик гамәл **бүлү** гамәле дип атала.

Бүленә торган сан бүленүче дип атала.

Бүлә торган сан бүлүче дип атала.

Бүлүдән килеп чыккан сан өлеш дип атала.

Бүлү тамгасы : (ике нокта).

243. (Телдән.) 1) Бүленүче 240. Бүлүче 12. Өлешне табарга.

2) 9 600 не 100 гә бүлүдән чыккан өлешне табарга.

244. (Телдән.) 1) Әгәр 720 не 8 тигез кисәккә бүлсәң, ничә чыга? Әгәр 640 ны 8 тапкыр киметсәң? 560 ның сигезенче өлешен тапсаң?

2) 200 эчендә 8 ничә тапкыр бар? 480 саны 8 дән ничә тапкыр зуррак?

Бу сорауларның һәрберсе нинди гамәл белән чишелә?

245. (Гелдән.)

130 : 2   189 : 3   168 : 4   135 : 5   136 : 8
148 : 2   171 : 3   180 : 4   190 : 5   168 : 8

246. 1) 84 728 : 68   82 212 : 372   306 252 : 724
65 704 : 86   17 604 : 326   301 035 : 141

2 1 242 : 18   2 432 : 38   11 424 : 168   124 672 : 256
1 653 : 29   2 773 : 47   12 025 : 185   185 976 : 378

247. 1) 618 : 2   836 : 4   3 672 : 18   7 930 : 26
924 : 3   510 : 5   4 270 : 14   9 225 : 45

2) 178 640 : 58   508 750 : 125   28 112 200 : 734
264 550 : 65   749 840 : 364   43 228 800 : 684

248. Ике мебель фабрикасы клуб өчен 938 данә бертөсле урындыклар ясадылар. Клуб бер фабрикага 14 000 сум, икенчесенә 12 264 сум түләде. Һәр фабрика ничә урындык эшләгән? Чишүнең дөреслеген тикшерергә.

249. Мебель фабрикасы пионерларның ике лагере өчен бертөсле 165 кровать эшләгән. Кроватьлар өчен бер лагерь 5 250 сум, икенче лагерь 1 875 сум артыграк түләгән. Һәр лагерь ничә кровать алырга тиеш?

250. 800 : 200   1 500 : 500   24 000 : 3 000
900 : 300   1 800 : 200   75 000 : 5 000

251. 1) 5 760 : 40   32 000 : 500   840 000 : 6 000
3 600 : 80   78 300 : 900   702 000 : 2 700

2) 7 800 : 600   984 000 : 8 200   1 410 000 : 1 500
9 600 : 800   315 000 : 7 000   1 767 000 : 4 650

252. Яшь натуралистлар ике түтәлгә шикәр чөгендере утыртып, беренче түтәлдәге чөгендернең яфракларын өзеп тордылар, ә икенче түтәлдәгеләрнекен өзмәделәр. Уңыш җыйганда, беренче түтәлдән алынган 10 чөгендернең 2 000 г авырлыкта, ә икенче түтәлдән алынган 6 чөгендернең 7 200 г авырлыкта булуы күренде. Кайсы чөгендер авыррак һәм күпмегә артык?

253. Безнең илебез көнбатыштан көнчыгышка кадәр 11 000 *км* га сузыла. 1) Бу араны көнгә 40 ар километр барып, җәяү узу өчен күпме вакыт кирәк булыр? 2) Сәгатькә

50 *км* тизлек белән баручы поездда узу өчен? 3) Сәгатькә 275 *км* тизлек белән баручы самолётта очу өчен?

254. Бер шәһәрнең 150 хат ташучысы шәһәр халкына көн саен уртача 44 000 данә газета һәм журналлар, 20 000 хат, 2 000 акча переводлары тапшыралар. Бер көндә бер хат ташучыга уртача ничә данә корреспонденция тапшырырга туры килә.

255. (Телдән.) Түбәндәге мәсьәләләрнең чишелешләрен языгыз:

1) Комбайнёр 9 көндә 180 *га* ның бодаен урып-җыйды. Ул көн саен ничә гектардан уңыш җыйган?

2) Бер көндә комбайнёр 20 *га* ның уңышын җыя. 9 көндә ул ничә гектардан уңыш җыя алыр?

Беренче мәсьәләдә бирелгән бүленүче икенче мәсьәләдә нинди гамәл белән табыла?

256. 255 нче мәсьәләгә охшатып, ике мәсьәлә төзегез. Бирелгән бүлүче һәм өлеш буенча бүленүчене ничек табу турында нәтиҗә ясагыз.

257. 1) Бер санны 12 гә бүлделәр, өлештә 10 чыкты. Нинди санны бүлгәннәр?

2) Бүлүче 12, өлеш 15. Бүленүче ничәгә тигез?

Бүленүче бүлүчене өлешкә тапкырлаудан чыккан санга тигез.

Шуңа күрә, билгесез бүленүчене табу өчен, бүлүчене өлешкә тапкырларга кирәк.

258. Билгесез бүленүчене (x) табарга:

1) $x:72=18$ $\quad x:124=85$ $\quad x:206=380$
$x:46=32$ $\quad x:346=48$ $\quad x:420=506$

2) $x:64=2\,800$ $\quad x:806=507$ $\quad x:100=730$
$x:39=4\,008$ $\quad x:208=609$ $\quad x:300=450$

Бүлүнең дөреслеген тикшерү өчен, бүлүчене өлешкә тапкырлыйлар. Әгәр гамәл дөрес эшләнгән булса, нәтиҗәдә бүленүче килеп чыгарга тиеш.

259. Бүләргә һәм нәтиҗәнең дөреслеген тапкырлау белән тикшерергә:

3 216 : 48	86 904 : 284	276 012 : 396
4 307 : 59	98 490 : 490	301 020 : 692

260. Бер участоктан 1 230 *ц*, икенчесеннән 300 *ц* га кимрәк, ә өченче участоктан, беренче ике участокның икесенә караганда, 4 тапкыр кимрәк арыш җыеп алдылар. Барлык арышны һәрберсенә 75 әр килограмм сыешлы капчыкларга тутырдылар. Бу капчыкларның уникедән берен тегермәнгә җибәрделәр. Тегермәнгә ничә капчык арыш җибәргәннәр?

Күрсәтү. Бүлгәндә центнерларны килограммнар белән алмаштырырга.

261. 1) Эшче 8 көндә 96 деталь эшләргә задание алды. Заданиене срогыннан алда үтәргә теләп, эшче көнгә, билгеләнгәнгә караганда, 4 деталь артыграк эшләде. Эшче заданиене срогыннан ничә көн элек үтәгән?

2) План буенча завод 26 көндә 3 640 данә авыл хуҗалыгы машиналары эшләп чыгарырга тиеш. Эшчеләр планны срогыннан алда үтәргә карар бирделәр һәм көн саен, планга караганда, 42 машина артыграк эшләп чыгардылар. Завод планны срогыннан ничә көн элек үтәгән?

262. (Телдән). 1) Әгәр уйланган санны 20 тапкыр киметсәң, 30 килеп чыга. Уйланган санны табарга.

2) Бүлүче 30, өлеш 15. Бүленүчене табарга.

3) Түбәндәге саннарның һәрберсен 18 тапкыр кечерәйтергә:

54; 90; 180; 360; 720; 1 800.

4) Поезд, сәгатькә 50 шәр километр барып, ике шәһәр арасын 3 сәгатьтә узган. Сәгатькә 15 *км* тизлек белән баручы велосипедистка бу араның яртысын узу өчен, ничә сәгать вакыт кирәк булыр?

263. Бүлеп карамыйча гына, 906 ны 3 кә; 3 276 ны 36 га; 439 625 не 125 кә бүлгәндә, өлештә ничә цифра чыгачагын әйтергә.

264.				
	6 084 : 12	17 748 : 58	229 425 : 285	740 480 : 356
	9 246 : 23	16 308 : 27	335 104 : 476	776 710 : 253
	8 456 : 14	52 078 : 26	339 014 : 338	873 300 : 426

265. Бүләргә һәм дөреслеген тикшерергә:

29 638 : 73	63 648 : 312	9 335 424 : 2 576
15 288 : 42	259 080 : 635	28 765 500 : 3 175
46 920 : 23	263 344 : 436	3 426 584 : 2 846

266. Ике МТСка, тракторлар санына карап, ягулык җибәргәннәр: берсенә 17 700 *л*, икенчесенә 14 400 *л*. Беренче МТСта, икенчесенә караганда, 22 трактор артыграк булган. Һәр МТСта ничә трактор булган?

267. Бер мастерской күлмәкләр тегү өчен 4 250 *м*, икенчесе 3 125 *м* материя тоткан. Икенче мастерской, беренчегә караганда, 225 күлмәк кимрәк теккән. Һәр мастерской ничәшәр күлмәк теккән? Дөреслеген тикшерергә.

268. Түбәндәге мәсьәләләрнең чишелешен язарга:

1) Колхозчы кыз 6 көндә 540 *кг* мамык җыйган. Ул һәр көнне ничә килограмм мамык җыйган?

2) Колхозчы кыз, көн саен 90 шар килограмм җыеп, 540 *кг* мамык җыйган. Ул ничә көн эшләгән?

Беренче мәсьәләдә бирелгән бүлүче икенче мәсьәләдә нинди гамәл белән табыла?

269. Бу мисалларның һәрберсендә бүленүчене өлешкә бүләргә:

1) $384 : 12 = 32$; 2) $650 : 13 = 50$; 3) $900 : 150 = 6$.

Килеп чыккан нәтиҗәне бүлүче белән чагыштырырга һәм бирелгән бүленүче һәм өлеш буенча бүлүчене ничек табарга кирәклеге турында нәтиҗә ясарга.

Бүлүче бүленүчене өлешкә бүлүдән чыккан санга тигез.

Шуңа күрә, билгесез бүлүчене табу өчен, бүленүчене өлешкә бүләргә кирәк.

270. 1) Бүленүче 1 000, өлеш 250. Бүлүчене табарга.

2) Бүленүче 600, өлеш 30. Бүлүче ничәгә тигез?

271. Билгесез бүлүчене (x) табарга:

$2\,400 : x = 96$	$9\,568 : x = 46$	$25\,200 : x = 24$
$1\,024 : x = 64$	$8\,235 : x = 27$	$73\,800 : x = 36$
$2\,033 : x = 19$	$23\,040 : x = 256$	$6\,030 : x = 15$

Бүлүнең дөреслеген бүлү белән тикшерергә мөмкин. Моның өчен бүленүчене өлешкә бүләләр. Әгәр гамәл дөрес эшләнгән булса, нәтиҗәдә бүлүче килеп чыгарга тиеш.

272. Бүләргә һәм ике юл белән (тапкырлау һәм бүлү юлы белән) дөреслеген тикшерергә.

804 : 4	8 040 : 20	15 300 : 75	190 400 : 340
609 : 3	10 050 : 25	13 056 : 32	187 960 : 370

273. Мамык җыю вакытында пионерлар юлда машиналардан коелып калган 129 *кг* һәм басудан 477 *кг* мамык җыйдылар. 1 *кг* мамыктан 20 *м* ситсы, ә 3 *м* ситсыдан бер күлмәк чыга. Пионерлар җыйган мамыктан тукылган ситсыдан ничә күлмәк тегеп була?

274. Пароход 684 *км* юл узган. Бу юлның өчтән бер өлешен ул сәгатькә 19 *км* тизлек белән, ә калган юлны сәгатькә 24 *км* тизлек белән барган. Әгәр тукталышларга барысы 14 сәгать вакыт киткән булса, пароход барлык юлны ничә сәгатьтә узган?

275. Пароходның күпме вакыт сәгатькә 19 *км* тизлек белән, күпме вакыт сәгатькә 24 *км* тизлек белән баруы билгеле булган мәсьәлә төзергә, аның күпме юл узганын белергә.

276. (Телдән.) 1) 25 чыксын өчен, 200 не нинди санга бүләргә кирәк? 40 чыксын өчен 400 не? 70 чыксын өчен 560 ны? 840 чыксын өчен 840 ны?

2) 15 чыксын өчен, нинди санны 20 гә бүләргә кирәк? 30 чыксын өчен, нинди санны 12 гә? 100 чыксын өчен, нинди санны 10 га? 1 чыксын өчен, нинди санны 50 гә?

277. 1) Бүленүче 140, өлеш 20. Бүлүче күпмегә тигез?

2) Бүлүче 25, өлеш 25. Бүленүчене табарга.

278. x ны табарга:

Бүленүче	Бүлүче	Өлеш
904 678	226	x
410 040	x	68
810 540	x	27
x	5 040	360
x	705	4 080

279.

$6\,408 : x = 8$	$x : 709 = 709$	$x \times 58 = 4\,350$
$7\,236 : x = 36$	$x : 320 = 470$	$x \times 24 = 4\,848$

280. Балалар аквариумдагы балыкны күзәттеләр һәм һәр 15 көн саен аның авырлыгын яза бардылар:

15 октябрь	25 *г*	30 октябрь	40 *г*
15 ноябрь	75 *г*	30 ноябрь	120 *г*
15 декабрь	175 *г*	30 декабрь	240 *г*

Һәр 15 көн саен балыкның авырлыгы күпмегә арта барган? Һәр ай саен балыкның авырлыгы ничә тапкыр арткан (30 нчы числолардагы авырлыкны чагыштырырга)?

281. Көньяк өлкәләрдәге совхозлардан Москвага, Ленинградка һәм башка шәһәрләргә 2124 *т* фрукт җибәрелгән; аларның өчтән бер өлеше персик; груша, персикка караганда, 4 тапкыр кимрәк; калганнары мандарин. Ничә тонна мандарин җибәрелгән?

---

282. 56, 64, 78, 90, 96, 120, 140, 160 саннары эченнән: 1) 8 гә калдыксыз бүленә торганнарын, 2) 8 гә калдыклы бүленә торганнарын күчереп алырга.

283. (Телдән.) 1) 28 сумга 3 әр сумлык китапны күбендә ничә данә алып була?

2) Әгәр 46 урындыкны бертигез итеп 8 бүлмәгә куйсаң, һәр бүлмәгә күбендә ничәшәр урындык куеп була? Ничә урындык кала?

284. Бүләргә һәм бүлүчене, өлешне һәм калдыкны белеп, бүленүчене ничек табарга икәнен язарга.

Мәсәлән: $59 : 6 = 9$ (калдык 5)

$$59 = 6 \times 9 + 5$$

74 : 8	39 : 5	65 : 4	78 : 15	60 : 14
58 : 4	46 : 7	89 : 8	94 : 18	86 : 17
55 : 9	78 : 6	64 : 12	141 : 2	806 : 8
68 : 7	92 : 8	82 : 16	402 : 4	692 : 3

Калдыклы бүлүдә бүленүче бүлүче белән өлеш тапкырчыгышына калдыкны кушкач чыккан санга тигез.

Шуңа күрә, калдыклы бүлүнең дөреслеген тикшерү өчен, бүлүчене өлешкә тапкырлыйлар һәм килеп чыккан тапкырчыгышка калдыкны кушалар. Әгәр гамәл дөрес эшләнгән булса, бүленүче килеп чыгарга тиеш.

285. Бүленүчене табарга, әгәр:

1) бүлүче 76, өлеш 24, калдык 15 булса;

2) бүлүче 54, өлеш 38, калдык 36 булса.

286. Бүленүчене табарга, әгәр:

1) бүлүче 25, өлеш 8, калдык 12 булса;

2) бүлүче 75, өлеш 6, калдык 16 булса.

Бирелгән санны 3 кә бүлгәндә, калдыкта нинди саннар булуы мөмкин? 5 кә бүлгәндә? 8 гә бүлгәндә? 13 кә бүлгәндә?

287. Өлешне һәм калдыкны табарга:

5 615 : 922	32 678 : 468	74 514 : 328
5 615 : 958	12 806 : 249	91 450 : 643
5 615 : 976	45 054 : 530	86 819 : 478

Соңгы багана мисалларын чишүнең дөреслеген тикшерергә.

288. x ны табарга:

Бүленүче	Бүлүче	Өлеш	Калдык
x	36	708	35
x	54	325	49
x	256	34	209
x	194	68	185

289 Мисалларны чишәргә һәм дөреслеген тикшерергә:

263 200 : 470	801 000 : 890	314 280 : 970
182 400 : 286	518 806 : 683	361 425 : 516

290. Ике колхозчы бер елда 806 хезмәт көне эшләгәннәр. Беренчесе, продуктлардан тыш, 3 088 сум, икенчесе 3 360 сум акча алган. Һәр колхозчы ничә хезмәт көне эшләгән?

291. Бер басудан 4 420 *ц*, икенче басудан 3 380 *ц* кукуруза бөртеге җыеп алганнар. Беренче басуның мәйданы икенчесеннән 20 *га* га артыграк. Әгәр уңыш бердәй булса, һәр басуда ничә гектар җиргә кукуруза чәчелгән?

292. Башта өлештә ничә цифра чыгачагын әйтеп, мисалларны язма рәвештә чишәргә:

1) 521 : 2	646 : 8	742 : 36	35 864 : 326
521 : 4	812 : 9	985 : 48	21 038 : 175

2)	841 : 4	919 : 9	650 . 21	27 726 : 138
	841 : 8	514 : 5	850 : 28	59 040 : 164

293. Бүләргә һәм дөреслеген тикшерергә:

762 : 4	6 842 : 3	9 027 : 45	759 120 : 253
967 : 8	9 965 : 6	3 618 : 16	984 245 : 328

294. (Телдән.) 1) Москвадан Калининградка кадәр 1300 *км*. Бу — Москвадан Ленинградка кадәрге арадан ике тапкыр артыграк. Москвадан Ленинградка кадәрге ераклыкны исәпләп чыгарырга.

2) Совхоз рекордчы сыердан елга 12 000 *кг* сөт алды; бу башка сыерлардан алынган уртача савымнан 4 тапкыр артыграк. Башка сыерлардан алынган уртача савымны исәпләргә.

3) Шкаф 330 сум тора, диван, шкафка караганда, 30 сумга, ә вешалка, диванга караганда, 30 тапкыр арзанрак. Вешалка күпме тора?

4) Самолётның сәгатьлек тизлеге 300 *км*, поездныкы 6 тапкыр кимрәк, ә велосипедистның тизлеге, поезд тизлегенә караганда, 35 *км* га кимрәк. Велосипедистның тизлеген табарга.

295. Бер отрядта 23 пионер спорт ярышларында 391 очко җыйдылар. Икенче отрядта 28 пионер 420 очко, ә өченче отрядта 36 пионер 648 очко җыйдылар. Кайсы отряд җиңүче булып чыкты?

296. Автозаводта бер автомобильгә 2 370 *кг* металл тоттылар. Берникадәр вакыттан соң бер автомобильгә 2 106 *кг* металл тота башладылар һәм бу норма буенча 101 000 автомобиль эшләп чыгардылар. Экономия ясалган металлдан планнан тыш автомобильләр ясадылар. Әгәр һәр автомобильгә тик 2 020 *кг* гына металл тотсалар, планнан тыш ничә автомобиль эшләп чыгарганнар?

297. 1) Бирелгән санны берничә тигез кисәккә бүлү; 2) санны берничә тапкыр киметү; 3) бер санның икенчесе эчендә ничә тапкыр бар икәнен белү; 4) бер санның икенчесеннән ничә тапкыр зуррак яки кимрәк икәнен белү соралган простой мәсьәләләр төзегез.

Бу мәсьәләләрнең барысы да нинди гамәл белән чишелә?

298. Түбәндәгечә чишелә торган мәсьәлә төзергә:

1) 168 *км* : 3 = 56 *км*
2) 42 *км* : 3 = 14 *км*
3) 56 *км* : 14 *км* = 4

Җавап. Поезд, велосипедистка караганда, 4 тапкыр тизрәк бара.

299. 1) Ничә килограмм алма сатып алынганлыгы һәм бер килограмм алманың күпме торганлыгы билгеле.

Бу бирелмәләр буенча нәрсә белергә мөмкин һәм нинди гамәл белән? Мәсьәлә төзергә һәм аны чишәргә.

2) Ничә килограмм алма сатып алганнары һәм барлык алма өчен күпме акча түләнгәне билгеле.

Бу бирелмәләр буенча нәрсә белергә мөмкин һәм нинди гамәл белән? Мәсьәлә төзергә һәм чишәргә.

3) Поездның нинди ераклыкны узганы һәм аның сәгатьлек тизлеге билгеле. Бу бирелмәләр буенча нәрсә белергә мөмкин һәм нинди гамәл белән? Мәсьәлә төзергә һәм аны чишәргә.

300. 1)

6 183 : 74	640 096 : 32	307 900 : 4 800
5 464 : 26	736 200 : 18	127 410 : 274
9 112 : 13	195 894 : 100	1 056 100 : 132

2)

$742 : x = 742$	$x : 25 = 25$	$789 : 789 =$
$658 : x = 658$	$x : 11 = 11$	$805 : 805 =$

301. Өлеш бүленүчегә тигез була аламы? бүлүчегә? берәмлеккә? Мисаллар китерергә.

Арифметик гамәлләрне үтәү тәртибе. Җәяләр.

Арифметикада дүрт гамәл өйрәнелә: кушу, алу, тапкырлау һәм бүлү.

Кушу һәм алу беренче баскыч гамәлләр дип аталалар. Тапкырлау һәм бүлү икенче баскыч гамәлләр дип аталалар.

Бер үк баскыч гамәлләр, ничек язылган булсалар, шул тәртиптә үтәләләр (сулдан уңга таба).

Әгәр мисалда төрле баскыч гамәлләр күрсәтелгән булса, ул вакытта башта икенче баскыч гамәлләр (тапкырлау һәм бүлү), ә аннан соң беренче баскыч гамәлләр (кушу һәм алу) үтәләләр.

Әгәр мисалда җәяләр бирелгән булса, башта җәяләр эчендәге гамәлләр үтәлә.

302. Түбәндәге һәр мәсьәләнең чишелешен, нинди гамәлләр һәм аларны нинди тәртиптә үтәргә икәнен күрсәтеп, санлы формула белән язарга:

1) Бер отрядта 42 пионер, икенчесендә, беренчегә караганда, 8 гә кимрәк, ә өченче отрядта, икенчегә караганда, 4 кә артыграк. Өченче отрядта ничә пионер?

2) Бер эшче 8 сәгатьтә 96 деталь, ә икенче эшче 6 сәгатьтә 108 деталь эшләгән. Икенче эшче сәгатькә ничә деталь артыграк эшләгән?

3) 3 ташчы 8 сәгатьтә 7 200 кирпеч салдылар. Бер эшче бер сәгатьтә ничә кирпеч салган?

4) 20 сарыктан бер елда 100 *кг* йон кырыктылар. Шундый 400 сарыктан елга ничә килограмм йон кыркып булыр?

5) Поезд 3 сәгать буена сәгатькә 50 *км* тизлек белән, 4 сәгать буена сәгатькә 52 *км* тизлек белән һәм 2 сәгать буена сәгатькә 48 *км* тизлек белән барды. Поезд нинди ераклыктагы араны узды?

6) Складта 180 *ц* бәрәңге булган. Складка тагы 120 *ц* бәрәңге китергәннәр. Барлык бәрәңгене бертигез итеп, 10 магазинга җибәргәннәр. Һәр магазинга ничә центнер бәрәңге җибәргәннәр?

7) Китапханә укучыларга беренче айда 600 китап, икенче айда 800 китап һәм өченче айда 1 000 китап җибәргән. Китапханә уртача бер айга ничә китап җибәргән?

303. Кирәк урында җәяләр куеп, түбәндәге гамәлләрне язарга һәм чишәргә:

1) 1 803 һәм 3 448 санннарының суммасын 3 тапкыр зурайтырга.

2) 21 004 һәм 907 саннарының аермасын 7 тапкыр киметергә.

3) 308 һәм 509 саннарының тапкырчыгышын 840 ны 30 га бүлүдән килеп чыккан өлешкә бүләргә.

4) 1 840 920 не 23 кә бүлүдән килеп чыккан өлешне 1 090 һәм 100 саннарының тапкырчыгышы кадәр зурайтырга.

304. $802 \times 406 - 900\,072 : 18 + 68\,392$

$53\,200 \cdot 7\,600 + 4\,070 \times 3\,600 - 82\,008$

$589\,000 + 500 \times 380 - 191\,580 : 93$

$100\,000 - 136\,068 : 68 + 4\,600 \times 900$

305. $1\,000\,000 - 129\,000 : 129 + 19\,140 : 132$

$304\,080 + 240 \times 108 - 7\,800\,52) : 520$

$(10\,200 - 9\,891) \times (70\,204 - 69\,874) : 206$

306.

$7\,012 : 14$	$4\,300 \times x = 8\,600$	$x \times 46 = 1\,840$
$6\,975 : 17$	$2\,800 : x = 280$	$x : 108 = 1\,040$

Кабатлау өчен сораулар.

1) Ике яки берничә санның тапкырчыгышы нинди гамәл белән табыла?

2) Тапкырлаганда саннар ничек атала?

3) Тапкырлауның урын алмаштыру үзлеге нәрсәдән тора?

4) Билгесез тапкырлашучыны ничек табарга?

5) Тапкырлауның дөреслеген ничек тикшерергә?

6) Бирелгән тапкырчыгыш һәм бер тапкырлашучы буенча икенче тапкырлашучы нинди гамәл белән табыла?

7) Бүлгәндә саннар ничек аталалар?

8) Билгесез бүленүчене ничек табарга? Билгесез бүлүчене?

9) Калдыклы бүлү очрагында бүленүчене ничек табарга?

10) Калдыкта нинди саннар килеп чыгарга мөмкин, мәсәлән, бүлүче 7 гә тигез булса?

11) Калдыксыз бүлүнең дөреслеген ничек тикшерергә? Калдыклы бүлүнең?

12) Бер генә баскыч гамәлләре кергән мисалларда арифметик гамәлләр нинди тәртиптә үтәлә? Төрле баскыч гамәлләре кергән мисалда? Җәяләр кергән мисалда?

Һәр җавапны мисаллар белән аңлатырга.

Барлык гамәлләргә мисаллар һәм мәсьәләләр.

307. (Телдән.)

$(1\,000 - 24 \times 8 + 192) : 100$

$(340 + 80 - 360 - 50) \times 100 - 999$

$(24 \times 20 - 16 \times 30) \times 10 + 125$

$(25 \times 100 - 1\,400 - 200) : 900 - 1$

$3\,500 : 5 - 700 + 12 \times 100 - 600$

$5 \times 5 \times 5 \times 5 + 625 - 1 \times 250 : 5$

$3\,500 : 5 + 700 + 12 \times 100 - 1\,300$

$10 \times 15 \times 5 : 25 : 10 + 9\,997$

308. 1) $136\,785 + 285\,001 - 89\,670 + 67\,058$
$380\,010 - (101\,020 - 79\,048) + (800\,100 - 80\,010)$
$(301\,204 - 300\,294) \times (131\,012 - 130\,121) : 130$
$(883\,685 + 796\,875) : (90\,011 - 89\,451) \times 102$

2) $308 \times 712 : 616 + 360 \times 804 : 540$
$918 \times 576 : 864 + 680 \times 4\,200 : 510$
$278\,002 - 520 \times 708 : 390 + 407 \times 320$
$180\,400 + 756 \times 504 : 378 - 9\,401\,880 : 470$

3) $3\,006\,100 - (50\,100 - 49\,896) \times (100\,004 - 99\,824)$
$(81\,140 - 80\,980) \times (40\,020 - 39\,814) : 824$
$380\,001 - (28\,765 + 30\,968 + 206\,810) + 256 \times 408 : 384$

4) $201\,040 - 168\,942) + 204 \times 3\,200 + 840\,560 : 280$
$3\,014\,016 : 752 + 278\,627 + 80 \times 705 + 7\,065$
$693\,840 : 1\,176 + 208 \times (50\,380 - 49\,672)$

309.

$x + 250 = 510$	$1\,482 + x = 2\,007$	$x \times 11 = 121$
$x + 360 = 720$	$1\,614 + x = 3\,010$	$x \times 15 = 225$
$x - 480 = 120$	$1\,250 - x = 578$	$x : 18 = 45$
$x - 530 = 470$	$3\,002 - x = 952$	$x : 26 = 78$

$1\,010 \times x = 812\,040$	$5\,202 : x = 17$
$3\,080 \times x = 708\,400$	$9\,760 : x = 16$

Телдән исәпләү өчен мәсьәләләр.

310. Тузбаш елан 80 ел яши ала, ә ташбака аннан 10 тапкыр артыграк. Ташбака ничә ел яши ала.

311. Хәрәкәт итмәгәндә кешенең үпкәсе аша бер минутта 6 *л* һава үтә, ә йөзгәндә моннан 20 тапкыр артыграк. Йөзүченең үпкәсе аша ничә литрга артыграк һава үтә?

312. Зоопаркта филгә көн саен 24 *кг* кара икмәк, 3 *кг* ак икмәк, 16 *кг* кишер, 16 *кг* чөгендер, 50 *кг* печән, 16 чиләк су бирәләр. Филгә бер айга (30 көн) һәр төр продукт күпмешәр кирәк?

313. Тавык йомыркасы 60 *г*, тәвә кошы йомыркасы аннан 24 тапкыр авыррак. Тәвә кошы йомыркасы нинди авырлыкта килә?

314. Яшь натуралистлар тар ояда яшәгән кроликның 2 айда 360 *г* га артуын, ә якты һәм киң ояда яшәүче кроликның 12

көндә 600 г га артуын күзәткәннәр. Икенче кроликның авырлыгы, беренчегә караганда, көнгә күпмегә артыграк арткан?

Күрсәтмә. Айда 30 көн дип санарга.

315. Бер тонна арыштан 600 *кг* крахмал алырга мөмкин, бу бер тонна бәрәңгедән алынганга караганда 4 тапкыр артыграк. Бер тонна бәрәңгедән күпме крахмал алып була?

316. Бер самолёт 2 сәгать, икенчесе 5 сәгать очкан. Икенче самолёт, беренчегә караганда, 960 *км* артыграк араны очкан. Әгәр алар бердәй тизлек белән очкан булсалар, һәр самолёт күпме араны очкан?

317. Беренче самолётта бензин тутырылган 4 бак, икенче самолётта 6 бак булган. Беренче самолётта, икенчесендәгегә караганда, 70 *кг* бензин кимрәк булган. Һәр самолётта ничә килограмм бензин булган?

318. Бер кисәктә 8 *м*, икенчесендә 12 *м* ефәк бар. Ике кисәк бергә 1 600 сум тора. Һәр кисәк күпме тора?

319. Ике кисәктә 20 *м* полотно бар. Беренче кисәк 180 сум, икенчесе 120 сум тора. Һәр кисәктә ничә метр полотно бар?

320. Колхоз хуҗалыгында 1 000 тавык, 1 000 каз һәм 500 үрдәк булган. Бер елга тавыкка 36 *кг*, казга 48 *кг*, үрдәккә 60 *кг* бөртекле ашлык кирәк. 1 айга барлык кошларга ничә килограмм ашлык кирәк?

321. Печәнне кул белән чабып-җыйганда бер районга 8 000 кеше, атлы чапкычлар белән җыйганда 4 тапкыр кимрәк кеше кирәк иде. Тракторлы машиналар керткәч, кешеләр саны тагы 10 тапкыр кимеде. Машиналар эшләү аркасында ничә кеше бушады?

322. Эшче 40 деталь эшләргә задание алды, шуның белән бергә аңа бер детальне хәзерләү өчен 18 минут, ә эшкәртү өчен 12 минут вакыт бирелгән иде. Ләкин эшче бер детальне хәзерләү һәм эшкәртү өчен барысы 20 минут кына вакыт тотты. 40 детальне эшләгәндә экономия ясалган вакыт эчендә эшче заданиедән тыш ничә деталь эшли алган?

323. 4 әйберне эшләү өчен план буенча 136 сәгать вакыт билгеләнгән; ләкин эшче бу эшне 6 сменада үтәгән. Һәр әйберне эшләгәндә эшче ничә сәгать вакытка экономия ясаган?

Белешмә. Сменада 8 эш сәгате.

324. Бер звено 5 *га* дан 300 *ц*, икенче звено 8 *га* дан 400 *ц* кукуруза бөртеге алды. Беренче звено 1 *га* дан ничә центнер артыграк уңыш алган?

325. Туристлар тау битләре буйлап тауның түбәсенә күтәреләләр. 1 200 *м* биеклектә яфраклы урманнар бетеп, ылыслы урманнар башландылар. Тагы 800 *м* күтәрелгәч, туристлар тау болыннары киңлегенә чыктылар. Тагы 1 100 *м* күтәрелеп, алар кар һәм бозлар эчендә калдылар. Болыннар тау итәгеннән нинди биеклектә? Кар һәм бозлар?

326. Элек МТСта 80 трактор булган; аларның биштән берсе чылбыр тәгәрмәчле тракторлар. Хәзер бу МТСта 108 трактор, аларның өчтән бере чылбыр тәгәрмәчле. МТСта чылбыр тәгәрмәчле тракторлар саны күпмегә арткан?

327. Яшь натуралистлар түгәрәгендә һәм „Булдыклы куллар" түгәрәгендә барлыгы 60 бала эшли. Яшь натуралистлар түгәрәгенә тагы 4 кеше язылгач, һәр ике түгәрәктә балалар саны бертигез булды. Башта һәр түгәрәктә ничә бала булган? Чишелешнең дөреслеген тикшерергә.

328. Ике класста 86 укучы булган. Бер класстагы 2 укучы икенче мәктәпкә күчкәч, укучылар саны һәр класста бертигез булып калган. Башта һәр класста ничә укучы булган? Чишелешнең дөреслеген тикшерергә.

Язма чишү өчен мәсьәләләр.

329. Яхшы итеп карау нәтиҗәсендә паровоз, капиталь ремонт ясамыйча, 132 642 *км* юл узган, бу — норма белән каралганнан 57 000 *км* га артыграк. Паровоз, капиталь ремонт ясамыйча, ничә километр юл үтәргә тиеш?

330. Бакчада 586 алмагач бар; бу — груша агачларына караганда 138 төпкә артыграк, чия агачларына караганда 95 төпкә кимрәк. Бакчада барысы ничә төп агач бар?

331. Пассажир самолётының тизлеге сәгатькә 325 *км*. Бу пароход тизлегеннән 13 тапкыр артыграк һәм реактив самолёт тизлегеннән 3 тапкыр кимрәк. Пароходның һәм реактив самолётның тизлекләрен табарга.

332. Бер колхозда 720 баш мөгезле эре терлек, мөгезле эре терлеккә караганда 125 башка артыграк сарык, сарыкка караганда 525 башка кимрәк дуңгыз, дуңгыздан 190 башка кимрәк ат, башка барлык терлекләргә караганда 1 015 кә артыграк кошлар бар. Бу колхозда ничә кош булган? Мәсьәләнең шартларын кыскача язарга.

333. Балалар йорты өчен 96 *м* сатин һәм 70 *м* полотно сатып алдылар. 1 *м* сатин 12 сум, ә 4 *м* полотно 5 *м* сатин бәясе кадәр тора. Сатып алынган барлык әйбер күпме тора?

334. Беренче басуда 48 *га*, икенче басуда 80 *га* мәйданга шикәр чөгендере чәчелде. Беренче басуда һәр гектардан уртача 500 *ц*, ә икенче басуның 4 гектарыннан беренче басуның 3 гектарыннан алынган кадәр чөгендер уңышы алынды. 1 *ц* чөгендердән 16 *кг* шикәр чыга. Барлык чөгендердән күпме шикәр алыныр?

335. Бер колхозда соңгы 15 ел эчендә бер гектардан алынган акчалата доход 435 сумнан 2 295 сумга кадәр, ә чәчү мәйданы 730 *га* дан 1 000 *га* га кадәр арткан. Бу колхозда доход ел саен уртача күпмегә арткан?

336. Самолёт 9 сәгать очкан. Беренче 4 сәгатьтә ул сәгатькә 320 *км* тизлек белән, ә калган вакытта сәгатькә 347 *км* тизлек белән очкан. Барлык араны самолёт нинди уртача тизлек белән очкан?

337. Һәр сыерга 50 *л*, һәр атка 60 *л*, сарыкка 8 *л* исәбеннән, колхозга сыерлар, атлар һәм сарыклар сугару өчен тәүлеккә 22 580 *л* су кирәк. Әгәр сыерлар 250 баш, атлар 48 баш булса, колхозда барысы ничә сарык булган?

338. Колхозда ничә сыер, ничә ат һәм сарык бар һәм бер сыерга, бер атка, бер сарыкка ничә литр су кирәклеге билгеле булып, бер тәүлеккә барысы күпме су киткәнлеген белү соралган мәсьәлә төзергә.

339. Тракторист 17 *га* җир сөргән һәм 323 *кг* керосин бетергән. Икенче трактор белән ул 234 *га* җир сөргән һәм 2 574 *кг* нефть бетергән. Кайсы тракторда ягулык кимрәк тотыла (1 *га* га)? Әгәр 1 *кг* керосин 45 тиен, ә 1 *кг* нефть 30 тиен торса, нефть белән эшләгәндә, тракторист 1 *га* га күпме акчага экономия ясый?

340. Бер өлкәдә урман хуҗалыклары 10 көн эчендә 3 000 *га* җиргә урман утыртырга йөкләмә алганнар. Беренче 3 көндә көнгә 380 шәр гектарга, ә калган көннәрне һәрберсендә 85 *га* га артыграк мәйданга урман утыртканнар. Йөкләмәне срогыннан ничә көн әлегрәк үтәгәннәр?

341. Новатор-машинистлар 30 поездда нормадан тыш 6 417 *т* йөк китерделәр, алардан 13 поездда 192 шәр тонна һәм 9 поездда 225 әр тонна. Калган поездларның һәрберсендә нормадан тыш уртача ничәшәр тонна йөк китерелгән?

342. Бер кисәк материя 1 200 сум, шундый ук материянең икенче кисәге 400 сумга артыграк тора. Беренче көнне 1 800 сумлык, ә икенче көнне калган 25 *м* материяне саттылар. Беренче көнне, икенче көнгә караганда, ничә метр материя артыграк саттылар? Чишелешнең дөреслеген тикшерергә.

343. Бер амбарда 3 000 *кг*, икенчесендә 2 100 *кг* бөртекле ашлык бар. Чәчүнең беренче көнендә амбарлардан 3 450 *кг*, икенче көнендә 22 капчыкка тутырылган калган ашлыкны алдылар. Әгәр ашлыклы капчыклар бертигез авырлыкта булсалар, беренче көнне, икенчегә караганда, ничә капчык артыграк ашлык алганнар? Чишелешнең дөреслеген тикшерергә.

344. Кече һәм өлкән яшьтәге 104 пионер колхозга урып-җыю эшендә булыштылар. Аларга тагы кече яшьтәге 8 пионер килеп кушылгач, теге һәм бу яшьтәге пионерлар саны бертигез булды. Өлкән яшьтәгеләр 7 шәр кеше, ә кече яшьтәгеләр 8 әр кеше булып, барлык пионерлар бригадаларга бүленделәр. Ничә бригада булган?

345. 1) 160 раманы буярга кирәк. Бер маляр көнгә 11 рама, икенчесе 9 рама буйый. Икесе бергә эшләп, алар бу рамаларны ничә көндә буярлар?

2) 150 раманы буярга кирәк. Бер маляр бу эшне 15 көндә, икенчесе 10 көндә үти ала. Әгәр бергә эшләсәләр, ике маляр шул эшне ничә көндә бетерер?

346. 1 440 деталь хәзерләргә кирәк. Бер эшче үзе генә бу эшне 20 сәгатьтә, икенчесе 30 сәгатьтә эшләп бетерә ала. Әгәр бергә эшләсәләр, ике эшче бу эшне ничә сәгатьтә эшләп бетерерләр?

347. 1) Түбәндә күрсәтелгән масштаб буенча *А* шәһәреннән *Б* шәһәренә кадәрге араның ераклыгын табарга.



9 нче рәсем.

2) *А* шәһәреннән *Б* шәһәренә кадәрге араның ераклыгы 500 *км*. Югарыда күрсәтелгән масштаб ярдәмендә бу ераклыкны туры сызык кисемтәсе рәвешендә сызып күрсәтегез.

348. Масштабтан файдаланып, карта буенча Москвадан Ленинградка, Архангельскига, Минскига, Киевка кадәр араның ераклыгын табыгыз.

349. Укучылар музейга экскурсиягә киттеләр. Мәктәптән чыккач, алар көнбатышка борылдылар һәм тыкрык буйлап 200 *м* бардылар. Бередә алар зур урамга чыктылар һәм, трамвайга утырып, 500 *м* төньяк юнәлешкә бардылар. Трамвайдан төшкәч, алар тагы көнбатышка борылдылар һәм, 100 *м* юл узгач, музейга җиттеләр.

1 *см* да 100 *м* масштабы белән укучыларның узган юлын сызымда күрсәтегез.

Мәсьәләләр.[1]

350. Балалар бакчасы өчен 12 лимон сатып алдылар, шуның белән бергә һәр 3 лимон өчен 5 әр сум түләделәр. Барлык лимоннар күпме тора?



10 нчы рәсем.

351. 36 укучы яшелчә бакчасында эшлиләр. Укытучы һәр өч укучыга берәр китмән һәм икешәр көрәк бирде. Укучыларга ничә китмән һәм ничә көрәк бирелгән?

352. 10 *м* материядән 3 күлмәк тегеп була. 30 *м* материядән ничә күлмәк тегеп булыр?

353. Автобуска 7 *км* юлга уртача 3 *л* бензин кирәк. 42 *л* бензин автобуска ничә километр юл узарга җитәр?

354. 20 *кг* бәрәңгедән 3 *кг* крахмал чыга. 100 *кг* бәрәңгедән күпме крахмал чыгар?

355. 50 *кг* ташкүмер 90 *кг* торф биргән кадәр җылы бирә. 300 *кг* күмер биргән җылыны алу өчен ничә килограмм торф кирәк булыр?

[1] 350 дән 368 гә кадәрге мәсьәләләр чагыштырмалар юлы белән чишеләләр.

356. „Булдыклы куллар“ түгәрәгендә 15 бала шөгыльләнә. Һәр биш балага берәр пычкы, 2 шәр чүкеч, 3 әр пәке, 4 әр линейка бирделәр. Барлык балаларга һәр инструмент ничәшәр бирелгән?

357. Мәктәптә 160 укучы бар. Һәр 40 укучыга 20 көрәк. 10 тырма, 5 лейка һәм 25 данә башка инструментлар туры килә. Мәктәптә ничә көрәк, тырма, лейка һәм башка инструментлар бар?

358. Икмәк пешергәндә 100 *кг* оннан 40 *кг* артым чыга. Пекарня көнгә 1 *т* он тота. Бу оннан пекарня ничә килограмм артым алыр?

Күрсәтмә. 1 *т* ны килограммнар белән алмаштырырга.

359. Һәр 400 *л* савылган сөт өчен савучыга 6 хезмәт көне язалар. Елга 28 000 *л* сөт сауган савучыга ничә хезмәт көне язарлар?

360. Рекордчы сыер бер елга 16 200 *л* сөт бирде. Һәр 100 *л* сөттән 4 *кг* май алып була. Бу сыер биргән барлык сөттән күпме май алып булыр?

361. Бер малай 320 адым ясады. Аның һәр 16 адымы 10 *м* га тигез. Бу малай нинди ераклыктагы араны узган?

362. Завод 8 айда 73 640 *т* ташкүмер тотты. 10 *т* нефть 14 *т* ташкүмер биргән җылыны бирсә, ташкүмерне нефть белән алмаштырганда, бу заводка бер елга күпме нефть кирәк булыр?

363. Бер автомобиль 460 *км*, икенчесе 574 *км* юл үтте. Беренче автомобиль һәр 4 *км* га 450 *г*, ә икенчесе һәр 7 *км* га 820 *г* бензин тота. Автомобильләрнең кайсы күбрәк ягулык бетергән һәм күпмегә артык?

364. Колхозда 540 сарык бар, аларның һәрберсе елга 4 *кг* йон бирде. 2 *кг* йоннан 3 *м* сукно чыга, ә 2 *м* сукнодан бер балалар пальтосы тегеп була. Бу йоннан әзерләнгән сукнодан ничә данә балалар пальтосы тегеп булыр?

365. Совхозда 108 баш савым сыер бар иде, аларның һәрберсе тәүлеккә уртача 17 *л* сөт бирә, ә 20 *л* сөттән 900 *г* атланмай чыга. Колхоздагы барлык сыерлардан бер ел эчендә алынган сөттән ничә килограмм атланмай хәзерләп булыр?

Белешмә. Бер елда сыерларны 300 көн саудылар.

366. Түбәндәге шарт буенча мәсьәлә төзергә һәм чишәргә:

13 *м* — 3 күлмәк

52 *м* — x күлмәк

367. Түбәндәгечә чишелә торган мәсьәлә төзергә:

1) 12 сәг. : 3 сәг. = 4
2) 100 *км* × 4 = 400 *км*

Җавап. 12 сәгатьтә поезд 400 *км* юл уза.

368. 1) 74 984 саны 364 тән ничә тапкыр зуррак булса, 308 дән шулкадәр тапкыр зуррак булган сан табарга.

2) 508 саны 4 572 дән ничә тапкыр кимрәк булса, 360 018 дән шулкадәр тапкыр кимрәк булган сан табарга.

3) 48 саны 9 840 тан ничә тапкыр кимрәк булса, 4 050 дән шулкадәр тапкыр зуррак булган сан табарга.

Исемле саннар.

Простой һәм төзелмә исемле сан. Ваклау һәм эреләү.

369. Кисемтәне сантиметрларга бүленгән линейка белән үлчәгәндә, кисемтәнең башы линейкадагы „0“ тамгасына, ә азагы „11“ тамгасына туры килгән. Кисемтәнең озынлыгы ничә сантиметрга тигез?

370. 1) Кисемтәләрне үлчәргә һәм беренче кисемтәнең озынлыгын сантиметрлар белән, ә икенче кисемтәнең озынлыгын сантиметрлар һәм миллиметрлар белән аңлатырга (11 нче рәсем).



11 нче рәсем.

2) Өстәлнең озынлыгын сантиметрлар белән, ә соңыннан дециметр һәм сантиметрлар белән үлчәргә.

3) Дәфтәрнең буен һәм иңен сантиметрлар белән, ә соңыннан сантиметр һәм миллиметрлар белән үлчәргә.

4) Дәфтәрләр өемен, IV класс өчен дәреслекләр наборын үлчәргә һәм аларның авырлыкларын граммнар белән, килограмм һәм граммнар белән аңлатырга.

5) Югарыда килеп чыккан саннарның, янында бер генә үлчәүлекнең исеме торганнары астына бер сызык, ике үлчәүлекнең исеме торганнары астына ике сызык сызыгыз.

Килеп чыккан саннар — исемле саннар.

Исемле сан дип, янында үлчәүлек исеме торган санны атыйлар.

Исемле саннар простой һәм төзелмә булалар.

Простой исемле сан дип, бер исемдәге берәмлекләрдән торган сан атала.

Мәсәлән: 5 *м*; 12 *кг*.

Төзелмә исемле сан дип, берничә исемдәге берәмлекләрдән торган сан атала.

Мәсәлән: 4 сум 50 тиен; 8 *кг* 200 *г*; 10 *м* 9 *дм*.

371. Түбәндәге саннарны укып чыгарга һәм алар арасыннан простой исемле саннарны бер баганага һәм төзелмә исемле саннарны икенче баганага күчереп алырга:

6 сум; 8 сум 70 тиен; 15 *м*; 15 *м* 63 *см*; 3 *дм* 8 *мм*; 6 *кг*; 10 *кг* 500 *г*; 85 *ц*; 7 *ц* 80 *кг*; 14 *т*; 14 *т* 906 *кг*; 20 *км* 800 *м*; 1 600 сум 75 тиен; 25 *км* 608 *м*; 9 *кг* 90 *г*.

372. 1) Озынлыкны аңлатучы 3 простой исемле сан һәм авырлыкны аңлатучы 3 простой исемле сан әйтергә.

2) Озынлыкны аңлатучы 3 төзелмә исемле сан һәм авырлыкны анлатучы 3 төзелмә исемле сан әйтергә.

373. Бер үк зурлыкны аңлатучы саннарны парлап язып чыгарга.

Мәсәлән: 6 *м* = 600 *см*.

8 *м*; 5 сум 70 тиен; 800 *см*; 570 тиен; 6 *ц*; 9 *км* 500 *м*; 2 *кг*; 600 *кг*; 9 500 *м*; 2 000 *г*.

Бер үк зурлык ваграк үлчәүлекләр белән дә һәм эрерәк үлчәүлекләр белән дә аңлатыла ала.

Исемле санны ваграк үлчәүлекләр белән аңлату ваклау дип атала.

Исемле санны эрерәк үлчәүлекләр белән аңлату эреләү дип атала.

374. Вакларга:

1) тиеннәргә:

10 сум	6 сум 58 тиен	8 сум 6 тиен
40 сум	10 сум 70 тиен	40 сум 5 тиен
86 сум	32 сум 68 тиен	80 сум 10 тиен

2) сантиметрларга:

6 *м* 75 *см*	4 *м* 8 *см*	28 *м* 65 *см*	9 *дм* 6 *см*
10 *м* 20 *см*	50 *м* 6 *см*	35 *м* 70 *см*	8 *дм* 7 *см*

3) метрларга:

5 *км* 496 *м*	15 *км* 458 *м*	3 *км* 30 *м*	7 *км* 5 *м*
2 *км* 365 *м*	28 *км* 600 *м*	8 *км* 60 *м*	2 *км* 9 *м*

4) килограммнарга:

6 *ц* 58 *кг*	5 *ц* 8 *кг*	12 *т* 396 *кг*	8 *т* 6 *кг*
9 *ц* 60 *кг*	9 *ц* 5 *кг*	15 *т* 720 *кг*	2 *т* 54 *кг*

5) граммнарга:

6 *кг* 556 *г*	48 *кг* 575 *г*	4 *кг* 5 *г*	1 *кг* 100 *г*
7 *кг* 900 *г*	24 *кг* 700 *г*	2 *кг* 56 *г*	1 *кг* 110 *г*

375. Түбәндәге төзелмә исемле саннарны простой исемле саннар белән аңлатырга:

20 сум 18 тиен	8 *см* 6 *мм*	5 *ц* 80 *кг*	12 *км* 94 *м*
265 сум 6 тиен	6 *см* 9 *мм*	8 *ц* 72 *кг*	12 *т* 15 *кг*
100 сум 70 тиен	4 *дм* 2 *мм*	6 *м* 6 *см*	15 *кг* 54 *г*

376. 300 тиендә ничә сум? 800 тиендә? 900 тиендә?
30 *ц* да ничә тонна? 80 *ц* да? 50 *ц* да? 90 *ц* да?
70 *дм* да ничә метр? 40 *дм* да? 80 *дм* да? 100 *дм* да?

377. Эреләргә:

1) сумнар һәм тиеннәргә:

643 тиен	1 875 тиен	1 360 тиен	7 503 тиен
972 тиен	2 640 тиен	1 002 тиен	8 006 тиен

2) метрлар һәм сантиметрларга:

802 *см*	63 *дм*	3 040 *мм*	9 640 *мм*
365 *см*	764 *дм*	2 050 *мм*	9 640 *см*
604 *см*	1 806 *дм*	5 006 *см*	9 640 *дм*

3) километр һәм метрларга:

7 640 *м*	9 030 *м*	3 008 *м*	15 030 *м*
7 385 *м*	4 500 *м*	5 046 *м*	30 608 *м*

4) килограммнарга һәм граммнарга:

9 040 *г*	6 035 *г*	5 800 *г*	27 534 *г*
7 836 *г*	2 006 *г*	1 030 *г*	368 700 *г*

5) тонналар һәм килограммнарга:

165 *ц*	408 *ц*	50 700 *кг*	10 006 *кг*
608 *ц*	1 264 *ц*	32 728 *кг*	21 004 *кг*

378. Түбәндәге простой исемле саннарны төзелмә исемле саннар белән аңлатырга.

Мәсәлән: 1 235 *см* = 12 *м* 35 *см*.

1 005 тиен	1 064 *см*	8 456 *м*	160 890 *кг*
2 307 тиен	2 607 *г*	9 703 *кг*	967 305 *г*
4 268 *см*	5 048 *м*	7 098 *г*	501 086 *м*

379. 1) Советлар Союзындагы иң биек тау — Сталин пигының биеклеге 7 *км* 495 *м*.

2) Төньяк Боз океанының иң зур тирәнлеге 4 *км* 975 *м*.

3) Кара диңгезнең иң зур тирәнлеге 2 *км* 245 *м*.

Бу төзелмә исемле саннарның һәрберсен метрлар белән аңлатырга.

380. Спортсменка дискны 55 *м* 68 *см* ераклыкка ыргытты (12 нче рәсем). Мондый нәтиҗәгә ул берничә ел буена тырышып күнегү аркасында ирешге. Беренче тапкыр дискны ул бары 28 *м* 67 *см* га гына ыргыткан иде, соңыннан нәтиҗәләр түбәндәгечә арта бардылар:

12 нче рәсем.

30 *м* 53 *см*	40 *м* 78 *см*
38 *м* 18 *см*	51 *м* 52 *см*
39 *м*	53 *м* 61 *см*
40 *м* 49 *см*	55 *м* 68 *см*

Төзелмә исемле саннарны простой исемле саннар белән алмаштырыгыз һәм һәр ыргытуның, алдагысына караганда, ничә сантиметрга еракрак булганын белегез.

381. 1) Казбек тавы 5 047 *м*, ә Эльбрус 5 633 *м*.

2) Беринг диңгезенең иң зур тирәнлеге 4 773 *м*, Охотск диңгезенең — 3 846 *м*, Япон диңгезенең—4 226 *м*, Кара диңгезнең — 2 245 *м*.

3) Парашют спорты мастеры парашютта 11 683 *м* биеклектән төште.

Бу исемле саннарның һәрберсен километр һәм метрларда аңлатырга.

382. Чабанга һәр 100 сарык өчен елга 12 хезмәт көне исәплиләр. Шуның өстенә, кыркылган һәр 10 *кг* йон өчен 2 хезмәт көне исәпләнә. Көтүдә 500 сарык бар, һәр сарыктан уртача 5 *кг* йон кырыкканнар. Чабанга ничә хезмәт көне исәпләгәннәр?

383. Савучы 10 сыерны карый. 6 сыердан ун көн саен 18 әр литр, ә калганнарыннан 14 әр литр сөт сава. Һәр 400 литр савылган сөт өчен аңа 6 хезмәт көне исәплиләр. 300 көнгә ул ничә хезмәт көне эшләгән?

Төзелмә исемле саннарны кушу

384. (Телдән.) 3 *м* һәм 8 *м* ны кушсан күпме була? 70 *кг* һәм 65 *кг* ны? 8 *кг* һәм 200 *г* ны? 10 *км* һәм 250 *м* ны? 5 сум 30 тиен һәм 40 тиенне? 2 *т* 200 *кг* һәм 3 *т* ны? 4 *м* 75 *см* һәм 25 *см* ны?

385.

$$\begin{array}{r} +\ 26\ м\ 58\ см \\ 13\ м\ 74\ см \\ \hline 40\ м\ 32\ см \end{array}$$

4 *м* 25 *см* + 3 *м* 40 *см*
8 *ц* 36 *кг* + 6 *ц* 50 *кг*
22 *м* 26 *см* + 64 *м* 56 *см*

48 *м* 75 *см* + 39 *м* 86 *см*
5 *км* 300 *м* + 7 *км* 450 *м*
8 *т* 540 *кг* + 4 *т* 650 *кг*

4 *кг* 658 *г* + 845 *г*
6 *т* 720 *кг* + 956 *кг*
26 *ц* 50 *кг* + 24 *ц* 68 *кг*

386. Счётта исәпләргә:

18 сум 37 тиен + 15 сум 42 тиен
23 сум 53 тиен + 40 сум 28 тиен
44 сум 17 тиен + 40 сум 83 тиен
185 сум 95 тиен + 14 сум 45 тиен
256 сум 62 тиен + 43 сум 17 тиен

387. Язып исәпләргә һәм дөреслеген счётка салып тикшерергә:

63 сум 52 тиен + 25 сум 36 тиен
27 сум 86 тиен + 40 сум 75 тиен
20 сум 82 тиен + 37 сум 18 тиен
36 сум 68 тиен + 78 сум 96 тиен

388. Москва метросы теземле рәвештә төзелә: беренче чиратта 11 *км* 600 *м* озынлыктагы юл, икенче чиратта, беренчегә караганда, 2 *км* 200 *м* га артыграк, өченче чиратта 13 *км* 100 *м* юл, дүртенче чиратта, өченче чираттагыга караганда, 10 *км* 300 *м* га озынрак юл төзелде, бишенче чиратта 11 *км* 900 *м* озынлыгында юл төзелә. Бишенче чират-

тагы юлны төзеп бетергәч, метроның барлык юллары нинди озынлыкта булыр? Чишелешне санлы формула белән язарга.

389. Кассадан башта 11 380 сум 96 тиен, аннан соң 32 705 сум 35 тиен акча җибәрделәр. Шуннан соң кассада, җибәрелгәнгә караганда, 975 сум 80 тиенгә артыграк акча калды. Башта кассада күпме акча булган?

390. 1) 8 *т* ничә килограммны төзи? 5 *т*? 2 *т* 400 *кг*? 8 *ц* 76 *кг*? 4 *ц* 8 *кг*?

2) 10 сум ничә тиенне төзи? 14 сум? 20 сум? 8 сум 75 тиен? 13 сум 50 тиен? 10 сум 8 тиен?

3) 4 785 *м* ничә километр һәм метрны төзи? 10 000 *м*? 16 005 *м*? 18 032 *м*?

391. (Телдән.) Ярыш вакытында укучы колга белән 3 *м* 96 *см* биеклеккә, ә олы спортсмен аннан 48 *см* га биегрәк сикерде. Спортсменның сикерү биеклеген табарга һәм аны сезнең класс бүлмәсе биеклеге белән чагыштырырга.

392 8 *ц* 75 *кг* + 4 *ц* 96 *кг* 15 *кг* 756 *г* + 20 *кг* 439 *г*
5 *м* 38 *см* + 9 *м* 75 *см* 17 *км* 390 *м* + 18 *км* 870 *м*
10 *т* 492 *кг* + 735 *кг* 5 *кг* 850 *г* + 644 *г*

393. 2 *км* 85 *м* + 6 *км* 73 *м* 8 сум 7 тиен + 26 сум 5 тиен
8 *км* 7 *м* + 5 *км* 4 *м* 6 сум 9 тиен + 95 сум 4 тиен
5 *т* 85 *кг* + 2 *т* 78 *кг* 58 *м* 6 *см* + 19 *м* 4 *см*
9 *т* 6 *кг* + 3 *т* 9 *кг* 26 *м* 7 *см* + 54 *м* 5 *см*

394. Пароход беренче сәгатьтә 18 *км* 400 *м*, икенче сәгатьтә, беренчегә караганда, 3 *км* 200 *м* артыграк, ә өченче сәгатьтә, беренче һәм икенче сәгатьләрнең икесендә узганга караганда, 2 тапкыр кимрәк узган. 3 сәгатьтә пароход күпме араны узган?

395. Складта яшелчә саклана иде. Складтан бер йөк машинасы белән 4 *т* 800 *кг*, ә икенче йөк машинасы белән 3 *т* 900 *кг* яшелчә җибәргәч, анда, җибәрелгәнгә караганда, 2 *т* 650 *кг* га артыграк яшелчә калды. Башта складта күпме яшелчә булган?

396. 29 сум 68 тиен + 71 сум 59 тиен
62 сум 6 тиен + 38 сум 75 тиен

15 *м* 98 *см* + 20 *м* 36 *см* 12 *кг* 78 *г* + 9 *кг* 60 *г*
12 *м* 34 *см* + 8 *м* 7 *см* 13 *ц* 95 *кг* + 18 *ц* 8 *кг*
10 *кг* 564 *г* + 5 *кг* 608 *г* 80 *км* 750 *м* + 26 *км* 90 *м*

397. 1) 80 *кг* 70 *г* һәм 90 *кг* 60 *г* саннарының суммасын 86 *кг* 64 *г* га арттырырга.

2) Киметүче 8 *ц* 67 *кг*. Аерма 9 *ц* 75 *кг*. Кимүчене табарга.

398. Туристлар 5 *км* 300 *м* биеклеккә менгәч, ял иттеләр. Моннан алар, бер көнне тагын 1 439 *м* га, икенче көнне 700 *м* га күтәрелеп, „Победа пигы"ның түбәсенә менеп җиттеләр. „Победа пигы"ның түбәсе нинди биеклектә?

399. Юл эшчеләренең ике бригадасы, юлның ике очыннан башлап бер-беренә каршы, шоссега асфальт җәеп киләләр. Бер бригада 5 *км* 60 *м*, ә икенче бригада аннан 2 *км* 80 *м* га артыграк юлга асфальт җәйгән, алар арасындагы ераклык 860 *м* булып калган. Шоссеның озынлыгын исәпләргә.

400. Поезд 3 сәгать юлда булган. Беренче сәгатьтә ул 43 *км* 500 *м*, икенче сәгатьтә, беренчегә караганда, 1 *км* 900 *м* га артыграк, ә өченче сәгатьтә, икенче сәгатьтәгегә караганда, 700 *м* га артыграк барган. Поездның уртача сәгатьлек тизлеген табарга.

Төзелмә исемле саннарны алу.

401. (Телдән.)

1) 1 *т* 1 *ц* дан ничә килограммга артыграк?
2) 1 *т* 1 *ц* дан ничә тапкыр артыграк?
3) 1 *кг* 1 *г* нан ничә граммга артыграк?
4) 1 *кг* 1 *г* нан ничә тапкыр артыграк?

402. Саннарның аермасын табарга:

1) 2 *т* 800 *кг* белән 800 *кг* ның; 2) 3 *кг* 725 *г* белән 725 *г* ның.

403. Ярышларда совет спортсменкасы йөгереп килеп 1 *м* 73 *см* биеклеккә сикерде, бу бөтенсоюз рекордыннан 4 *см* га һәм бөтендөнья рекордыннан 1 *см* га артыграк. Моңарчы бөтенсоюз рекорды һәм бөтендөнья рекорды нинди булган?

404. 36 *м* 87 *см* — 12 *м* 35 *см* 　　 5 *кг* 825 *г* — 2 *кг* 485 *г*
18 *м* 84 *см* — 10 *м* 42 *см* 　　 9 *км* 632 *м* — 7 *км* 268 *м*

405. $\begin{array}{r} -\,5\ т\ 176\ кг \\ 2\ т\ 285\ кг \\ \hline 2\ т\ 891\ кг \end{array}$ $\underline{12\ км\ 86\ м - 7\ км\ 98\ м = 4\ км\ 988\ м}$ $\begin{array}{r} -\,12086\ м \\ 7098\ м \\ \hline 4988\ м \end{array}$

8 *ц* 75 *кг* — 3 *ц* 86 *кг* 8 *т* 648 *кг* — 2 *т* 964 *кг*
7 *ц* 18 *кг* — 5 *ц* 28 *кг* 12 *кг* 500 *г* — 4 *кг* 645 *г*
9 *м* 50 *см* — 4 *м* 60 *см* 30 *км* 900 *м* — 6 *км* 940 *м*

406 Счётта исәпләргә:

63 сум 56 тиен — 57 сум 24 тиен
74 сум 62 тиен — 43 сум 9 тиен
84 сум 46 тиен — 28 сум 28 тиен
52 сум 30 тиен — 39 сум 45 тиен
71 сум 34 тиен — 28 сум 38 тиен
30 сум 20 тиен — 17 сум 7 тиен

407. 5 *ц* 75 *кг* — 2 *ц* 90 *кг*
9 сум 80 тиен — 4 сум 86 тиен
10 сум 45 тиен — 5 сум 70 тиен
12 *т* 400 *кг* — 8 *т* 600 *кг*
40 *км* 600 *м* — 7 *км* 805 *м*
12 *кг* 425 *г* — 6 *кг* 486 *г*

408. Халыкара ярышларда совет спортсмены бер-бер артлы өч штанга күтәрде (13 нче рәсем). Берсе 137 *кг* 500 *г*, икенчесе 97 *кг* 500 *г*, өченчесе 105 *кг* авырлыкта. Барлык штангаларның авырлыгын кушкач, суммада бөтендөнья рекордыннан 2 *кг* 500 *г* га артыграк сан килеп чыкты. Совет спортсмены нинди рекорд куйды? Безнең спортсмен җиңүенә кадәр бөтендөнья рекорды нинди булган?

13 нче рәсем.

409. Сезнең классның спорт ярышларында буйга сикерү, биеклеккә сикерү, чабу тизлеге, чаңгыда йөрү буенча казанышлары турында мәсьәлә төзегез.

410. Физкультурник 3 *км* 500 *м* араны чабып узды, шуннан соң аңа тагы, узганга караганда, 1 *км* 800 *м* га кимрәк

араны узасы калды. Физкультурник инди ераклыктагы араны чабып узарга тиеш булган?

411. Ящик фруктысы белән 12 *кг* 500 *г* авырлыкта килә. Фруктның саф авырлыгы 10 *кг* 700 *г*. Фрукт, ящикка караганда, күпмегә авыррак?

412. (Телдән.)

1) 1 тоннага кадәр тутырырга: 680 *кг* ны; 520 *кг* ны; 150 *кг* ны; 860 *кг* ны.

2) 1 *км* га кадәр тутырырга: 680 *м* ны; 750 *м* ны; 470 *м* ны; 340 *м* ны.

3) 7 *т* дан 340 *кг* ны алырга. 4 *кг*, 750 граммга караганда, күпмегә артык?

4) 8 сумнан 2 сум 50 тиенне алырга. 5 *км* ны 2 *км* 500 *м* га киметергә.

413. 1) 12 сум 4 тиен — 10 сум 8 тиен
16 *см* 5 *мм* — 12 *см* 6 *мм*
8 *ц* 7 *кг* — 2 *ц* 9 *кг*
10 *ц* 4 *кг* — 7 *ц* 65 *кг*

2) 7 *т* 24 *кг* — 2 *т* 256 *кг*
86 *кг* 8 *г* — 27 *кг* 654 *г*
52 *кг* 13 *г* — 32 *кг* 85 *г*
15 *км* 5 *м* — 12 *км* 8 *м*

414. Гамәлләрне эшләргә һәм дөреслеген тикшерергә:

12 сум 8 тиен — 5 сум 9 тиен	25 *км* 234 *м* — 10 *км* 68 *м*
16 *см* 6 *мм* — 8 *см* 8 *мм*	11 *т* 60 *кг* + 9 *т* 50 *кг*
18 *ц* 9 *кг* + 4 *ц* 47 *кг*	14 *км* 75 *м* — 6 *км* 89 *м*
28 *ц* 64 *кг* — 9 *ц* 5 *кг*	50 *кг* 70 *г* — 40 *кг* 80 *г*

415. 15 *км* 80 *м* һәм 8 *км* 90 *м* саннарының суммасын бу саннарның аермасы кадәр киметергә.

416. Өч малай көнгә 11 *кг* балык тотканнар. Беренче һәм икенче малай тоткан балык бергә 7 *кг* 900 *г* килә, әгәр икенче һәм өченче малайлар тоткан балыкны кушсаң, 6 *кг* 600 *г* була. Һәр малай күпме балык тоткан?

417. Колхоз ашлык җыю пунктына өч машина белән 8 *т* 670 *кг* ашлык җибәрде. Беренче һәм икенче машиналарда бергә 5 *т* 580 *кг*, ә беренче һәм өченчедә 6 *т* 170 *кг*. Һәр машинада күпме ашлык булган?

418. Беренче участоктан 12 *т* 80 *кг*, икенче участоктан 3 *т* 90 *кг* га кимрәк бәрәңге җыеп алдылар. Бәрәңгенең бер өлешен төяп алып киткәч, беренче участокта 5 *т* 400 *кг*, икенче участокта 3 *т* 900 *кг* бәрәңге калган. Кайсы участоктан күбрәк бәрәңге алып киткәннәр һәм күпмегә артык? Чишелешнең дөреслеген тикшерергә.

419. (Телдән.)

1) 18 сум 25 тиен — 3 сум   7 *кг* — 3 *кг* 500 *г*
10 сум 12 тиен — 75 тиен   8 *ц* — 2 *ц* 90 *кг*
10 *м* 16 *см* — 80 *см*   6 *км* — 2 *км* 60 *м*

2) 14 *т* — 8 *ц*   12 *кг* — 445 *г*   18 *ц* — 6 *ц* 72 *кг*
19 *ц* — 19 *кг*   10 *км* — 804 *м*   20 *км* — 2 *км* 180 *м*
56 *м* — 76 *см*   15 *т* — 328 *кг*   60 *кг* — 5 *кг* 470 *г*

3) Гадәттәгечә утыртканда, кыяр уңышы 1 *га* дан 98 *ц*, ә торф-черемә чүлмәкләрдә утыртканда, 1 *га* дан 120 *ц* булган. Торф-черемә чүлмәкләрдә утыртканда, уңыш ничә центнерга артыграк булган?

420. 256 *км* — 35 *км* 675 *м*   120 *м* — 87 *м* 90 *см*
480 *кг* — 139 *кг* 815 *г*   115 *т* — 46 *т* 730 *кг*
500 сум — 387 сум 60 тиен   75 *ц* — 28 *ц* 67 *кг*

421. 32 *км* 165 *м* — 12 *км* 433 *м* + 49 *км* 236 *м*
180 *м* 95 *см* + 58 *м* 45 *см* — 100 *м* 94 *см*
12 *т* — 8 *т* 350 *кг* + 6 *ц* 80 *кг* — 3 *т* 550 *кг*

422. Эшчеләр бер елда 12 *км* тирәнлектә скважина бораулады́лар. Еллык задание 5 *км* 900 *м* иде. Задание ничә метрга арттырып үтәлгән?

423. Патша Россиясендә эшче елга уртача 12 *кг* 800 *г* шикәр тоткан, ә СССР да бер эшче 35 *кг* 600 *г* тота. Совет эшчесе елга ничә килограммга күбрәк шикәр тота?

424. Автобус бер шәһәрдән икенче шәһәргә кадәрге араны 3 сәгатьтә узган. Беренче сәгатьтә ул 32 *км* 200 *м*, икенче сәгатьтә, беренче сәгатьтәгегә караганда, 1 *км* 400 *м* га кимрәк, ә өченче сәгатьтә, беренче ике сәгатьтәгенең икесенә караганда, өч тапкыр кимрәк юл узган. Бу шәһәрләр арасындагы ераклыкны исәпләргә.

425. (Телдән.) Түбәндәге мисалларның һәрберсендә, кушылучыларны простой исемле сан чыгарлык итеп парлап берләштереп, дүрт кушылучының суммасын табарга:

8 *м* 76 *см* + 6 *м* 17 *см* + 10 *м* 24 *см* + 3 *м* 83 *см*
24 сум 8 тиен + 12 сум 35 тиен + 5 сум 92 тиен + 8 сум 65 тиен
3 *км* 720 *м* + 2 *км* 540 *м* + 8 *км* 280 *м* + 1 *км* 460 *м*

426. 1) „Беларусь" тракторының сәгатькә иң кечкенә тизлеге 4 *км* 560 *м*, ә иң зур тизлеге 12 *км* 950 *м*. Бакча тракторының сәгатькә иң кечкенә тизлеге 710 *м*, ә иң зур тизлеге 12 *км* 730 *м*. Һәр тракторның иң кечкенә һәм иң зур тизлекләре аермасын табарга.

2) Кимүче 200 сум, аерма 85 сум. Бу бирелмәләр буенча нәрсә табарга мөмкин һәм нинди гамәл белән?

3) Киметүче 6 *км* 300 *м*, аерма 12 *км* 200 *м*. Бу бирелмәләр буенча нәрсә табарга мөмкин һәм нинди гамәл белән?

427. Өч санның суммасы 2 *т*. Беренче кушылучы икенчедән 7 *ц* 5 *кг* га кимрәк, ә икенче кушылучы 1 *т* 2 *ц* га тигез. Өченче кушылучыны табарга.

428. Кул хезмәте дәресләре өчен мәктәп тукыма һәм жепләр сатып алган. Тукыма 48 сум, жепләр 8 сум 40 тиенгә кимрәк тора. Кассага 100 сумлык акча биргәннәр. Күпме кайтарып алырга тиешләр?

429. Түбәндәге таблицада колхоз звеносы җыеп алган яшелчә уңышы күрсәтелгән.

Яшелчәнең төрләре	План буенча билгеләнгән	Алынган	Өстәмә түләү
Кыяр	23 *ц* 80 *кг*	43 *ц* 28 *кг*	3 *ц* 89 *кг*
Помидор	156 *ц* 20 *кг*	171 *ц* 20 *кг*	2 *ц* 88 *кг*
Кәбестә	146 *ц* 50 *кг*	191 *ц* 97 *кг*	9 *ц* 99 *кг*

Таблица буенча табарга:

1) звеноның һәр культура буенча планны күпмегә арттырып үтәгәнен;

2) звеноның планны арттырып үтәгән өчен барысы күпме өстәмә яшелчә алуын.

430. Күмер төялгән ике вагонны бушаттылар. Беренче вагонда 30 *т*, икенче вагонда 1 *т* 800 *кг* га кимрәк күмер бул-

ган. Бер сәгать бушаткач, беренче вагонда 13 *т* 600 *кг*, ә икенче вагонда 11 *т* 400 *кг* күмер калган. Кайсы вагоннан күбрәк бушатканнар һәм күпмегә артыграк?

431. 2 *кг* 500 *г* — 1 *кг* 750 *г* мисалына карата алу гамәленә әч простой мәсьәлә төзергә һәм чишәргә.

Төзелмә исемле саннарны тапкырлау.

432. (Телдән.)

7 сум 15 тиен × 3 | 5 *ц* 16 *кг* × 4 | 8 *см* 3 *мм* × 3
6 сум 20 тиен × 5 | 8 *м* 27 *см* × 2 | 5 *дм* 2 *см* × 5

433.

```
  8 км 156 м        6 кг 387 г
×        6        ×          4
 48 км 936 м       25 кг 548 г
```

4 *кг* 286 *г* × 3 | 5 *кг* 250 *г* × 4 | 9 *км* 428 *м* × 5
5 *т* 435 *кг* × 2 | 2 *км* 125 *м* × 8 | 8 *т* 340 *кг* × 7
8 *км* 136 *м* × 6 | 6 *т* 200 *кг* × 5 | 2 *кг* 185 *г* × 9

434. 12 сум 54 тиен × 9 | 19 *км* 384 *м* × 7 | 8 *кг* 40 *г* × 9
16 *м* 68 *см* × 6 | 18 *т* 574 *кг* × 5 | 5 *км* 6 *м* × 8

435. 7 сум 83 тиен × 3 | 3 *км* 35 *м* × 7 | 32 *т* 7 *кг* × 8
9 *м* 65 *см* × 4 | 4 *кг* 490 *г* × 6 | 28 *кг* 150 *г* × 9
8 *ц* 8 *кг* × 9 | 8 *км* 625 *м* × 5 | 24 *ц* 60 *кг* × 7

436. Тракторист 8 *га* җир сөргән һәм 120 *кг* ягулык бетергән. Норма буенча ул бер гектарга 17 *кг* 500 *г* ягулык тота ала. Тракторист күпме ягулыкка экономия ясаган?

437. Мәктәп буфеты өчен җибәрелгән продуктлар барысы бергә күпме тора икәнен исәпләргә:

Товар исеме	Микъдар	1 *кг* ның бәясе		Гомуми бәясе
		сум	тиен	
Шикәр	5 *кг*	10	50	?
Конфет	6 *кг*	15	65	?
Сыр	2 *кг*	25	20	?
Май	3 *кг*	25	80	?
Барысы				?

438. Беренчесе икенчесеннән 3 тапкыр озынрак, икенчесе өченчедән 2 тапкыр озынрак, ә өченчесе 1 *см* 8 *мм* га тигез булган өч кисемтә сызарга.

439. Мастерской бер кешедән ике пар аяк киеме төзәтергә алган һәм аңа квитанция биргән. Расчёт дөрес ясалганмы икәнен тикшерегез. Гамәлләрне языгыз һәм үтәгез:

Эш исемнәре	Микъдар	1 данәнең бәясе	Гомуми бәясе
Подмёткалар Ямаулар Набойкалар	1 пар 4 данә 4 данә	12 сум 75 тиен 1 сум 90 тиен 2 сум 50 тиен	12 сум 75 тиен 7 сум 60 тиен 10 сум
Барысы			30 сум 35 тиен

440. (Телдән.) 5 *т* 260 *кг* да ничә килограмм? 8 *ц* 6 *кг* да? 3 *км* 750 *м* да ничә метр? 12 *м* 80 *см* да ничә сантиметр?

441. 8 *м* 76 *см* × 48 = 420 *м* 48 *см*

$$\begin{array}{r} 876\ см \\ \times\ 48 \\ \hline 7008 \\ +\ 3504 \\ \hline 42048\ см \end{array}$$

1) 8 *м* 9 *дм* × 56   7 *м* 85 *см* × 18   15 *км* 685 *м* × 76
5 *см* 6 *мм* × 40   4 *ц* 90 *кг* × 26   28 *т* 426 *кг* × 98

2) 9 *т* 8 *ц* × 74   8 сум 35 тиен × 52   20 *кг* 506 *г* × 64
6 *дм* 4 *см* × 19   9 *м* 17 *см* × 68   15 *км* 760 *м* × 90

442. 1) 8 *км* 95 *м* × 16   10 *м* 8 *см* × 76   6 *т* 90 *кг* × 400
5 *т* 70 *кг* × 38   8 *ц* 6 *кг* × 45   2 *кг* 68 *г* × 520

2) 9 *кг* 84 *г* × 52   6 *дм* 7 *мм* × 58   8 *км* 79 *м* × 346
6 *км* 50 *м* × 80   8 *км* 6 *м* × 70   9 *ц* 75 *кг* × 108

443. Кит аулаучы флотилия „Слава“ бер рейста 3000 кит аулады. Һәр киттан уртача 8 *т* 400 *кг* май алдылар. Әгәр 1 *т* балык маен алмаштыру өчен 120 сарык кирәк булса, бу рейста табылган майны алмаштыру өчен ничә сарык кирәк булыр иде?

444. Колхоз умарталыгында 200 умарта бар. Колхоз һәр умартадан уртача 68 *кг* 250 *г* бал һәм 1 *кг* 300 *г* балавыз алды. Барлык умарталардан барысы күпме бал һәм күпме балавыз алынган?

445. 40 *кг* сөттән 1 *кг* 800 *г* май алынган. 80 чиләк сөттән күпме май алып булыр? Чиләк 12 *кг* 500 *г* сөт сыйдыра.

446. (Телдән.)

1) 3 *кг* он 1 *кг* 200 *г* артым бирде. Шундый 15 *кг* он күпме артым бирер?

2) 6 *т* тимер рудасыннан 2 *т* 650 *кг* чуен алынды. Шундый 12 *т* тимер рудасыннан күпме чуен чыгар?

3) Кеше тәнендә һәр 12 *кг* авырлыкка 8 *кг* 400 *г* су туры килә. 60 *кг* авырлыктагы кешенең тәнендә ничә килограмм су булыр?

447.

8 сум 78 тиен × 26	12 *км* 76 *м* × 96	10 *м* 80 *см* × 604
5 сум 3 тиен × 48	15 *т* 75 *кг* × 84	50 *кг* 90 *г* × 809
10 сум 6 тиен × 54	30 *кг* 80 *г* × 75	40 *км* 500 *м* × 706

448. (15 *м* 45 *см* + 18 *м* 88 *см*) × 38
(20 *кг* 750 *г* — 14 *кг* 900 *г*) × 206

449. 2 *кг* 854 *г* × 28 + 3 *кг* 406 *г* × 46
7 *км* 462 *м* × 42 — 4 *км* 308 *м* × 37
8 *кг* 769 *г* × 25 — 3 *кг* 260 *г* × 17

450. 1) Тапкырлануычы 5 *м* 8 *дм*, тапкырлаучы 20 булса, тапкырчыгышны табарга; 2) тапкырлануычы 6 *ц* 8 *кг*, тапкырлаучы 15 булса, тапкырчыгышны табарга.

451. Ял йортында һәр ял итүчегә бер тәүлеккә түбәндәге продуктлар тотыла:

арыш һәм бодай икмәге	400 *г*	ит 200 *г*
бәрәңге	300 *г*	май 40 *г*
төрле яшелчә	350 *г*	сөт 400 *г*
ярмалар һәм макарон	40 *г*	шикәр 100 *г*
фруктлар һәм җиләк	240 *г*	

Ял йортына 200 кешегә бер айга (айда 30 көн дип исәпләп) һәр продуктның күпме кирәк булуын исәпләргә.

452. Турыпочмаклыкның иңе 4 *см* 8 *мм*, ә буе, иңенә карагында, ике тапкыр озынрак. Бу турыпочмаклыкның яклары суммасын исәпләргә. Чишелешне санлы формула белән язарга.

453. Бер физкультурник секундка 5 *м* 86 *см*, ә икенчесе 6 *м* 6 *дм* чаба. 1 минутта аларның берсе икенчесеннән күпмегә артыграк араны чаба? Мәсьәләнең чишелешен санлы формула белән язарга.

454. Эшче хатын 8 сәгатьтә кулдан 12 *кг* пилмән ясый, ә машина-автомат бер минутта 16 *кг* 600 *г* пилмән хәзерли. Автоматның җитештерүчәнлеге, кул белән эшләүгә караганда, ничә тапкыр артыграк?

Төзелмә исемле саннарны бүлү.

455. (Телдән.)

1) Метрларга вакларга: 3 *км* 27 *м*; 2 *км* 6 *м*; 10 *км* 20 *м*
килограммнарга: 6 *т* 240 *кг*; 8 *ц* 10 *кг*; 6 *кг* 80 *г*

2) Километрлар һәм метрларга эреләргә: 3 035 *м*; 2 009 *м*
килограмм һәм граммнарга: 5 045 *г*; 4 285 *г*
тонналар һәм килограммнарга: 2 615 *кг*; 8 080 *кг*

456.

```
  36 м     | 24               36 сум      | 45
  12 м     |------------    _ 3600 тиен  |---------
 -------   |1 м 50 см         360         |80 тиен
_ 1200 см                     -----
  120
  ----
```

54 сум : 24	2 *дм* : 8	17 *м* : 85
77 *м* : 28	2 *см* : 4	36 *м* : 48
35 *ц* : 10	3 *м* : 6	15 *кг* : 60
36 *км* : 16	6 *см* : 4	42 *т* : 30

457.

152 *км* : 32	13 *т* : 2	6 *т* : 80
492 *м* : 24	22 *км* : 5	12 *м* : 25
350 *м* : 28	86 *ц* : 4	16 *ц* : 64
248 сум : 20	100 сум : 8	12 *кг* : 16

458. Бамбук агачы биеклеккә бары 45 көн генә үсә һәм шул арада аның биеклеге 36 *м* га җитә. Бамбук агачы көнгә уртача ничә сантиметрга үсә?

459. Пионерлар лагеренда 50 пионерны тукландыруга көнгә 20 *кг* икмәк, 10 *кг* ит, 2 *кг* май, 15 *кг* бәрәнге, 3 *кг* ярма, 5 *кг* шикәр, 1 *кг* каймак һәм 50 *кг* фрукт тоталар. Бер пионерны тукландыру өчен һәр продукт аерым-аерым күпме китә?

460. 24 данә балалар күлмәге тегү өчен 60 *м* материя киткән. Зурлар күлмәгенә, балалар күлмәгенә караганда, 75 *см* артыграк материя китә. 30 данә зурлар күлмәге тегү өчен ничә метр материя китәр?

461. 18 *кг* йоннан 15 пар хатын-кызлар киез итеге сукканнар. Бер пар ирләр киез итегенә, бер пар хатын-кызлар итегенә караганда, 1 *кг* га артыграк йон китә. 40 пар ирләр киез итегенә күпме йон кирәк?

462. (Телдән.)

1) 6 *ц* да ничә килограмм? 12 *км* да ничә метр? 10 сумда ничә тиен?

2) 2 *кг* ны 4 кә; 6 *км* ны 4 кә; 15 *ц* ны 6 га; 11 *т* ны 5 кә бүләргә.

463. (Телдән.) Машина белән бер сәгатьтә 3 *км* озынлыгындагы канауны казып була, ә бер җир казучы эшче 8 сәгатьтә шундый 24 *м* канауны казый ала. Бу машина ничә җир казучыны алмаштыра?

Күрсәтмә. 3 *км* ны метрларга вакларга.

464. (Телдән.) 25 тонна йөк күтәрешле үзбушаткыч автомобиль көнгә 16 рейс ясый, ә ат шул ераклыкка көнгә 2 *т* йөк илтә ала. Бу автомобиль ничә атны алмаштыра?

465.

```
_90 сум 72 тиен | 28                 _5 м 85 см | 18
  84            |---------------      ---------+------------
  ----          | 3 сум 24 тиен         585 см | 32 см 5 мм
   6 сум                                45
  ------                                ---
_ 672 тиен                               9 см
  56                                    ------
  ---                                   90 мм
_ 112                                   ---
  112                                    0
  ---
   0
```

54 сум 4 тиен : 28	35 *км* 25 *м* : 15	81 *т* 25 *кг* : 25
40 *км* 352 *м* : 32	66 *ц* 56 *кг* : 32	98 *ц* 70 *кг* : 94

466.

721 сум 44 тиен : 36	282 *км* 975 *м* : 75	814 *ц* 3 *кг* : 203
125 *кг* 285 *г* : 45	109 *т* 392 *кг* : 48	516 *ц* 12 *кг* : 253

467. Бүләргә һәм дөреслеген тикшерергә:

8 *м* 64 *см* : 9   10 *ц* 44 *кг* : 36   9*ц* 65 *кг* : 40
4 *м* 68 *см* : 6   16 *м* 32 *см* 48   12 *м* 72 *см* : 48
7 *ц* 35 *кг* : 5   11 *м* 70 *см* : 36   2 *км* 328 *м* : 75

468. 50 *км* 52 *м* : 86   (53 *км* 256 *м* + 30 *км* 744 *м*) : 42
33 *м* 76 *см* : 80   (5 *т* 120 *кг* — 2 *т* 840 *кг*) : 12

469. 27 *т* 536 *кг* : 16 + 72 *т* 928 *кг* : 32
62 *м* 30 *см* : 35 — 53 *м* 90 *см* : 70
41 *кг* 745 *г* : 15 — 34 *кг* 335 *г* : 45

470. 1) 4 *кг* 186 *г* һәм 24 саннарының тапкырчыгышын 48 тапкыр киметергә.

2) Бүленүче 121 *кг* 440 *г*, бүлүче 24. Өлешне табарга.

471. Балта 2 *кг* 700 *г*, чүкеч балтадан 3 тапкыр җиңелрәк, ә келәшчәдән 4 тапкыр авыррак. Бу өч инструмент бергә нинди авырлыкта килә?

472. Өч колхоз шикәр заводына чөгендер китерделәр: берсе 633 *т* 600 *кг*, икенчесе аннан 2 тапкыр кимрәк, ә өченчесе беренче китергәннең дүрттән бере кадәр. Өч колхоз барысы күпме чөгендер китергәннәр?

473. Колхоз 300 баш сыер өчен кышка 1 620 *т* силос хәзерләгән. Әгәр бу запас 180 көнгә җитәргә тиеш булса, бер сыерга көнгә күпме силос бирергә мөмкин?

474. Буфетчы балалар өчен 50 иртәнге аш (бутерброд белән кайнар чәй) хәзерләде һәм моның өчен ул 1 *кг* май, 1 *кг* шикәр, 1 *кг* сыр һәм 5 *кг* икмәк тотты. Түбәндәге таблицадан файдаланып, бер иртәнге ашның уртача бәясен исәпләргә.

Продукт исемнәре	1 *кг* ның бәясе	
	сум	тиен
Икмәк	1	90
Май	25	80
Сыр	24	70
Шикәр	10	50

475. Шикәр заводында шикәрне 500 грамм итеп пачкаларга төрәләр. 1 *т* шикәрне төргәндә, шундый ничә пачка чыгар?

476. 36 сум : 75 тиен 21 *км* : 840 *м* 30 *ц* : 15 *кг*
35 *кг* : 125 *г* 72 *м* : 96 *см* 28 *т* : 8 *ц*
74 *т* : 250 *кг* 18 *ц* : 72 *кг* 15 сум : 25 тиен

477. 6 *кг* : 25 *г* 8 *м* : 5 *мм* 20 сум : 50 тиен
2 *км* : 8 *м* 7 *ц* : 5 *кг* 85 сум : 25 тиен
5 *т* : 2 *кг* 9 *кг* : 10 *г* 90 *м* : 10 *см*

478. Слесарьлык мастерскоенда берсе 16 *кг* 500 *г* авырлыкта, икенчесе аннан 3 тапкыр җиңелрәк булган ике төргәк тимер чыбык тотканнар. Әгәр 1 *м* чыбык 80 *г* килсә, бу төргәкләрдә ничә метр тимер чыбык булган?

479. Бер рекордчы сыер тәүлеккә 42 *кг* 100 *г*, ә икенчесе аннан 4 *кг* 800 *г* га артыграк сөт биргән. Әгәр һәр балага көненә 500 *г* сөт бирелсә, бу ике сыердан алынган сөт ничә балага җитәр?

480. Сыр пешерү заводында, 1 *кг* сөттән 90 *г* сыр алып, 5 көндә 1 *т* 800 *кг* сыр хәзерләгәннәр. Бу заводта көн саен күпме сөт эшкәрткәннәр?

481. Арышны тар рәтләргә чәчкәндә, 1 *га* дан алына торган уңыш 2 *ц* 50 *кг* га арткан. Әгәр барлык участоктан алынган уңыш 50 *т* га арткан булса, бу юл белән ничә гектар җиргә арыш чәчелгән?

482. 10 сум : 2 сум 50 тиен 735 *кг* : 7 *кг* 500 *г*
14 сум : 2 сум 80 тиен 150 *км* : 3 *км* 125 *м*
84 *км* : 5 *км* 600 *м* 450 *т* : 9 *т* 375 *кг*

483. 30 *м* : 3 *м* 75 *см* 35 *кг* : 125 *г* 132 *м* : 2 *м* 75 *см*
6 *т* : 2 *ц* 40 *кг* 4 *м* : 50 *мм* 385 *км* : 3 *км* 80 *м*

484. 1) 26 сум 24 тиен : 32 тиен 8 *дм* 6 *см* : 4 *мм*
48 *м* 24 *см* : 36 *см* 6 *т* 68 *кг* : 200 *г*
22 *км* 50 *м* : 150 *м* 8 *т* 100 *кг* : 9 *ц*

2) 14 *ц* 56 *кг* : 52 *кг* 29 *км* 240 *м* : 680 *м*
28 *м* 50 *см* : 75 *см* 42 *км* 25 *м* : 205 *см*
16 *т* 9 *ц* : 50 *кг* 47 *т* 89 *кг* : 217 *кг*

485. Бер кисәктә 10 *м* 50 *см*, икенчесендә аннан 4 тапкыр артыграк тукыма бар. Икенче кисәк тукымадан, һәрбер-

сенә 3 *м* 50 *см* кертеп, күлмәкләр текteләр. Ничә күлмәк теккәннәр?

486. Бер кисәктә 38 *м* 80 *см*, икенчесендә аннан 12 *м* 60 *см* га кимрәк сукно бар. Бер пальтога 3 *м* 25 *см* сукно китә. Бу ике кисәк суконадан ничә пальто тегәргә мөмкин?

487. Бәрәңге уңышы буенча дөньякүләм рекорд безнең илдә, бу рекорд 1 *га* дан 133 *т*, ә бәрәңгедән алына торган гадәттәге уртача уңыш 1 *га* дан 16 *т* 625 *кг*. Дөньякүләм рекорд гадәттәге уртача уңыштан ничә тапкыр артыграк?

488. Бер машинада иң вак 4 деталь 16 *г*, ә иң эре 3 деталь 9 *кг* 600 *г* авырлыкта килә. Бер эре детальнең авырлыгы бер вак деталь авырлыгыннан ничә тапкыр артыграк?

489. 1 *ц* кыярны тозлау өчен 3 *кг* укроп, 500 *г* керән, 500 *г* сарымсак, 100 *г* кызыл борыч алалар. 1 *т* 500 *кг* кыярны тозлау өчен бу әйберләрнең һәрберсен күпмешәр хәзерләргә кирәк?

490. Буш мичкә 14 *кг* 500 *г*, ә керосин тутырылгач 94 *кг* 300 *г* авырлыкта килә. 1 *л* керосин 798 *г* килә. Мичкәдә ничә литр керосин бар?

491. Бер колхозда үстерелгән йөк аты 15 *т* 300 *кг* йөк тартты. Гадәттә ат бик ерак булмаган арага 900 *кг* йөк илтә. Бу йөк аты ничә гади атны алмаштыра ала?

492. Колхозчы хезмәт көннәренә акчалата 3 570 сум алган. Бер хезмәт көненә 5 *кг* яшелчә, 2 *кг* 400 *г* бодай һәм 8 сум 50 тиен акча бирелгән. Бу колхозчы күпме бодай һәм күпме яшелчә алган?

493. 166 *м* 25 *см* : 4 *м* 75 *см* =

166 *м* 25 *см* = 16 625 *см*
4 *м* 75 *см* = 475 *см*

```
_16 625 см | 475 см
  1 425    |--------
  -----    | 35
 _ 2375
   2375
   ----
      0
```

12 *км* 510 *м* : 1 *км* 390 *м* 197 сум 60 тиен : 5 сум 20 тиен
25 *т* 200 *кг* : 3 *т* 150 *кг* 320 *кг* 45 *г* : 1 *кг* 265 *г*
49 *км* 920 *м* : 2 *км* 80 *м* ч 190 *ц* 8 *кг* : 3 *ц* 52 *кг*

494. Бүләргә, тапкырлау һәм бүлү белән дөреслеген тикшерергә:

51 *кг* 450 *г* : 3 *кг* 430 *г* 418 *км* 200 *м* : 2 *км* 50 *м*
56 сум 70 тиен : 4 сум 5 тиен 129 *м* 60 *см* : 5 *м* 40 *см*

495. Самолёт моделе ясау өчен балалар 35 *м* чыбыкны ике тигез кисәккә кистеләр; аннан соң бер кисәген тагы 2 *м* 50 *см* лы кисәкләргә, ә икенче кисәген 1 *м* 75 *см* лы кисәкләргә кистеләр. Барысы ничә кисәк килеп чыкты?

496. 9 *м* 60 *см* озынлыктагы тимер чыбыктан 7 *м* 20 *см* лы кисәк кисеп алдылар. Калган чыбык, кисеп алынганына караганда, ничә тапкыр кимрәк?

497. 1) 470 *км* 890 *м*, 2 *км* 170 *м* га караганда, ничә тапкыр зуррак? 255 *т* 380 *кг*, 1 *т* 130 *кг* га караганда?

2) 6 *кг* 400 *г*, 12 *ц* 16 *кг* га караганда, ничә тапкыр кимрәк? 2 *м* 82 *см*, 242 *м* 52 *см* га караганда?

498. Яхшыртылган нәселле бер тәкә елга 23 *кг* 300 *г*, ә икенче тәкә аннан 3 *кг* 800 *г* га артыграк нечкә йон биргән. Бер костюмга җитәрлек тукыма өчен 4 *кг* 200 *г* йон кирәк. Бу ике тәкә йонынннан хәзерләнгән материядән ничә костюм тегеп булыр?

499. Квадратлап-оялап утыртканда, гектарга 8 хезмәт көне киткән һәм һәр гектардан 270 *ц*, ә рәткә утыртканда, гектарга 52 хезмәт көне киткән һәм һәр гектардан 117 *ц* бәрәңге алганнар. Квадратлап-оялап утыртканда, 1 хезмәт көненә ничә тапкыр артыграк бәрәңге алганнар?

500. Түбәндәгечә чишелә торган мәсьәлә төзергә:

1) 14 *м* 40 *см* : 3 = 4 *м* 80 *см*

2) 33 *м* 60 *см* : 4 *м* 80 *см* = 7 (күлмәк)

Җавап. 33 *м* 60 *см* материядән 7 күлмәк чыга.

Исемле саннар өстендә барлык гамәлләргә мәсьәләләр.

501. Уралда Благодать тавы хәзинәләрендә 36 500 000 *т*, ә Магнитный тавы хәзинәләрендә шундый 188 000 000 *т* чамасы магнит рудасы бар. 100 *кг* магнит рудасыннан 72 *кг* тимер чыга. Бу ике таудагы рудадан күпме тимер эретеп булыр?

502. Эрләү фабрикасы эшчеләре 8 ай эчендә 20 *т* мамыкка, 10 *т* җепкә һәм 1 600 000 сум акчага экономия ясадылар. Фабрика бер елга күпме мамыкка, җепкә һәм акчага экономия ясый ала? Ике юл белән чишәргә.

503. Алдынгы бригадада 25 эшче хатын-кызның һәрберсе көнгә 60 *г* җепкә экономия ясады. Әгәр 1 *м* тукымага 520 *г*

жеп китсә, бер айда ясалган экономиядән ничә метр тукыма сугып булыр? Әгәр бер костюмга 3 *м* тукыма китсә, бу тукымадан ничә костюм тегеп булыр?

Белешмә. Айда 26 эш көне.

504. Заказчикка костюм күпмегә төшкән? Аны түбәндәге квитанция буенча исәпләгез.

Материал һәм тегү	Микъдар	1 *м* нын бәясе		Гомуми бәясе	
		сум	тиен	сум	тиен
Йон материал	3 *м*	205	—		
Сатин	3 *м* 50 *см*	14	—		
Астарлык һ. б.				47	50
Тегү				190	

505. 1) 12 йөк машинасы белән 44 *т* 500 *кг* күмер китерделәр, алардан 5 машинага 3 *т* 500 *кг* нан, 3 машинага 4 *т* 200 *кг* нан төягәннәр. Әгәр һәр машинага бертигез төягән булсалар, калган машиналарның һәрберсе белән күпме күмер китергәннәр?

2) Йөк машиналарының савы һәм һәр машинага күпме күмер төяүләре билгеле булып, барысы күпме күмер китерелгәнне белү соралган мәсьәлә төзергә.

506. Запас юлда бер рәттән барысы 60 товар һәм пассажир вагоннары тора, шуның белән бергә аларның биштән бере пассажир вагоннары. Товар вагонының буе 7 *м* 5 *дм*, ә пассажир вагоны аннан 4 *м* га озынрак. Барлык составның озынлыгын табарга.

507 Паровоз поездның һәр тонна авырлыгына сәгатькә 8 *кг* 500 *г* су тота. Поезд 95 *т* авырлыктагы паровоздан һәм уртача һәрберсе 22 *т* 5 *ц* авырлыгындагы 44 вагоннан тора. Паровоз 4 сәгатьлек юлга ничә тонна су алырга тиеш?

508. Кул эше дәресләре өчен мәктәп 45 кайчы һәм 30 пычак сатып алган. Бер пычак 2 сум 70 тиен, ә өч кайчының бәясе 5 пычак бәясе кадәр тора. Сатып алынган әйберләр барысы бергә күпме тора?

509. География дәресләре өчен 24 сум 75 әр тиеннән 2 данә стена картасы, 36 сум 45 тиенгә бер зур глобус һәм балалар өчен тагы 20 данә кечкенә глобус сатып алганнар

Әгәр 9 кечкенә глобус 2 зур глобус кадәр торса, барлык әйберләр күпме тора?

510. 8 *кг* свежий грушадан 3 *кг* кипкән груша, ә 11 *кг* свежий алмадан 5 *кг* кипкән алма чыга. 4 *ц* груша, 8 *ц* 80 *кг* алманы киптергәч, күпме кипкән фрукт чыгар?

511. Өч йөк машинасына бер үк авырлыктагы капчыкларда 92 *ц* бөртекле ашлык төяделәр. Бер машинага 42 капчык, икенчесенә 38 капчык, өченчесенә 35 капчык төяделәр. Һәр машинага ничә килограмм ашлык төягәннәр?

512. Бер совхозда бер сарыктан 5 *кг* 200 *г* йон алдылар, шуның белән бергә һәр 100 *г* йоннан 37 *г* саф сүс алдылар. Икенче совхозда бер сарыктан 4 *кг* 700 *г* йон, шуның белән бергә һәр 100 *г* йоннан 47 *г* саф сүс алганнар. Кайсы совхозда бер сарыктан күбрәк саф сүс алганнар һәм күпмегә артык?

513. Аралары 350 *км* булган ике пристаньнан бер-беренә каршы ике пароход чыккан. Аларның берсе сәгатькә 20 *км* тизлек белән барган. 6 сәгатьтән соң алар арасындагыераклык 80 *км* булган. Икенче пароходның сәгатьлек тизлеген табарга. Өч гамәл белән чишәргә.

514. Саннар эзләп табарга һәм түбәндәге мәсьәләләрне чишәргә:

1) Әтисе һәм улы (ун яшьлек малай) аралары ... *км* булган ике урыннан бер үк вакытта бер-берсенә каршы чыкканнар. Әтисе сәгатькә ... *км*, ә улы ... *км* барган. Очрашканга кадәр аларның һәрберсе нинди ераклыктагы араны узган?

2) Ике велосипедист аралары ... *км* булган ике урыннан бер үк вакытта бер-берсенә каршы чыкканнар. ... сәгатьтән соң алар очрашканнар. Бер велосипедист сәгатькә ... *км* тизлек белән барган. Икенче велосипедист нинди тизлек белән барган?

515. Москвадагы метроны төзүче ике бригада бер айда 100 *м* туннель салырга йөкләмә алган. 20 көндә бер бригада 40 *м* 20 *см*, икенчесе 4 *м* 60 *см* га артыграк туннель салган. Ай азагына кадәр шул ук житештерүчәнлек белән эшләсәләр, бу бригадалар йөкләмәне күпмегә арттырып үтәрләр?

Белешмә. Айда 26 эш көне.

516. Бер совхозда 150 сыер елга уртача 6 050 шәр литр сөт бирде. Бу сөтнең барысы да май эшләүгә китте. 25 *л* сөттән 1 *кг* май чыкты. Әгәр һәр кешегә елга 11 *кг* май тотылса, бу май ничә кешегә житәр?

517. Ике гади һәм бер ашыгыч телеграмма өчен 27 сум 60 тиен түләделәр. Бер гади телеграммада 17 сүз, икенчесендә 23 сүз булган. Ашыгыч телеграммада ничә сүз булган?

Белешмә. Гади телеграмманың һәр сүзе өчен 30 тиен, ә ашыгыч телеграмманың һәр сүзе өчен 90 тиен түлиләр. Шуның өстенә һәр телеграмманы җибәрү өчен 1 сум алалар.

518. Бер мәктәпнең укучылары, икенче мәктәп укучылары белән язышу өчен, елга 17 сум 90 тиен расход тотканнар; алар 16 простой хат, 14 ачык хат һәм берничә заказной хат җибәргәннәр. Заказной хатны җибәрү 1 сум, простой хатны җибәрү 40 тиен, ачык хатны җибәрү 25 тиен тора. Ничә заказной хат җибәрелгән?

519. Өч саклагычта 313 *т* 5 *ц* бәрәңге бар. Һәр саклагычтан бертигез бәрәңге алгач, беренчедә 97 *т* 6 *ц*, икенчедә 79 *т* 5 *ц*, өченчедә 80 *т* 6 *ц* бәрәңге калган. Башта һәр саклагычта күпме бәрәңге булган? Чишелешнең дөреслеген тикшерергә.

520. 1) Ике төзелешкә бердәй 115 ящикта кадак җибәргәннәр. Ике төзелештә бергә 2060 *кг* кадак тоткач, бер төзелештә 5 ящик, икенче төзелештә 7 ящик кадак калган. Һәр төзелештә ничә килограмм кадак калган?

2) Ике кисәктә 6152 сумлык йон материя бар. Бу ике кисәктән 44 *м* саткач, беренче кисәктә 1307 сум 30 тиенлек, ә икенче кисәктә 1461 сум 10 тиенлек материя калды. Һәр кисәктә ничә метр материя калган?

521. Магазин төрле сорттан һәм төрле бәя белән 9 *т* 4 *ц* алма сатты. Барлык алманың дүрттән бер өлеше килограммы 5 сумнан, яртысы 3 сум 75 тиеннән, ә калган алма килограммы 2 сум 50 тиеннән сатылды. Барлык алма өчен магазин күпме акча җыеп алды?

Кабатлау өчен сораулар.

1) Озынлык үлчәүлекләрен һәм авырлык үлчәүлекләрен әйтергә. Аларны таблица рәвешендә язарга.

2) Нинди исемле сан простой һәм нинди төзелмә дип атала?

3) Исемле санны ваклау дип нәрсәне атыйлар?

4) Исемле санны эреләү дип нәрсәне атыйлар?

5) Исемле саннарны бүлгәндә кайчан исемсез сан һәм кайчан исемле сан чыга?

Диаграммалар

Диаграмма — ул төрле зурлыкларны үзара чагыштырырга булышлык итә торган сызым.

Диаграммаларда саннар туры сызык, турыпочмаклык, түгәрәк һәм башка фигуралар белән, шулай ук рәсемнәр белән сынланалар.

Диаграммалар сызарга керешкәнче, әлек масштаб сайларга кирәк.

Диаграммалар белән еш кына промышленность үсешен, авыл хуҗалыгы үсешен күрсәтү өчен, шулай ук мәктәп тормышының төрле күренешләрен: өлгереш, йөреш һәм башкаларны күрсәтмәле итеп сынлау өчен файдаланалар.



14 нче рәсем.



15 нче рәсем.

522. Диаграммада (14 нче рәсем) квадратлап-оялап утыртканда һәм гадәттәгечә утыртканда, 1 *га* дан алынган бәрәңге уңышы күрсәтелгән. Үлчәү берәмлеге итеп, биеклеге 3 *мм* лы

турыпочмаклык алынган. Ул 10 *ц* ны күрсәтә. Бу диаграмма нәрсә турында сөйли?

523. Диаграммада (15 нче рәсем) Казбек, Эльбрус һәм Сталин пигы тауларының чагыштырма биеклекләре күрсәтелгән. Бу диаграмма нәрсә турында сөйли?

524. Сезнең класстагы малайлар һәм кызлар санын күрсәткән диаграмма сызарга.

525. Мәктәптә 160 пионер бар иде; бер елдан соң алар 220 булдылар. Пионерлар саны үсешен күрсәткән диаграмма сызарга.

526. Китапханәдә 3000 китап бар иде. Уку елы азагына китаплар саны 600 гә, ә яңа уку елы башына тагы 400 китапка артты. Бер шакмакны 200 китап дип алып, диаграмма сызарга.

Квадрат үлчәүлекләр

Мәйдан исәпләү.

Безне әйләндереп алган предметлар арасында турыпочмаклык формасындагы предметлар күп. Мәсәлән, табаклы кәгазь, өстәл өсте, класс тактасы, бүлмәнең идәне һәм стеналары һәм башкалар. Шундый һәрбер предмет билгеле бер мәйданны алып тора.

Мәйданнар төрле зурлыкта булалар. Мәсәлән, тәрәзәнең мәйданы стена мәйданыннан кечерәк, класс тактасының мәйданы өстәл өсте мәйданыннан зуррак, капма-каршы стеналарның мәйданнары үзара тигез.

Мәйданнарны үлчәү өчен квадрат үлчәүлекләр хезмәт итәләр: квадрат метр, квадрат дециметр, квадрат сантиметр һәм башкалар.

Квадрат метр дип, ягы 1 *м* га тигез булган квадратның мәйданы атала.

Квадрат дециметр дип, ягы 1 *дм* га тигез булган квадратның мәйданы атала.

Квадрат сантиметр дип, ягы 1 *см* га тигез булган квадратның мәйданы атала.

527. 1) Дәфтәрдә квадрат дециметр һәм квадрат сантиметр сызарга. Аларны буярга.

2) Газеталардан кисеп һәм ябыштырып квадрат метр ясарга.

528. Буе 7 *см* һәм иңе 1 *см* лы турыпочмаклык сызарга һәм аны бирелгән үрнәкчә (16 нчы рәсем) квадрат сантиметрларга бүләргә. Анда ничә квадрат сантиметр?



16 нчы рәсем.

529. Буе 7 *см*, иңе 3 *см* лы турыпочмаклык сызарга һәм аны бирелгән үрнәкчә (17 нче рәсем) квадрат сантиметрларга бүләргә. Анда ничә квадрат сантиметр?



17 нче рәсем.

530. 18 нче рәсемдә күрсәтелгән турыпочмаклыкның мәйданында ничә квадрат берәмлек бар? (Ике юл белән чишәргә һәм исәпләүләрне язарга.)



18 нче рәсем.

Чишелеш. 11 кв. берәм. $\times$ 6 = 66 кв. берәм. яки
6 кв. берәм. $\times$ 11 = 66 кв. берәм.

531. Турыпочмаклыкның буен һәм иңен үлчәргә, аның мәйданын квадрат сантиметрларга бүләргә һәм турыпочмаклыкның мәйданында (19 нчы рәсем) ул квадрат сантиметрларның ничә икәнен санарга.



19 нчы рәсем.

532. Безнең классның буе ..., иңе ... . Идәннең барлык мәйданына ничә квадрат метр салына алыр?

533 Түбәндәге турыпочмаклыкларның мәйданын исәпләргә:

буе 8 *см*, иңе 3 *см*
„ 15 *см*, „ 8 *см*
„ 24 *см*, „ 10 *см*

Турыпочмаклыкның мәйданын исәпләү өчен, аның буен һәм иңен бер үк үлчәүлек белән үлчәргә һәм килеп чыккан саннарны бер-беренә тапкырларга кирәк. Тапкырчыгышта һәрвакыт квадрат үлчәүлекләр чыга.

534. Әгәр ягы 5 *см*; 9 *см*; 12 *см*; 25 *см*; 40 *см* булса, квадратның мәйданын исәпләргә.

535*. Бүлмәнең буе 5 *м*, иңе 4 *м*. Идәннең мәйданын исәпләргә.

536. Яшелчә бакчасының буе 40 *м*, иңе 20 *м*. Яшелчә бакчасының мәйданын исәпләргә.

537. Чәчәклекнең буе 12 *м*, иңе 10 *м*. Чәчәклекнең мәйданын исәпләргә.

538. Класс бүлмәсенең буе 8 *м*, иңе 6 *м*. Класста 24 укучы. Бер укучыга ничә квадрат метр идән мәйданы туры килә?

1 *см* да 2 *м* масштабы белән сызым ясарга.

539. Бакчаның буе 60 *м*, иңе 40 *м*. Анда 50 төп алмагач үсә. Бер алмагачка ничә квадрат метр туры килә;

540. Коридорның буе 20 *м*, иңе 16 *м* га кимрәк. Коридор идәненең мәйданы күпмегә тигез?

541. Бәрәңге утыртылган участокның иңе 120 *м*, буе 60 *м* га артыграк. Участокның мәйданы күпмегә тигез?

1 *см* да 20 *м* масштабы белән турыпочмаклы участок сызарга.

542. Йөзү бассейнының буе 30 *м*, иңе буенын яртысы кадәр. Бассейнның мәйданы күпмегә тигез?

543. Яшелчә бакчасының буе 160 *м*, иңе 40 *м* га кимрәк. Яшелчә бакчасының мәйданы күпмегә тигез?

544 Мәктәп бакчасы өчен 2 880 *кв. м* зурлыктагы мәйдан бүленеп бирелгән. Әгәр һәр алмагачка буе 6 *м*, иңе 8 *м* лы участок кирәк булса, бу мәйданга ничә төп алмагач утыртып булыр?

---

* Бу бүлекнең киләчәк барлык мәсьәләләрендә турыпочмаклык формасындагы фигуралар бирелә.

545. Мәктәптә 4 класс. Мәктәп участогында һәр классның буе 9 *м*, иңе 8 *м* лы делянкасы бар. Барлык делянкаларның мәйданы күпмегә тигез?

546. Класс бүлмәсенең буе 8 *м*, ә иңе 6 *м*; коридорның буе 24 *м*, ә иңе 4 *м*. Коридорның мәйданы класс бүлмәсе мәйданыннан ничә тапкыр зуррак?

547. Молотов су саклагычы буйга 300 *км*, ә иңгә уртача 30 *км* га сузыла. Аның мәйданын исәпләргә.

548. Яшелчә бакчасының буе 96 *м*, иңе 24 *м* га кимрәк. Бакчаның дүрттән беренә кәбестә, сигездән беренә төрле азыктамырлар, калганына бәрәңге утырттылар. Бәрәңгене ничә квадрат метр мәйданга утыртканнар?

1 *см* да 12 *м* масштабы белән сызым ясарга һәм мәсьәлә бирелмәләре буенча яшелчә бакчасын участокларга бүләргә.

549. Басуның иңе 450 *м*, ә буе 225 *м* га артыграк. Басуның биштән бер өлешенә карабодай, өчтән беренә арпа, калган мәйданга солы чәчкәннәр. Солы нинди мәйданны алып тора?

550. Яшь натуралистлар буе 30 *м*, иңе 20 *м* лы тәҗрибә участогына чөгендер утыртканнар. Алар һәр 100 *кв. м* дан 3 *ц* чөгендер җыеп алганнар. Яшь натуралистлар барысы күпме чөгендер җыеп алганнар?

551. Шәһәрдә квадрат формасында яңа парк утырттылар. Ягы 100 *м* булса, ул паркның мәйданы нинди булыр?

552. Ишек алды квадрат формасында, аның ягы 25 *м* га тигез. Ишек алдының мәйданы нинди?

553. Квадратның ягы 5 *см* га тигез. Квадратның һәр ягын ике тапкыр зурайттылар. Яңа квадратның мәйданы күпмегә тигез? Квадратның мәйданы ничә тапкыр арткан?

Сызым ясарга, фигураларны кисеп алырга һәм кечкенә квадратны зурысы өстенә салырга.

554. Ягы 100 *м* лы квадрат формасындагы участокта кино-театр кордылар һәм парк утырттылар. Кинотеатр алып торган мәйдан квадрат формасында, аның ягы участок ягының дүрттән бере кадәр. Парк нинди мәйданны алып тора? (20 нче рәсем.)

20 нче рәсем.

555. Мәйданы 120 *кв. м* булган турыпочмаклыкның буе һәм иңе нинди булырга мөмкин?

1 *см* да 2 *м* масштабы белән шул турыпочмаклыкларның берсен сызарга.

556. Мәйданы 180 *кв. м* булган участокның буе һәм иңе нинди булырга мөмкин?

557. Шәһәр паркында волейбол өчен буе 15 *м*, иңе 10 *м* лы, футбол өчен буе 90 *м*, иңе 75 *м* лы, крокет өчен буе 25 *м*, иңе 20 *м* лы мәйданчыклар төзеделәр. Өч мәйданчык бергә ничә квадрат метр мәйданны алып тора?

558. Мәктәпнең буе 28 *м* һәм иңе 24 *м* лы яшелчә бакчасында I класс өчен 60 *кв. м*, II класс өчен аннан 15 *кв. м* га артыграк, III һәм IV классларның һәрберсенә 90 *кв. м* мәйдан бүлеп бирделәр, ә калган мәйданны чәчәклек һәм җиләк куаклары өчен аерып куйдылар. Чәчәклек һәм җиләк куаклары өчен ничә квадрат метр урын биргәннәр?

559. Узган мәсьәләләр үрнәгендә бердән артык гамәл белән чишелә торган мәсьәлә төзегез.

560. Түбәндәгечә чишелә торган мәсьәлә төзергә:

1) 20 *кв. м* $\times$ 12 = 240 *кв. м*

2) 240 *кв. м* : 2 = 120 *кв. м*

Җавап. Бөтен бакча мәйданының 120 *кв. м* ын җиләк куаклары алып тора.

561. 21 нче рәсем буенча мәсьәлә төзегез һәм чишегез.



Масштаб: 1 см да — 50 м

21 нче рәсем.

562. Квадрат формасындагы кәгазьнең барлык яклары суммасы 36 *см*. Бу кәгазьнең мәйданында ничә квадрат сантиметр бар?

Бу кәгазьне 1 *см* киңлектәге полоскаларга кисегез. Һәр полосканың мәйданы нинди? Бер полосканың барлык яклары суммасы нинди?

Ар һәм гектар — җир мәйданнары үлчәүлекләре.

Ар — ягы 10 *м* лы квадратның мәйданы. **1 арда 100 *кв. м*.** Ар кыскача *а* хәрефе белән тамгалана.

Гектар — ягы 100 *м* лы квадратның мәйданы.

Гектарда 10 000 *кв. м*. Гектарда 100 *а*. Гектар кыскача *га* дип тамгалана.

563. 1) Мәктәп бинасындагы һәм мәктәп янындагы нинди мәйданнар якынча бер арга тигез?

2) Мәйданы бер арга тигез булган турыпочмаклыкның буе һәм иңе нинди озынлыкларда булырга мөмкин? 1 *см* да 5 *м* масштабы белән шундый турыпочмаклыкларның берсен сызарга.

564. Пионерлар лагерендагы балалар, колхозга булышып, буе 75 *м*, иңе 16 *м* лы яшелчә бакчасының чүбен утадылар. Пионерлар ничә ар җирнең чүбен утаганнар?

565. Яшь натуралистлар буе 20 *м* һәм иңе 15 *м* лы тәҗрибә участогында яңа сорт бодай үстерделәр. Һәр ардан алар уртача 32 *кг* бодай алдылар. Яшь натуралистлар барысы күпме бодай алганнар? Уңыш шундый булганда, 1 *га* мәйданнан ничә килограмм бодай алып булыр иде?

566. Мәктәп укучылары буе 20 *м*, иңе 15 *м* лы тәҗрибә участогында, квадратлап-оялап бәрәңге утырттылар. Алар һәр ардан, гадәттәгечә утыртудагыга караганда, 2 тапкыр артык уңыш алдылар. Гадәттәгечә утыртканда, бер ардан 140 *кг* уңыш алынган булса, тәҗрибә участогыннан күпме бәрәңге алынган?

567 Барысы ничә ар: 300 *кв. м* да; 800 *кв. м* да; 1 000 *кв. м* да; 2 600 *кв. м* да; 4 800 *кв. м* да; 7 000 *кв. м* да; 8 200 *кв. м* да?

568. Түбәндәге исемле саннарда ничә ар һәм квадрат метр:

125 *кв. м*	705 *кв. м*	1 280 *кв; м*	6 965 *кв. м*
375 *кв. м*	840 *кв. м*	3 608 *кв. м*	2 078 *кв. м*

569. Мәйданы бер гектарга тигез булган турыпочмаклык формасындагы участокның буе һәм иңе нинди булырга мөмкин? 1 *см* да 25 *м* масштабы белән шундый участокларның берсен сызарга.

570. Басуның буе 750 *м*, иңе 160 *м*. Басу ничә гектар мәйданны алып тора?

Чишелеш. 750 *кв. м* $\times$ 160 = 120 000 *кв. м* = 12 *га*.

571. Шәһәр паркы буйга 600 *м* га, ә иңгә 400 *м* га сузыла. Парк ничә гектарны алып тора? Бу паркның коймасы нинди озынлыкта?

572. Буе 960 *м*, иңе 750 *м* лы турыпочмаклы басуга бодай чәчкәннәр. 1 *га* га 140 *кг* бөртек чәчкәннәр. Бу басуга барысы күпме бодай чәчкәннәр?

573 Ничә гектар: 10 000 *кв. м* да; 20 000 *кв. м* да; 60 000 *кв. м* да; 100 000 *кв. м* да; 450 000 *кв. м* да; 700 000 *кв. м* да?

574 Ничә гектар һәм квадрат метр: 36 000 *кв. м* да; 506 000 *кв. м* да; 2 725 000 *кв. м* да; 82 725 *кв. м* да; 968 740 *кв. м* да; 9 684 851 *кв. м* да?

575. Бирелгән үрнәк буенча (22 нче рәсем) квадрат дециметр сызарга һәм аны квадрат сантиметрга, ә квадрат сантиметрларның берсен квадрат миллиметрларга бүләргә.



22 нче рәсем.

Квадрат үлчәүлекләр таблицасы.

1 *кв. м* = 100 *кв. дм*	1 *а* = 100 *кв. м*
1 *кв. дм* = 100 *кв. см*	1 *га* = 100 *а* = 10 000 *кв. м*
1 *кв. см* = 100 *кв. мм*	1 *кв. км* = 1 000 000 *кв. м*

576. Сызыкча һәм квадрат үлчәүлекләрне чагыштырыгыз:

1 *м* = 10 *дм*	1 *кв. м* = 100 *кв. дм*
1 *дм* = 10 *см*	1 *кв. дм* = 100 *кв. см*
1 *см* = 10 *мм*	1 *кв. см* = 100 *кв. мм*

577. 1) 100 *кв. мм* да ничә квадрат сантиметр? 400 *кв. мм* да? 500 *кв. мм* да? 2) 100 *кв. см* да ничә квадрат дециметр? 200 *кв. см* да? 700 *кв. см* да? 900 *кв. см* да? 3) 100 *кв. дм* да ничә квадрат метр? 600 *кв. дм* да? 800 *кв. дм* да? 10 000 *кв. см* да? 30 000 *кв. см* да? 60 000 *кв. см* да? 83 000 *кв. см* да? 36 100 *кв. см* да?

578. Дәфтәр битенең буе 2 *дм* 1 *см*, иңе 1 *дм* 7 *см*. Дәфтәр битенең мәйданы күпмегә тигез?

579. Өстәл өстенең буе 1 *м* 4 *дм*, иңе 9 *дм*, Өстәл өстенең мәйданын исәпләргә.

580. Тәрәзәнең биеклеге 1 *м* 9 *дм*, иңе 12 *дм*. Сорау куярга һәм мәсьәләне чишәргә.

581. Безнең класс ишегенең иңе ..., биеклеге ... . Үлчәгез һәм ишекнең мәйданын табыгыз.

582. Колхозга план буенча буе 1 *км*, иңе 600 *м* лы участокка бәрәңге утыртырга кирәк. Әгәр 1 *га* га 2 *т* бәрәңге утыртсалар, колхоз күпме орлыклык бәрәңге хәзерләргә тиеш?

583. Болынның буе 1 *км* 875 *м*, иңе 1 *км* 632 *м*. Һәр гектардан 120 *ц* үлән чабып алдылар. Әгәр 24 *ц* үләннән 5 *ц* печән чыкса, бу болыннан ничә тонна печән чыккан?

584. Буе 1 *км* 250 *м*, иңе 24 *м* лы урамны асфальт белән капладылар, шуның белән бергә һәр 100 *кв. м* га 3 *т* 900 *кг* асфальт тоттылар. Барысы ничә тонна асфальт тотканнар?

585. Бүлмәнең идәне квадрат формасында, аның ягы 7 *м* 50 *см* га тигез. Әгәр квадрат плитканың ягы 15 *см* булса, бу бүлмәнең идәненә җәю өчен ничә плитка кирәк булыр?

586. Кошлар туйдыру өчен иң простой җимлек — буе һәм иңе 45 шәр *см* лы такта. Әгәр почмаклары туры булса, бу такта нинди формада? Аның мәйданы нинди?

587. Бер төп чөгендер өчен ягы 30 *см* лы квадрат формасындагы мәйдан кирәк. 7 200 *кв. м* мәйданга ничә төп чөгендер үрентесе утыртып була?

588. Буе 1 *км* 560 *м* һәм иңе 750 *м* лы участокка чөгендер утыртылган. 1 *га* да үстерелгән чөгендердән 25 *ц* шикәр эшләп чыгаралар. Бу участокта утыртылган чөгендердән күпме шикәр алырлар?

589. Яшь натуралистлар 1 *га* га 2 *ц* исәбеннән 12 *кв. м* лы участокка борчак чәчкәннәр. Чәчелгәнгә караганда, 16 тапкыр артыграк уңыш алганнар. Яшь натуралистлар ничә килограмм борчак җыеп алганнар?

590. Буе 48 *см*, ә иңе 36 *см* лы картонны, һәрберсенең буе 16 *см* һәм иңе 12 *см* лы кисәкләргә ваклаганнар. Ничә кисәк килеп чыккан?

591. Буе 80 *см*, иңе 64 *см* лы бер табак пыяладан буе 32 *см*, иңе 30 *см* лы һәм буе 50 *см*, ине 32 *см* лы пыялалар кисеп алырга кирәк. 1 *см* да 8 *м* масштабы белән сызым ясарга һәм бер табак пыяланы ничек кисәргә икәнен тамгаларга.

592 Түбәндәге бирелмәләр буенча турыпочмаклыкның мәйданын исәпләргә:

1) буе 86 *м*,	иңе 48 *м*
2) „ 76 *м*,	„ 50 *см*
3) „ 8 *м* 50 *см*,	„ 4 *м* 8 *см*

593. Таблицаны күчереп алырга һәм соңгы графаны тутырырга.

Турыпочмаклыкның буе	Турыпочмаклыкның ине	Мәйданы гектарлар белән
840 *м*	750 *м*	
2 *км*	120 *м*	
1 *км* 700 *м*	1 *км* 200 *м*	
7 *км* 200 *м*	2 *км* 500 *м*	
6 *км* 250 *м*	1 *км*	

594. Түбәндәгечә чишелә торган мәсьәлә төзергә:

400 *кв. м* × 250 = 100 000 *кв. м* = 10 *га*

595. 23 нче рәсемдә күрсәтелгән үлчәмнәр буенча һәр культура алып торган мәйданны исәпләргә.



23 нче рәсем.

596. Җир участогының планы (24 нче рәсем) 1 *см* да 50 *м* масштабы белән сызылган. Участокның буен, иңен һәм мәйданын исәпләргә.



Масштаб : 1 см дә — 50 м

24 нче рәсем.

597. Турыпочмаклыкларның (25 нче рәсем) мәйданын күздән чамалап билгеләргә һәм җавапның дөреслеген үлчәп һәм исәпләп тикшерергә.



25 нче рәсем.

598. Алмагач яфрагы ничә квадрат берәмлекне алып тора икәнен якынча исәпләргә (26 нчы рәсем).

26 нчы рәсем.

Кабатлау өчен сораулар.

1) Квадрат дип нәрсә атала?

2) Мәйдан үлчәүлекләрен әйтергә. Аларны таблица рәвешендә язарга.

3) Җир мәйданнарын үлчәү өчен нинди үлчәүлекләр кулланыла?

4) Турыпочмаклыкның мәйданын ничек исәпләргә? Квадратның мәйданын ничек исәпләргә?

5) Турыпочмаклыкның мәйданын исәпләүгә мәсьәлә төзергә һәм аның чишелешен язарга.

Мәсьәләләр[1].

599. 1) 10 *л* сөттән 1 бидон каймак һәм шундый 4 бидон өсте алынган сөт чыккан (27 нче рәсем). Өсте алынган сөт ничә литр?

27 нче рәсем.

2) Сөттән бер өлеш каймак һәм шундый 4 өлеш өсте алынган сөт чыккан. 25 *л* сөттән күпме каймак һәм күпме өсте алынган сөт чыгар? 40 *л* сөттән? 60 *л* сөттән?

600. Ике малай бергә 120 чикләвек җыйдылар һәм берсенә бер өлеш, ә икенчесенә 2 өлеш тиярлек итеп, үзара бүлделәр. Һәр малайга ничә чикләвек тигән?

601. Рәсемне тикшереп карагыз һәм түбәндәге сорауларга җавап бирегез:

28 нче рәсем.

[1] 599 дан 621 гә кадәрге мәсьәләләр—суммасы һәм чагыштырмасы буенча ике санны табуга булган мәсьәләләр.

1) Сул якта ничә каләм? 2) Әгәр 4 каләмне бер өлеш дип кабул итсәк, уң яктагы каләмнәр ничә өлешне төзерләр? Барлык каләмнәр барысы ничә өлешне төзиләр?

602. Чиләккә тоткыч ябыштыру өчен балалар „Булдыклы куллар“ түгәрәгендә 2 өлеш кургаш һәм бер өлеш аккургаштан торган 117 *г* эретмә хәзерләделәр (29 нчы рәсем). Бу эретмәгә ничә грамм кургаш һәм ничә грамм аккургаш кергән?

29 нчы рәсем.

603. Клейстер хәзерләү өчен 1 өлеш крахмал, 1 өлеш салкын су һәм шундый 13 өлеш кайнар су алдылар. Һәрберсендә 250 шәр граммлы 3 стакан клейстер хәзерләделәр. Ничә грамм крахмал алганнар?

604. Столярлык клейе хәзерләү өчен, балалар 8 өлеш плиткалы коры клей алдылар һәм аңа 9 өлеш су куштылар (30 нчы рәсем). Әгәр коры клейне 40 *г* алган булсалар, ничә грамм су кушканнар?

30 нчы рәсем.

605. Завод 780 *т* бутылка пыяласы эшләп чыгарырга тиеш. Пыяла хәзерләгәндә 100 өлеш комга 36 өлеш сода һәм 20 өлеш известь китә. Заводка ничә тонна ком кирәк булыр?

606. Торф-черемә чүлмәкләр 7 өлеш торф һәм 2 өлеш черемә катнашмасыннан ясалалар. Шундый 1 *т* катнашмадан 2 500 чүлмәк хәзерләп була. 4 500 000 чүлмәк ясау өчен күпме торф хәзерләргә кирәк?

607. 1) Яшелчә бакчасының бер өлешен кәбестә утырту өчен һәм шундый ук өч өлешен бәрәңге утырту өчен аерып куйдылар. Бер мәйдан икенчесеннән ничә тапкыр зуррак?

2. Яшелчә бакчасының 600 *кв. м* га тигез мәйданына кәбестә һәм бәрәңге утыртылган. Бәрәңге утыртылган җир, кәбестә утыртылган җиргә караганда, 3 тапкыр зуррак. Ничә квадрат метрга кәбестә һәм ничә квадрат метрга бәрәңге утыртылган.

608. Паркта барысы 900 төп каен һәм юкә агачлары үсә, шуның белән бергә каен, юкәгә караганда, 5 тапкыр артыграк. Паркта ничә төп каен һәм ничә төп юкә үсә?

609. Пионерларга 200 *кг* металл ватыгы җыярга задание бирелгән. Өлкән пионерларга, кечкенәләргә караганда, 3 тапкыр артыграк җыю тапшырылган. Кечкенәләр һәм өлкән пионерлар ничәшәр килограмм тимер ватыгы җыярга тиешләр?

610. Пионерларның ике отряды 258 төп агач утыртканнар. Беренче отряд, икенчесенә караганда, 2 тапкыр артыграк утырткан. Һәр отряд аерым-аерым ничәшәр төп агач утырткан?

611. Москвадагы бер мәктәпнең пионерлары Себер һәм Уралдагы мәктәп укучылары белән язышалар. Бер елда алар барлыгы 42 хат алганнар. Себер укучыларыннан алынган хатлар саны Уралдан алынган хатлардан 2 тапкыр артыграк. Себердән һәм Уралдан аерым-аерым ничә хат алынган?

612. Колхозда 125 сыер һәм 100 бозау өчен 6 000 *ц* силос хәзерләнгән. Барлык сыерларга, барлык бозауларга караганда, 5 тапкыр артыграк силос хәзерләгәннәр. Һәр сыерга һәм һәр бозауга күпме силос хәзерләнгән?

613. Ирләр костюмы һәм хатын-кыз күлмәге тегү бергә 240 сум тора. Күлмәк тегү, ирләр костюмы тегүгә караганда, 2 тапкыр арзанрак тора. Һәр төр киемне тегү аерым-аерым күпме тора?

614. Буе 75 *м*, ә иңе 60 *м* булган мәктәп участогында яшелчә бакчасы һәм җимеш бакчасы ясаганнар, шуның белән бергә җимеш бакчасы өчен, яшелчә бакчасына караганда, өч тапкыр кимрәк мәйдан биргәннәр. Һәр төр бакчаның мәйданын табарга.

615. Колхоз бер басудан 294 *ц*, ә икенчесеннән 180 *ц* артыграк бодай җыеп алган. Бодайны чистарткач, сортлы бөртек, сортсыз бөртеккә караганда, 5 тапкыр артыграк икәне күренгән. Ике басудан колхоз күпме сортлы бөртек җыеп алган?

616. Ике артель 5 540 пар чаңгы хәзерләргә тиеш булганнар. Беренчесе 1 835 пар, ә икенчесе 325 пар чаңгы хәзерләгәч, икенче артельгә, беренчегә караганда, 3 тапкыр артыграк чаңгы хәзерлисе калган. Һәр артель ничә пар чаңгы хәзерләгән?

617. 31 һәм 32 нче рәсемнәр буенча мәсьәләләр төзергә:



31 нче рәсем.



32 нче рәсем.

618. Түбәндәгечә чишелә торган мәсьәлә төзергә:

1) 1 өл. + 2 өл. = 3 өл.
2) 60 сум : 3 = 20 сум
3) 20 сум × 2 = 40 сум

Җавап. Галош 20 сум һәм ботинка 40 сум тора.

619. Бирелгән санны, бер кисәге икенчесеннән берничә тапкыр кимрәк булырлык итеп, ике кисәккә бүлү соралган мәсьәлә төзергә.

620. Түбәндәге саннарның һәрберсен, бер кисәге икенчесеннән 23 тапкыр зуррак булырлык итеп, кисәкләргә бүләргә:

1 968; 72 168; 50 409 600.

621. 32 *см* озынлыгындагы картон полосканы, бер кисәге икенчесеннән 7 тапкыр кимрәк булырлык итеп тамгаларга.

622. 609 һәм 611 нче мәсьәләләр бирелмәләре буенча диаграммалар төзергә.

Кубик үлчәүлекләр.

Күләм исәпләү.

Безне әйләндереп алган предметлар арасында бер формадагы предметлар күп, мәсәлән: ящиклар, шкафлар, кирпечләр, брусоклар, шырпы тартмалары. һәм ш. о. Әйтелеп узган предметларның барысының өч үлчәме бар: буй, иң һәм биеклек.

Шундый һәрбер предметның сыйдырышы яки күләме бар. Күләмнәр яки сыйдырышлар төрле зурлыкта булырга мөмкин. Мәсәлән, бүлмәнең күләме шкаф күләменнән зуррак, кирпечнең күләме ящик күләменнән кечкенәрәк, шырпы тартмаларының күләмнәре үзара тигез.

Күләмнәрне үлчәү өчен кубик үлчәүлекләр хезмәт итәләр.

Куб алты кыр белән чикләнгән Кубның һәр кыры квадрат формасында. Кубның барлык кырлары үзара тигез. Куб кырларының яклары **кабыргалар** дип аталалар. Кубның 12 кабыргасы бар. Кубның барлык кабыргалары үзара тигез. Кубның 8 түбәсе бар.

Кабыргасы 1 *м* га тигез булган кубның күләме **куб метр** дип атала.

Кабыргасы 1 *дм* га тигез булган кубның күләме **куб дециметр** дип атала.

Кабыргасы 1 *см* га тигез булган кубның күләме **куб сантиметр** дип атала.

623. Куб турында (33 нче рәсем) сөйләгез; аның кырларын, кабыргаларын, түбәләрен күрсәтегез. Куб рәсемен ясагыз. Чөгендердән яки бәрәңгедән куб кисеп алыгыз.



33 нче рәсем.

624. 34 нче рәсемдә куб җәелмәсе бирелгән. Бу үрнәк буенча кабыргасы 1 *дм* га тигез булган кубның җәелмәсен ясагыз. Аны кисеп алыгыз һәм куб ябыштырыгыз. Мондый кубның күләме күпмегә тигез?



34 нче рәсем.

625. Шырпы тартмасының, шкафның, ящикның, бүлмәнең буен, иңен һәм биеклеген күрсәтегез.

626. Буе 4 *см*, иңе 3 *см* һәм биеклеге 2 *см* лы картон коробканы куб сантиметрлар белән тутырыгыз һәм моның өчен ничә кубик кирәк булганын санагыз.

627. 35 нче рәсемдәге бирелмәләр буенча ящикның күләмен исәпләргә.



35 нче рәсем.

628. Көнелдән куб метрлар белән тутырып, класс бүлмәсенең күләмен исәпләргә.

629 Үлчәмнәре түбәндәгечә булган тартмага ничә куб сантиметр урнашыр:

1) тартманың буе 8 *см*, иңе 1 *см*, биеклеге 1 *см*;
2) „ „ 6 *см*, „ 4 *см*, „ 1 *см*;
3) „ „ 10 *см*, „ 8 *см*, „ 5 *см*.

Ящик, тартма, бүлмә һәм шуңа охшашлы предметның күләмен исәпләү өчен, бер үк үлчәүлек белән аның буен, иңен һәм биеклеген үлчәргә һәм килеп чыккан саннарны бер-беренә тапкырларга кирәк. Тапкырчыгышта һәрвакыт кубик үлчәүлекләр чыга.

630. Класс бүлмәсенең буе 7 *м*, иңе 5 *м*, биеклеге 4 *м*. Класс бүлмәсенең күләмен табарга.

Чишү. 7 *куб м* $\times 5 \times 4 = 140$ *куб м*.



36 нчы рәсем.

631 Сарайның буе 16 *м*, иңе 10 *м*, биеклеге 5 *м*. Сарайның күләме күпмегә тигез (түбәгә кадәр)? (36 нчы рәсем.)

632. 1) Буе 8 *м*, иңе 6 *м* һәм биеклеге 5 *м* лы класс бүлмәсендә 40 бала укый. Бер укучыга ничә куб метр һава туры килә?

2) Сезнең класста бер укучыга ничә куб метр һава туры килә икәнен исәпләргә.

633. Буе 21 *м*, иңе 12 *м* һәм биеклеге 5 *м* булган цехта 28 эшче эшли. Бер эшчегә ничә куб метр һава туры килә?

634. Буе 12 *м*, иңе 5 *м* һәм биеклеге 3 *м* лы сарай печән белән тутырылган. Әгәр 1 *куб м* печән 60 *кг* килсә, бу сарайда күпме печән бар?

635. Кладовой куб формасында, аның кабыргасы 4 *м*. Кладовойның күләмен исәпләргә.

636. Аквариум (37 нче рәсем) куб формасында, аның кабыргасы 70 *см*. Аны 50 *см* биеклеккә кадәр су белән тутырганнар. Ничә куб сантиметр урын су белән тутырылмыйча калган?



37 нче рәсем.

637. Металлдан ясалган кубның кабыргасы 10 *см*. 1 *куб см* ы 8 *г* килсә, бу куб нинди авырлыкта булыр?

638 Квартирада 3 бүлмә бар. Түбәндәге бирелмәләр буенча һәр бүлмәнең идән мәйданын һәм күләмен исәпләргә, ә соңыннан барлык квартираның гомуми күләмен табарга.

Бүлмәләр №№	Буй	Ин	Биеклек	Идән мәйданы	Күләм
1	8 *м*	6 *м*	4 *м*		
2	7 *м*	5 *м*	4 *м*		
3	4 *м*	4 *м*	4 *м*		

639. 1) Узган мәсьәлә үрнәге буенча мәктәпнең яки нинди дә булса йортның аерым бүлмәләренең һәм бөтен бинасының мәйданын һәм күләмен исәпләргә.

Кабыргасы 4 *м* лы кубның күләмен исәпләргә; 8 *дм* лы кубның; 11 *см* лы кубның; 1 *м* 5 *дм* лы кубның.

640. 1) Куб дециметрны (кечерәйтелгән) күрсәтүче 38 нче рәсемне җентекләп тикшерегез һәм анда ничә куб сантиметр бар икәнен санагыз.



38 нче рәсем.

2) Куб метрның күләмен тутыру өчен, ничә куб дециметр кирәк булыр?

Күрсәтмә. Башта бер катлауда ничә куб дециметр булуын, ә аннан соң ничә катлау икәнен санагыз.

Кубик үлчәүлекләр таблицасы.

1 *куб м* = 1000 *куб дм*
1 *куб дм* = 1000 *куб см*
1 *куб см* = 1000 *куб мм*
1 *куб м* = 1 000 000 *куб см*

641. 3 *куб м* да ничә куб дециметр? 5 *куб м* да? 12 *куб м* да? 8 *куб м* да? 2 *куб м* 500 *куб дм* да?

642. 6 *куб дм* да ничә куб сантиметр? 10 *куб дм* да? 16 *куб дм* да? 9 *куб дм* 800 *куб см* да?

643. 4 *куб см* да ничә куб миллиметр? 7 *куб см* да? 12 *куб см* да? 5 *куб см* да? 7 *куб см* 280 *куб мм* да?

644. Тагы да эрерәк үлчәүлекләр белән аңлатырга:

1 000 *куб дм*	1 000 *куб ом*	1 000 *куб мм*
4 000 *куб дм*	6 000 *куб см*	5 000 *куб мм*
9 500 *куб дм*	7 648 *куб см*	3 118 *куб мм*
35 800 *куб дм*	90 126 *куб см*	67 500 *куб мм*
198 725 *куб дм*	1 276 000 *куб см*	38 600 *куб мм*

645. Колхоз буе 67 *м* 5 *дм*, иңе 24 *м*, тирәнлеге 2 *м* лы буа казыды. Чыгарылган балчыкны машиналар белән ташыдылар, шуның белән бергә һәр машина 3 *куб м* төяп 60 рейс ясады. Балчык ташу өчен ничә машина кирәк булган?

646. Әгәр 1 *куб м* бөртек 700 *кг* килсә, ящигының буе 4 *м*, ине 1 *м* 25 *см*. һәм тирәнлеге 80 *см* булган машинада күпме бодай илтергә мөмкин?

647. Буе 12 *м*, иңе 5 *дм*, биеклеге 24 *м* лы кирпеч стена салырга кирәк. Әгәр бер куб метр стенага 600 данә кирпеч китсә, моның өчен ничә данә кирпеч кирәк булыр? Әгәр эремә күләмнең биштән бере кадәр булса, бу стенаны салу өчен күпме эремә кирәк булыр?

648. (Телдән.) Су бозга әйләнгәндә аның күләме уннан бер өлешкә арта. 490 *куб м* су катканда килеп чыккан бозның күләмен исәпләргә.

649. (Телдән.) Спорт белән шөгыльләнми торган кешеләрнең үпкә сыемы якынча 3000 *куб см* га тигез, ә спортчыларда ул 5700 *куб см* га житә. Спортчыларның үпкә сыемы күпмегә артыграк?

650. Буе 7 *дм*, иңе 4 *дм*, биеклеге 35 *см* лы аквариумга 30 *см* биеклеккә кадәр су салганнар. Аквариумга ничә литр су салганнар?

Белешмә. 1 *л* 1 *куб дм* га тигез.

651. Ике тартма ясаганнар; берсенең буе 8 *см*, иңе 6 *см* һәм биеклеге 4 *см*, икенчесенең барлык үлчәмнәре ике тапкыр артыграк. Икенче тартманың күләме ничә тапкыр зуррак?

652 Буе 10 *м* һәм иңе 6 *м* 4 *дм* лы мәйдан 3 *дм* калынлыкта кар белән капланган. Балалар карны буе, иңе һәм биеклеге 16 *дм*, 10 *дм*, 4 *дм* лы ящикка төяп, чана белән ташыйлар. Мәйдандагы барлык карны түгеп бетерү өчен ящикны ничә тапкыр тутырырга туры килер?

653. Фабрикада шикәрне буе 12 *см*, иңе 7 *см* һәм биеклеге 5 *см* лы пачкаларга тутырдылар, ул пачкаларны буе 6 *дм*, иңе 56 *см* һәм биеклеге 2 *дм* лы ящикларга салдылар. Шундый 100 ящикка ничә пачка шикәр салганнар?

654. (Телдән.) Колхоз буе 24 *м*, иңе 5 *м* һәм тирәнлеге 5 *м* лы турыпочмаклы чокырда сыерлар өчен силос хәзерләде. Әгәр 1 *куб м* силос 5 *ц* авырлыкта килсә, колхоздагы силос запасын исәпләргә.

655 Төзелешләрдә җир эшләре өчен атлап йөрүче экскаваторлар кулланалар (39 нчы рәсем). Андый экскаваторның чүмече бер тапкырда 14 *куб м* балчык ала һәм сәгатькә 45 тапкыр бушатыла. Экскаватор 16 сәгатьтә ничә куб метр җир казый? Әгәр 1 *куб м* балчык 14 *ц* авырлыкта килсә, казылып алынган барлык балчык ничә тонна булыр?



39 нчы рәсем.

656. 2 минутта 3 экскаватор 108 *куб м* грунт алып, читкә илтеп куя, ә җир казучы бер эшче сигез сәгатьлек эш көнендә 5 *куб м* грунт казый ала. Бер экскаваторның 8 сәгатьтә эшләгән эшен үтәү өчен ничә эшче кирәк булыр иде?

657. Түбәндәге бирелмәләр буенча брусның күләмен исәпләргә:

1) буе 80 *см*, иңе 12 *см*, биеклеге 8 *см*;
2) „ 1 *м* 20 *см*, „ 4 *дм*, „ 3 *дм*;
3) „ 2 *м*, „ 60 *см*, „ 45 *см*.

658. 40 нчы рәсемдә күрсәтелгән ящикларның күләмнәрен чагыштырыгыз. Бер ящикның күләме икенче ящикныкыннан күпмегә артыграк яки кимрәк? Бер ящикның күләме икенчесенекеннән ничә тапкыр кимрәк?



40 нчы рәсем.

659. Түбәндәгечә чишелә торган мәсьәлә төзергә:

1) 12 *куб см* × 8 × 6 = 576 *куб см*
2) 15 *куб см* × 10 × 8 = 1200 *куб см*
3) 1200 *куб см* — 576 *куб см* = 624 *куб см*.

Җавап. Бер тартманың күләме икенчесеннән 624 *куб см* га зуррак.

660. 1) Бүлмәнең буе 8 *м*, иңе 5 *м*, ә биеклеге 4 *м*. Идәннең, түшәмнең, стеналарның мәйданын исәпләргә.

2) Кирәкле үлчәүләрне эшләп, үз классыгыз турында шундый мәсьәлә төзергә һәм чишәргә.

661. Буе 8 *м*, иңе 6 *м* һәм биеклеге 4 *м* лы бүлмәнең стеналарын һәм түшәмен агартырга, идәнен буярга кирәк. Түшәм һәм стеналарның 1 *кв м* ын агарту 60 тиен, ә идәннең 1 *кв м* ын буяу 6 сум 25 тиен тора. Барлык эш күпме тора? (Тәрәзә һәм ишекләр гомуми мәйданнан чыгарылмый.)

662. Мәсьәлә-расчёт: „Сезнең класс бүлмәсенең стеналарын һәм түшәмен агарту күпме тора?“

Расчёт өчен түбәндәге бирелмәләрне табыгыз:

Класс бүлмәсенең буе ...; иңе ...; биеклеге ...; 1 *кв м* ны агарту бәясе ... .

663. 1) Буе 10 *м*, иңе 6 *м*, биеклеге 3 *м* лы бүлмәнең стеналарына обой ябыштырырга булдылар. Бер кисәк обой 6 *кв м* стенага ябыштырырга җитә. Әгәр бер кисәк обой 4 сум 50 тиен торса, барлык обой күпме торыр?

2) Мәсьәлә-расчёт: „Мин торган бүлмәнең стеналарына ябыштыру өчен күпмелек обой кирәк булыр?“

Расчёт өчен кирәкле бирелмәләрне үзең тап.

664. Бина өчен буе 80 *м*, калынлыгы 5 *дм*, биеклеге 6 *м* лы кирпеч стена төзеделәр. Һәр куб метр стенага 500 кирпеч китте. Барлык кирпечне ике көндә китерделәр, шуның белән бергә беренче көнне, икенче көндәгегә караганда, 3 тапкыр артыграк китерделәр. Беренче һәм икенче көнне ничә кирпеч китергәннәр?

665. Класс бүлмәсендә шундый таблица эленеп тора (41 нче рәсем):

Классның буе	8 *м*
Классның иңе	6 *м*
Классның биеклеге	4 *м*
Идән мәйданы	48 *кв. м*
Классның күләме	192 *куб м*

41 нче рәсем.

Үз классыгыз өчен һәм үзегез торган бүлмә өчен шундый таблица ясагыз.

Кабатлау өчен сораулар.

1) Куб турында сөйләргә.

2) Күләм үлчәүлекләрен әйтергә. Аларны таблица рәвешендә язарга.

3) Ящикның күләмен ничек исәпләргә? Бүлмәнең күләмен?

4) Күләм исәпләүгә мәсьәлә төзергә һәм аның чишелешен язарга.

Кабатлау.

666. Телдән санагыз:

1) $16 + 18 - 17 + 83 - 52$
$80 - 36 + 42 - 36 + 48$
$15 + 26 - 12 + 71 - 64$

2) $80 + 56 - 21 + 85 - 66$
$156 - 76 + 92 - 35 + 63$
$73 + 72 - 48 + 34 - 32$

3) $87 \times 5 \times 2$
$72 \times 5 \times 2$
$28 \times 5 \times 4$
$26 \times 5 \times 6$

4) $56 \times 25 \times 4$
$48 \times 25 \times 4$
$27 \times 25 \times 8$
$18 \times 25 \times 8$

5) $75 \times 4 + 75 \times 6$
$84 \times 8 + 84 \times 2$
$92 \times 9 + 92 \times 1$
$57 \times 6 + 57 \times 4$

6) $90:5 + 90:18 + 5 \times 18$
$120:5 + 120:24 + 5 \times 24$
$160:5 - 160:32 + 5 \times 32$
$180:6 - 180:30 + 6 \times 30$

7) $490:70 + 560:80$
$640:80 - 720:90$
$360:40 + 420:70$
$630:90 - 300:50$

667. $65\,254 : 79 - 75\,369 \cdot 97 + 766\,506 : 951$
$460 \times 308 + 447\,480 : 132 - 398\,748 . 564$
$73\,689 \cdot 87 - 96\,064 : 158 + 310\,726 - 95\,437$
$76\,428 - 771\,840 : 192 - 209\,160 : 249$

668. Гамәлләрне эшләргә һәм дөреслеген тикшерергә:

5 *т* 83 *кг* + 4 *т* 96 *кг*
8 *км* 90 *м* — 1 *км* 85 *м*
3 *кг* 80 *г* — 1 *кг* 96 *г*
7 *км* 75 *м* — 2 *км* 85 *м*

38 сум 7 тиен × 56
15 *т* 90 *кг* × 53
73 *м* 80 *см* : 36
12 *кг* 96 *г* : 3 *кг* 24 *г*

669. Москва белән Рига арасы 945 *км*; бу шәһәрләрдән бер үк вакытта бер-беренә каршы ике поезд чыга. Москва поезды сәгатькә 55 *км*, Рига поезды 50 *км* тизлек белән бара. Поездлар Москвадан нинди ераклыкта очрашырлар?

670. Москвадан Харьковка кадәр 784 *км*. Харьковтан Москвага сәгатькә 42 *км* тизлек белән баручы поезд чыга.

2 сәгатьтән соң аңа каршы Москвадан сәгатькә 58 *км* тизлек белән баручы поезд чыга. Поездлар Харьковтан нинди ераклыкта очрашырлар?

671 Самолёт 10 сәгать очты. Беренче 6 сәгатьтә ул сәгатькә 300 *км*, ә калган вакытта сәгатькә 325 *км* тизлек белән очкан. Самолёт барлык араны нинди уртача тизлек белән очкан?

672. 12 автомашина белән станциядән мәктәпкә күмер китерделәр. 4 машинага 35 әр центнер, ә калганнарына 38 әр центнер төягәннәр. Бер машинага уртача күпме күмер туры килә?

673. 3 сәгать эчендә самолёттан 200 *га* мәйданга урман утырттылар. 12 сәгатьтә 3 самолёт белән ничә гектар мәйданга урман утыртырга мөмкин?

674. Яшь натуралистлар 50 *кв м* дан 200 *кг* помидор алдылар. Уңыш шундый булганда, 1 *га* дан ничә тонна помидор алып булыр? Ике юл белән чишәргә.

675 Балыкчылар бер көндә 46 *кг* 800 *г* чуртан һәм алабуга тоттылар. Чуртаннарның авырлыгы, алабугаларга караганда, 3 тапкыр артыграк булган. Һәр төр балыкны күпмешәр тотканнар?

676 Ике заводның эшчеләре һәм хезмәткәрләре өчен санаторий һәм ял йортларына 1859 путёвка бүленгән. Беренче завод 563, ә икенче завод 264 путёвканы файдалангач, беренче заводның, икенчегә караганда, 2 тапкыр артыграк путёвка аласы калган. Һәр заводка ничә путёвка бүленгән?

677. Өч кисемтә бирелгән (42 нче рәсем). Бу кисемтәләр өчен арифметик урта булган кисемтә сызарга.



42 нче рәсем.

678. Өч басудан бәрәңге җыеп алганнар. Икенче басудан 1312 *ц* бәрәңге алганнар. Бу, беренче басудан алганга караганда, 2 тапкыр кимрәк һәм, өченче басудан алганга караганда, 2 тапкыр артыграк. Өч басудан күпме бәрәңге җыеп алганнар?

679. Завод бер айда 3420 машина эшләргә задание алган. Беренче 12 көндә завод көнгә 135 әр машина эшләгән, ә аннан соң көнгә 15 машина артыграк эшләп чыгара башлаган. Завод заданиене ничә көнгә алдан үтәгән?

Белешмә: Айда 26 эш көне.

680. Самолёт 1920 *км* араны очып узарга тиеш. Бу ераклыкның дүрттән бер өлешен ул сәгатькә 240 *км* тизлек белән очкан. Барлык араны 7 сәгатьтә очып узу өчен, ул калган юлны нинди тизлек белән очарга тиеш?

681. Коридорның буе 16 *м*, иңе 5 *м*. Анда 5 тәрәзә бар. Һәр тәрәзәнең биеклеге 1 *м* 60 *см*, иңе 1 *м* 25 *см*. Коридор идәненең мәйданы барлык тәрәзәләр мәйданыннан ничә тапкыр артыграк?

682. Бирелгән план һәм масштаб буенча (43 нче рәсем) участокның чын буен һәм иңен, яшелчә бакчасы һәм җимеш бакчасының мәйданын исәпләргә.

43 нче рәсем.

683. Буе 30 *м*, калынлыгы 6 *дм*, биеклеге 8 *м* лы кирпеч стенаны сүттеләр. Һәр куб метр стена 2 *т* авырлыкта килә. Сүтелгән стенадан чыккан барлык материалны ташу өчен өч тонналы йөк машинасы ничә тапкыр барып кайтырга тиеш?

684. Саратовтан газ уздыргач, Москва өчен елга күмер 650 000 *т* га һәм утын 1 000 000 *куб м* га кимрәк китә башлады. Әгәр уртача 2 *куб м* утын 1 *т* авырлыкта килсә, хәзер Москвага ягулык ташу өчен 20 *т* йөк күтәрешле вагоннар күпмегә кимрәк кирәк?

Вакыт үлчәүлекләре.

Вакыт үлчәүлекләре таблицасы.

Гасыр 100 елга тигез.
Ел 12 айга тигез.
Простой елда 365 көн, кәбисә елда 366 көн.
Ай 30 яки 31 көнгә тигез (февральдә 28 яки 29 көн).
Тәүлек 24 сәгатькә тигез.
Сәгать 60 минутка тигез.
Минут 60 секундка тигез.

685. Тәртибе белән ай исемнәрен санап чыгарга һәм һәр айда ничә көн икәнен әйтергә.

686. 1956 нчы елга табель-календарь.

Атнаның көннәре	Январь	Февраль
Дүшәмбе	2 9 16 23 30	6 13 20 27
Сишәмбе	3 10 17 24 31	7 14 21 28
Чәршәмбе	4 11 18 25	1 8 15 22 29
Пәнҗешәмбе	5 12 19 26	2 9 16 23
Җомга	6 13 20 27	3 10 17 24
Шимбә	7 14 21 28	4 11 18 25
Якшәмбе	1 8 15 22 29	5 12 19 26

Табель-календарьны дәфтәргә күчереп языгыз, аны уку елы азагына кадәр дәвам иттерегез.

687. 1) Февральдә 1 нче число чәршәмбегә туры килгән. Бу айда аннан соңгы чәршәмбеләр кайсы числоларга туры киләләр?

2) 15 июнь җомга көн иде. 17 июньдә атнаның нинди көне булыр? 22 июньдә? 25 июньдә?

3) Календарь буенча, 1 апрельдән 20 майга кадәр ничә көн үтүен санагыз; 1 сентябрьдән 7 ноябрьга кадәр; 20 ноябрьдән 1 январьга кадәр.

688. Бирелгән үрнәк буенча (44 нче рәсем) өйдә үзегез өчен календарь ясагыз. Башта ай исемнәре өчен һәм атнаның көннәрен һәм числоны күрсәтү өчен ничә карточка кирәген санагыз.

44 нче рәсем.

689. Түбәндә IV класс укучысы Илдар Шакировның көнлек режимы бирелә:

7 сәг. — 8 сәг. 20 мин.	Йокыдан торам, иртәнге гимнастика ясыйм. Иртәнге ашны ашыйм. Мәктәпкә барам.
8 сәг. 30 мин. — 13 сәг.	Мәктәптә: дәресләр һәм җәмәгать эше.
13 сәг. 30 мин. — 14 сәг. 30 мин.	Көндезге ашны ашыйм, ял итәм, хуҗалыкта эшлим.
14 сәг. 30 мин. — 16 сәг.	Ачык һавада уйныйм.
16 сәг. — 18 сәг.	Дәресләр хәзерлим.
18 сәг. — 19 сәг. 30 мин.	Чәй эчәм. Ачык һавада ял итәм. Чәршәмбе көннәрне „Булдыклы куллар" түгәрәгендә шөгыльләнәм.
19 сәг. 30 мин. — 20 сәг.	Кичке ашны ашыйм.
20 сәг. — 21 сәг.	Укыйм.
21 сәг. — 21 сәг. 30 мин.	Йокыга хәзерләнәм һәм йокларга ятам.

Укучының һәр занятиегә күпме вакыты китүен исәпләргә.

Үз режимыгызны бу режим белән чагыштырып карагыз.

690. Иван Владимирович Мичурин үзенең көнен менә ничек булгән.

Ул иртән сәгать 5 тә торган. Сәгать 6 да иртәнге ашны ашаган. 7 дән 12 гә кадәр питомникта эшләгән. 12 дән 12 сәг. 30 минутка кадәр обед ашаган. Обедтан соң газеталар укыган һәм ял иткән. 15 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр питомникта эшләгән. 17 сәгатьтә чәй эчкән, ә 17 сәг. 30 минуттан 21 сәгатькә кадәр кабинетта эшләгән. 21 сәгатьтә кичке ашны ашаган һәм 22 сәгатьтә йокларга яткан.

Иван Владимирович питомникта һәм кабинетта көнгә ничә сәгать эшләгән?

Ваклау һәм эреләү.

691. „Булдыклы куллар“ түгәрәгендә занятиеләр 1 сәг. 15 минут дәвам иттеләр. Занятиеләр ничә минут дәвам иткәннәр?

692. Поезд Москвадан Владивостокка 9 тәүл. 4 сәг. барган. Поезд ничә сәгать юлда булган?

693. Вакларга:

1) айларга: 8 ел; 15 ел; 10 ел 10 ай; 12 ел 8 ай;

2) сәгатьләргә: 5 тәүл.; 12 тәүл.; 6 тәүл. 15 сәг; 20 тәүл. 20 сәг;

3) минутларга: 10 сәг.; 19 сәг.; 6 сәг. 30 мин; 15 сәг. 45 мин.;

4) секундларга: 8 мин.; 14 мин.; 7 мин. 15 секунд; 16 мин. 15 секунд.

694. 1) Тәүлектә ничә минут икәнен; 2) сәгатьтә ничә секунд икәнен исәпләргә.

695. Вакларга: 1) 18 сәг. 30 мин. 45 секундны — секундларга; 2) 7 атна 6 тәүл. 20 сәгатьне — сәгатьләргә.

696. Наилгә 10 яшь һәм 1 ай. Наил ничә сәгать гомер иткән?

Белешмә. 8 елны 365 әр көн, ә 2 елны 366 шар көн дип санарга.

697. Эшче станокны һәм эш алымын яхшыртты. Шуңа күрә ул норма буенча 30 сменага дип билгеләнгән заданиене 12 сменада үтәде. Эшче ничә сәгать вакытка экономия ясады? Ике юл белән чишәргә.

Белешмә. Смена 8 сәгать дәвам итә.

698. Дәресләрен хәзерләп бетергәч, Разия Саниягә: „Бүген мин өйгә бирелгән эшләрне 7 200 секундта үтәдем“, — диде, ә Сания аңа каршы: „Ә мин дәресләрне 2 сәгать эчендә хәзерләп бетердем“, — дип җавап бирде. Аларның кайсысы өйгә бирелгән эшләрне тизрәк үтәгән?

699. Кеше 36 миллион минут яши аламы?

700. Эрерәк үлчәүлекләргә әйләндерергә.

240 сәг.	900 мин.	960 секунд
384 сәг.	2 880 мин.	4 200 секунд
500 сәг.	4 345 мин.	9 860 секунд

701. 144 сәгатьтә ничә тәүлек? 3 600 секундта ничә сәгать?

702. Москва университетының яңа бинасында 45 000 бүлмә бар. Һәр бүлмәдә 1 әр генә минут булганда, бу бүлмәләрнең барысын йөреп чыгу өчен күпме вакыт кирәк булыр?

703. 20 секундта экскаватор 6 *куб. м* грунтны казып ала һәм читкә илтеп ташлый. Экскаватор 1 минутта ничә куб метр грунтны казып ала һәм читкә илтеп ташлый?

704. Машина 1 секундта елга төбеннән 6 *куб. м* юшкынны казып ала. 8 сәгатьтә ул күпме юшкынны казып алыр?

705. Эрерәк үлчәүлекләрдә аңлатырга:

20 050 секунд	18 270 мин.	50 000 сәг.
90 600 секунд	75 300 мин.	73 240 сәг.

Кушу һәм алу.

706. Бер араны чабып узу өчен, бер пионер 2 мин. 54 секунд, ә икенче пионер аннан 18 секунд артыграк вакыт уздырган. Икенче пионер бу араны күпме вакытта узган?

707. Машинист поездны бер шәһәрдән икенчесенә билгеләнгән вакыт эчендә алып барырга тиеш. Юлда 4 сәг. 45 мин. булгач, аңа тагы, барганга караганда, 2 сәг. 35 мин. артыграк юлда буласы калган. Машинист поездны бер шәһәрдән икенчесенә күпме вакытта китерергә тиеш булган?

708.

$$\begin{array}{r} +\begin{array}{r} 15 \text{ сәг. } 45 \text{ мин.} \\ 10 \text{ сәг. } 27 \text{ мин.} \end{array} \\ \hline 25 \text{ сәг. } 72 \text{ мин.} \\ \hline 1 \text{ тәүл. } 2 \text{ сәг. } 12 \text{ мин.} \end{array}$$

6 ел 5 ай + 8 ел 7 ай
3 ел 10 ай + 4 ел 8 ай
15 тәүл. 18 сәг. + 9 тәүл. 4 сәг.
2 тәүл. 14 сәг. + 7 тәүл. 10 сәг.
17 сәг. 47 мин. + 5 сәг. 13 мин.
12 сәг. 38 мин. + 19 сәг. 56 мин.
36 мин. 58 секунд + 23 мин. 2 секунд
15 мин. 46 секунд + 57 мин. 50 секунд

709.

36 мин. 28 секунд + 23 мин. 32 секунд
20 сәг. 46 мин. + 15 сәг. 30 мин.
14 ел 11 ай + 25 ел 10 ай
8 сәг. 56 мин. + 7 сәг.
9 мин. 57 секунд + 13 секунд
7 ел 10 ай + 6 ай

710. Асиягә 9 яшь 8 ай. Ул үзенең абыйсыннан 4 яшь 6 айга кечерәк. Абыйсының яшен табарга.

711. Стена газетасын хәзерләүгә укучылар бер көнне 1 сәг. 10 мин., икенче көнне, беренче көндәгегә караганда, 1 сәг. 15 мин. артыграк вакыт уздырдылар. Укучылар стена газетасын хәзерләүгә барысы күпме вакыт уздырдылар?

712. Пионерлар 3 көн колхозга печән җыюда булыштылар. Беренче көнне алар 1 сәг. 10 мин., икенче көнне аннан 30 минутка артыграк, ә өченче көнне, беренче һәм икенче көндәгенең икесенә караганда, 20 минутка артыграк эшләделәр. Пионерлар печән җыюда һәр көн уртача күпме вакыт эшләгәннәр? Мәсьәләнең шартын кыскача язарга.

713. (Телдән.)

1 ел — 4 ай	7 мин. — 15 секунд	15 ел — 5 ел 8 ай
8 ел — 7 ай	18 мин. — 56 секунд	30 тәүл. — 6 тәүл. 17 сәг.
1 тәүл. — 15 сәг.	1 сәг. — 24 мин.	22 сәг. — 18 сәг. 49 мин.
6 тәүл. — 18 сәг.	16 сәг. — 48 мин.	50 мин. — 26 мин. 33 секунд

714.

$$\begin{array}{r} -\,45 \text{ мин. } 50 \text{ секунд} \\ 15 \text{ мин. } 38 \text{ секунд} \\ \hline 30 \text{ мин. } 12 \text{ секунд} \end{array} \qquad \begin{array}{r} -\,12 \text{ сәг. } 18 \text{ мин.} \\ 4 \text{ сәг. } 50 \text{ мин.} \\ \hline 7 \text{ сәг. } 28 \text{ мин.} \end{array}$$

56 ел 10 ай — 28 ел 8 ай
24 ел 3 ай — 10 ел 9 ай
20 сәг. 36 мин. — 17 сәг. 28 мин.
16 сәг. 12 мин. — 15 сәг. 40 мин.

715. Алырга һәм дөреслеген тикшерергә:

28 тәүл. 21 сәг. — 15 тәүл. 13 сәг.
17 тәүл. 12 сәг. — 11 тәүл. 23 сәг.
50 мин. 50 секунд — 22 мин. 6 секунд
42 мин. 2 секунд — 40 мин. 9 секунд

716. 1) Ике кушылучының суммасы 32 сәг. 18 мин.; аларның берсе 1 сәг. 56 мин. Икенче кушылучы күпмегә тигез?

2) Өч кушылучының суммасы 30 тәүл. 22 сәг. Әгәр беренче һәм икенче кушылучыларны кушсаң, 20 тәүл. 15 сәг. була. Әгәр беренче һәм өченче кушылучыларны кушсаң, 18 тәүл. 17 сәг. була. Һәр кушылучыны табарга.

3) Кимүче 5 мин., киметүче 5 секунд. Аерманы табарга.

4) Кимүче 10 сәг. 40 мин., аерма 8 сәг. 58 мин. Бу бирелмәләр буенча нәрсә белергә мөмкин һәм нинди гамәл белән?

717. (Телдән.) Балалар җил тегермәне моделен 2 сәг. 45 мин. та ясадылар. Вакытның бер өлеше детальләрне эшләргә, ә калган 50 минуты модельне җыюга китте. Детальләрне эшләү өчен күпме вакыт киткән?

718. Укучы кыз ярышта 400 *м* ны 6 минутта йөзеп узды. Бу бөтенсоюз рекордыннан 26 секундка озаграк. Йөзү буенча бөтенсоюз рекордын табарга.

719. Бер детальне хәзерләү өчен эшче беренче көнне 2 сәг. 5 мин., ә икенче көнне 28 минутка кимрәк вакыт уздырды. Икенче көнне эшче детальне күпме вакытта хәзерләгән?

720. Эшче беренче детальне 4 мин. 10 секундта, ә унынчы детальне 2 мин. 58 секундта эшләде. Унынчы детальне эшләү өчен, эшче күпмегә кимрәк вакыт уздырды?

721. Абыйсына 12 яшь 8 ай. Ул, сеңелесенә караганда, 3 ел 10 айга олырак. Сеңелесенә ничә яшь?

722. 4 сәг. 38 мин. + 7 сәг. 46 мин. — 8 сәг. 45 мин.
9 мин. 16 секунд — 5 мин. 50 секунд + 6 мин. 7 секунд

723. 3 ай 12 тәүл. + 5 ай 15 тәүл. — 4 ай 28 тәүл.
6 тәүл. 12 сәг. — 2 тәүл. 20 сәг. + 5 тәүл. 8 сәг.

724. (Телдән.)

1) 40 минутка 40 минутны кушарга һәм алга таба да, 6 сәгатькә тулганчы, 40 ар минутны куша барырга.

2) 540 минуттан 60 минутны алырга һәм алга таба да, нуль чыкканчы 60 ар минутлап ала барырга.

3) 15 сәгатькә 15 сәгатьне кушарга һәм алга таба да, 5 тәүлек килеп чыкканчы, 15 әр сәгатьләп куша барырга.

725. Илдус планёр ясау өстендә өч көн эшләде (45 нче рәсем) һәм барысы 9 сәг. 40 мин. вакыт уздырды. Беренче һәм икенче көнне ул 5 сәг. 55 мин. вакыт уздырды, әгәр беренче һәм өченче көн уздырган вакытларны кушсаң, суммада 6 сәг. 20 мин. чыга. Илдус һәр көнне күпме вакыт эшләгән?

45 нче рәсем.

726. Лётчик өч көн эчендә 42 сәг. 50 мин. вакыт һавада булды. Беренче көнне ул 14 сәг. 30 мин., икенче көнне аннан 50 мин. ка кимрәк вакыт һавада булды. Лётчик өченче көнне күпме вакыт һавада булган?

727. Тимераякта шуучы өч кеше бер үк араны узуда ярышалар. Берсе бу араны 19 мин. 10 секундта, икенчесе 19 мин. 2 секундта, өченчесе 18 мин. 54 секундта узган. Өченче кеше, икенчегә караганда, күпмегә тизрәк узган? Беренчегә караганда?

---

728. Бер малай 21 сәгатьтә йокларга яткан, ә иртән 7 сәг. 15 минутта торган. Бу малай күпме вакыт йоклаган?

729. Кояш 6 да чыккан, ә 19 сәг. 8 минутта баткан. Көн озынлыгын исәпләргә.

730. Сакчы 22 сәгать 30 минутта дежурлык итә башлаган, ә 6 сәгать 30 минутта дежурлыктан киткән. Дежурлык күпме вакытка сузылган?

731. Бер кыз 21 сәг. 30 мин. та йокларга яткан. Әгәр 9 сәг. 30 мин. йокларга тиеш булса, ул кайчан торырга тиеш?

732. Поезд 23 сәг. 15 минутта Ленинградтан Москвага чыга һәм 10 сәг. 45 мин. юлда була. Ул Москвага кайчан килеп житкән?

733. Володя пионерлар лагерена 3 июньдә килде һәм анда 26 көн торды. Володя пионерлар лагереннан кайчан кайткан?

734. Поезд Ленинградтан Москвага иртән 8 сәгатьтә килде. Әгәр ул 12 сәгать юлда булган булса, Ленинградтан кайчан чыккан?

735. Кояш 19 сәгатьтә батты. Әгәр көн озынлыгы 12 сәг. 49 мин. булса, кояш кайчан чыккан?

736. Мәктәптә дәресләр 8 сәг. 30 минутта башлана. Укучы өйдән мәктәпкә кадәр баруга 25 мин. вакыт уздыра һәм мәктәпкә дәресләр башланудан 10 мин. алда килеп житә. Ул өйдән кайчан чыга?

737. Пионерлар сборы 17 сәгатьтә башланды һәм 1 сәг. 15 мин. дәвам итте. Сбор кайчан беткән?

738. Ленинград укучылары 12 февральдә кытай укучыларының 23 январьда Пекиннан җибәргән хатын алдылар. Хат Пекиннан Ленинградка кадәр ничә тәүлек барган?

Тапкырлау һәм бүлү.

739. (Телдән.)

1) 10 сәгатьтә ничә минут? 12 сәг. тә? 5 сәг. 40 мин. та? 8 сәг. 30 мин. та?

2) 96 сәгатьтә ничә тәүлек? 144 сәг. тә? 120 сәг. тә? 240 сәг. тә?

3) 6 минутта ничә секунд? 8 мин. та? 15 мин. та? 20 мин. та?

740.

$\times$ 6 ел 115 тәүл.
3
18 ел 345 тәүл.

$\times$ 12 сәг. 35 мин.
8
96 сәг. 280 мин.
4 тәүл. 4 сәг. 40 мин.

7 тәүл. 8 сәг. $\times$ 3
12 тәүл. 15 сәг. $\times$ 8
16 тәүл. 17 мин. $\times$ 5
5 ел 10 ай $\times$ 4

13 сәг. 50 мин. $\times$ 9
20 мин. 48 секунд $\times$ 6
40 мин. 15 секунд $\times$ 8
3 тәүл. 16 сәг. $\times$ 6

741. Москвадан Севастопольгә кадәр араны самолёт 4 сәг. 40 мин. та очып уза ала, ә бу араны поездда бару өчен 9 тапкыр артыграк вакыт кирәк. Москвадан Севастопольгә поезд белән күпме вакытта барып була?

742. Хат самолёт белән Москвадан Тбилисига кадәр 8 сәг. 25 мин. бара. Бу, тимер юлда баруга караганда, 8 тапкыр тизрәк. Москвадан Тбилисига кадәр хат тимер юл белән күпме вакытта бара?

743. 36 мин. 24 секунд $\times$ 30 = 18 сәг. 12 мин.

$\times$ 24 секунд
30
720 секунд

720 секунд : 60 секунд = 12 (мин.)

$\times$ 36 мин.
30
1080 мин.

1080 мин. + 12 мин. = 1092 мин.

1092 мин. : 60 мин. = 18 (сәг.)
− 1092
60
− 492
480
12 мин.

14 сәг. 56 мин. ×36
12 сәг. 28 мин. ×45
50 мин. 40 секунд ×20.
42 мин. 37 секунд ×59
18 тәүл. 15 сәг. ×96
10 тәүл. 16 сәг. ×30

744. 4 ай 15 тәүл. ×18
8 ел 9 ай ×24
3 тәүл. 10 сәг. ×60
4 тәүл. 23 сәг. ×90
5 сәг. 46 мин. ×48
8 сәг. 30 мин. ×70
11 мин. 31 секунд ×30
5 мин. 24 секунд ×80

745. (8 тәүл. 16 сәг. + 4 тәүл. 18 сәг.) ×36
(16 сәг. 10 мин. — 3 сәг. 20 мин.) ×40
(18 мин. — 5 мин. 42 секунд + 56 секунд) ×24

746. Тапкырчыгышны табарга:
1) тапкырланучы 6 сәг. 20 мин., тапкырлаучы 24;
2) тапкырланучы 3 *км* 75 *м*, тапкырлаучы 300.

747. Бер детальне эшләү өчен норма буенча 12 мин. вакыт бирелә, ә эшче бу детальне 10 мин. 30 секундта эшли. 40 детальне эшләгәндә эшче күпме вакытка экономия ясый?

748. Тукучы сусаны норма буенча каралган 8 секунд урынына 5 секундта алмаштыра башлады. Шундый алмаштыруны ул эш көне дәвамында 4 000 тапкыр эшли. Бер эш көнендә тукучы күпме вакытка (сәгать һәм минут) экономия ясый?

749. „Минут сәгатьне саклый“ икәнен күрсәтә торган бер мәсьәлә уйлап табарга.

750. Ике автомобиль, „Москвич“ һәм „Победа“, бер үк вакытта бер шәһәрдән 500 *км* ераклыктагы икенче шәһәргә чыгып китәләр. „Москвич“ һәр 25 *км* юлга, „Победа“га караганда, 2 мин. 45 секунд артыграк вакыт уздыра. „Москвич“ икенче шәһәргә, „Победа“га караганда, күпмегә соңрак барып житәр?

751. Пароход 10 тәүл. 16 сәгатьтә бер рейс ясый. Пароходны һәр рейска хәзерләү өчен тагы 32 сәгать вакыт китә. Пароход ничә тәүлектә 18 рейс ясар?

752. 10 сәг. 40 мин. та станциягә 32 вагон күмер килде. Комсомолецлар бригадасы, һәр вагонга уртача 5 мин. вакыт тотып, составны тиз генә бушаттылар, һәм бушаган вагоннарга, һәр вагонга уртача 7 минут вакыт биреп, агач төяде-

ләр. Шуннан соң вагоннар тоткарсыз озатылдылар. Вагоннар станциядән ничә сәгатьтә озатылганнар?

753. Түбәндәге мисалга мәсьәлә уйлап табарга:

(5 мин. 30 секунд — 3 мин. 50 секунд) × 10

754.

23 сәг.	5	7 тәүл.	12
3 сәг.	4 сәг. 36 мин.	168 сәг.	14 сәг.
180 мин.		48	
30		0	
0			

26 сәг. : 8	5 сәг. : 75	29 мин. : 15
15 тәүл. : 4	9 тәүл. : 12	18 мин. : 12
12 тәүл. : 9	4 ел : 24	20 ел : 16

755.

37 тәүл. 8 сәг. : 7	~~7 сәг. 28 мин. : 24~~
20 сәг. 15 мин. : 9	41 мин. 15 секунд : 75
2 тәүл. 9 сәг. : 5	39 тәүл. 14 сәг. : 38

756.

5 ел 4 ай : 8	16 сәг. 20 мин. : 35
18 сәг. 20 мин. : 4	22 сәг. 36 мин. : 12
48 мин. 36 секунд : 9	58 тәүл. 12 сәг. : 18

757. Укучы мәсьәләне 11 минутта, ә мисалны 2 тапкыр тизрәк чиште. Мәсьәләне һәм мисалны чишүгә барысы күпме вакыт киткән?

758. Йөзү спорты мастеры 200 *км* ны 28 сәгатьтә йөзеп узган. 1 *км* ны ул уртача күпме вакытта йөзеп узган?

759. Эшче 49 мин. 24 секундта 19 деталь эшли. Шундый 100 деталь эшләү өчен аңа күпме вакыт кирәк?

760. Тукран иртән 3 сәг. 30 минутта үзенең балаларына азык ташый башлый һәм 21 сәгатькә кадәр ташуында дәвам итә. Бу вакыт эчендә ул 300 очыш ясый. Тукранга һәр очыш өчен уртача күпме вакыт кирәк?

761. Ике малай түгәрәктә бер самолёт моделе ясыйлар. Берсе иртән килеп эшнең бер өлешен үти һәм күпме вакыт эшләгәнен билгеләп китә. Икенчесе кичен килә һәм, беренчесенә караганда, ике тапкыр артыграк вакыт биреп, модельне ясап бетерә. Алар икесе бергә 3 сәг. 45 мин. вакыт уздыралар. Һәр малай күпме вакыт эшләгән?

762. Контроль эш вакытында укучы 4 мисал һәм бер мәсьәләне 42 минутта чиште. Барлык мисалларга ул, мәсьәләгә караганда, ике тапкыр кимрәк вакыт бетерде. Бер мисалны чишүгә ул уртача күпме вакыт уздырган?

763. Велосипедистлар куышында иң яхшы велосипедист 187 *км* 200 *м* араны 4 сәг. 20 мин. эчендә узган. Бер велосипедистның сәгатьлек тизлеге күпмегә тигез?

764. Спортсмен 42 *км* 150 *м* араны 2 сәг. 30 мин. та йөгереп узган. Спортсменның сәгатьлек тизлеген табарга. Спортсменның тизлеген велосипедист тизлеге белән чагыштырыгыз.

Б е л е ш м ә. Велосипедистның уртача тизлеге сәгатькә 12 *км*.

765. 18 сәг. : 24 мин. 2 тәүл. : 30 мин.
15 мин. : 45 секунд 8 сәг. : 15 секунд
8 сәг. : 24 мин. 4 ел : 18 сәг.

30 мин. : 12 секунд
3 тәүл. : 36 мин.
30 сәг. : 24 мин.

766. 5 сәг. 24 мин. : 12 мин. =
5 сәг. 24 мин. = 324 мин.
324 мин. : 12 мин. = 27

40 мин. 30 секунд : 15 секунд 7 сәг. 30 мин. : 25 мин.
9 мин. 12 секунд : 24 секунд 4 сәг. 30 мин. : 18 мин.

767. 4 ел 7 ай : 11 ай 39 тәүл. 14 сәг. : 38 сәг.
8 тәүл. 3 сәг. : 15 сәг. 22 сәг. 36 мин. : 12 мин.

768. 18 мин. : 2 мин. 15 секунд =
18 мин. = 1080 секунд; 2 мин. 15 секунд = 135 секунд

```
_ 1080 секунд | 135 секунд
  1080        |------------
  ----------- | 8
     0
```

10 тәүл. : 2 сәг. 30 мин. 27 мин. : 2 мин. 15 секунд
17 сәг. : 3 сәг. 24 мин. 13 тәүл. : 4 тәүл. 8 сәг.

769. Буләргә һәм дөреслеген тикшерергә:

30 мин. : 7 мин. 30 секунд — 16 ел : 2 ел 8 ай

25 тәүл. : 8 сәг. 20 мин. — 38 тәүл. : 3 тәүл. 4 сәг.

770.

1 сәг. 30 мин. : 2 мин. 30 секунд

1 сәг. 25 мин. : 2 мин. 50 секунд

28 ел 8 ай : 3 ел 7 ай

20 тәүл. 6 сәг. : 3 тәүл. 9 сәг.

2 сәг. 39 мин. : 4 мин. 25 секунд

26 тәүл. 6 сәг. : 10 сәг. 30 мин.

20 сәг. 6 мин. : 2 сәг. 14 мин.

51 мин. 12 секунд : 6 мин. 24 секунд

771. 3 сәг. килеп чыксын өчен, ничә тапкыр 30 ар минут алырга кирәк? 3 мин. килеп чыксын өчен, ничә тапкыр 45 әр секунд алырга кирәк? 5 тәүлектә 12 сәгать ничә тапкыр бар?

772. Конвейердан һәр 24 мин. саен бер әзер трактор чыга. 2 сменада завод ничә трактор эшләп чыгара?

773. Совет инженерлары бәрәңгедән элек 30 сәгатьтә табыла торган крахмалны хәзер 15 минутта таба торган машина уйлап таптылар. Яңа машина аркасында крахмалны ничә тапкыр тизрәк таба башладылар?

774. Элек бер вагонны бушату өчен 6 сәгать вакыт уздыралар иде. Хәзер эшчеләр бушатуның яңа алымын кулланалар һәм вагонны 3 мин. та бушаталар. Хәзер 6 сәг. эчендә 40 ар вагонлы ничә поездны бушатып була?

775. Ничә тапкыр бар: 1) 6 мин. эчендә 1 мин. 30 секунд? 15 мин. эчендә? 2) 1 сәг. 40 мин. эчендә 5 мин.? 2 сәг. 30 мин. эчендә?

776. Токарь бер детальне эшләүдә 50 секунд вакытка экономия ясый, шуның аркасында ул көнлек норманы смена бетүдән 1 сәг. 40 минутка алданрак үти. Токарь бер детальне эшләү өчен күпме вакыт уздырган?

Б е л е ш м ә. Смена 8 сәгать дәвам итә.

777. Бригада паровозны сәгать 7 дә ремонтларга кереште һәм 12 сәг. 20 мин. та ремонтлап бетерде. Норма буенча бу эшкә 16 сәгать вакыт бирелә. Эш ничә тапкыр тизрәк үтәлгән?

778. Пионерлар отряды ике көн буена колхозга агачларны кышка хәзерләргә — аларның кәүсәләрен буярга булышты. Беренче көнне отряд 1 сәг. 40 минутта 45 төп агачның кәү-

сәсен буяды. Әгәр отряд икенче көнне 3 сәг. 20 мин. эшләгән булса, ул көнне ничә агачның кәүсәсен буяган?

779. 1 сәг. 5 мин. та бакка 140 чиләк су тутырдылар. 2 сәг. 10 минутта ничә чиләк су тутырырга мөмкин?

780. Бер үк араны бер йөзүче 7 мин. 45 секундта, икенчесе 15 мин. 30 секундта йөзеп узды. Беренче йөзүче ничә тапкыр кимрәк вакыт уздырган?

781. 1 *км* ны поезд 1 мин. 25 секундта, ә велосипедист 4 мин. 15 секундта уза. 1 *км* юл узу өчен велосипедист, поездга караганда, ничә тапкыр күбрәк вакыт уздыра?

782. Заводта өйрәнчек 66 минутта 4 деталь, ә мастер 55 минутта шундый 10 деталь эшләгән. Бер детальне эшләү өчен мастер ничә тапкыр кимрәк вакыт уздырган?

783. Тапкырлаучыны табарга:

1) ике санның тапкырчыгышы 94 тәүл. 12 сәг., тапкырланучы 6 тәүл. 18 сәг.;

2) ике санның тапкырчыгышы 74 сәг. 48 мин., тапкырланучы 3 сәг. 24 мин.

Метрик үлчәүлекләр һәм вакыт үлчәүлекләре өстендә барлык гамәлләр.

784. 1) 15 *м* 38 *см* + 18 *м* 76 *см*
13 сәг. 56 мин. + 15 сәг. 28 мин.
18 *км*. 40 *м* — 6 *км* 270 *м*
20 тәүл. 16 сәг. — 7 тәүл. 18 сәг.

2) 17 *ц* 64 *кг* : 1 *ц* 26 *кг* 8 *кг* 370 *г* × 68
16 тәүл. 6 сәг. : 1 тәүл. 6 сәг. 15 мин. 40 секунд × 56

785. 18 ел 11 ай + 12 ел 9 ай
11 мин. 35 секунд — 3 мин. 52 секунд
7 *т* 326 *кг* + 2 *т* 674 *кг*
65 сум 4 тиен — 25 сум 8 тиен

786. 12 тәүл. 16 сәг. × 42 14 сәг. 24 мин. : 48 мин.
15 *т* 60 *кг* × 38 52 сум 48 тиен : 64 тиен

787. 1) Әгәр бүленүче 26 тәүл., бүлүче 16 сәг. булса, өлешне табарга; бүленүче 18 ел, бүлүче 9 ай булса?

2) Бүлүче 1 мин. 46 секунд, өлеш 84 булса, бүленүчене табарга.

3) Бүленүче 15 сәг. 50 мин., өлеш 38 булса, бүлүчене табарга.

788. Балалар елга буйлап көймәдә йөриләр һәм 2 сәг. 15 мин. эчендә бер пунктган икенчесенә баралар һәм борылып кайталар. Алар агым уңаена, агымга каршы йөзүгә караганда, 2 тапкыр тизрәк баралар. Балалар агым уңаена күпме вакыт һәм агымга каршы күпме вакыт йөзгәннәр?

789. Турист-пионерлар биек тауга күтәрелү һәм төшүгә 1 тәүл. 6 сәг. вакыт уздырганнар. Тау төшүгә, менүгә караганда, 3 тапкыр кимрәк вакыт киткән. Алар күпме вакыт күтәрелгәннәр һәм күпме вакыт таудан төшкәннәр? Чишелешнең дөреслеген тикшерергә.

790. Укучы китапны 5 көндә укып чыккан, шуның белән бергә 2 көн ул көнгә 1 сәг. 30 ар минут, 2 көн — 1 сәг. 15 әр минут һәм 1 көнне 2 сәгать укыган. Укучы көнгә уртача күпме вакыт укыган?

791. Тракторист эш көнен 7 сәгатьтә башлаган һәм 18 сәг. 30 мин. та бетергән. 3 *га* мәйданны сөрү өчен аның 3 сәг. 20 мин. вакыты киткән. Ул 1 сәг. 30 мин. ял иткән. Тракторист көнгә ничә гектар сөргән?

792. Өч тонналы машинаны кулдан 35 минутта төйиләр иде. Механик төягеч уйлап тапкач, төяү вакыты 7 тапкыр кыскарды. Колхозның элеваторга 1800 *т* бөртекле ашлык илтәсе бар. Әгәр бу ашлыкны өч тонналы машиналарда илтсәләр, шундый механик төягеч кулланып, колхоз күпме вакытка экономия ясар?

793. 6 ай эчендә төньяк полюс янындагы зур боз кисәге 1166 *км* 400 *м* га урыныннан күчте. Боз кисәге бер айда уртача күпмегә күчте? бер тәүлектә? бер сәгатьтә? бер минутта?

---

794. 1) Ай башыннан алып тулы 8 тәүлек узгач, айның ничәнче числосы килә? 14 тәүл. узгач? 25 тәүлек узгач?

2) Айның 6 числосына кадәр ай башыннан алып ничә тәүлек узган? 15 числосына кадәр? 22 числосына кадәр?

795. 1) Ел башыннан алып 3 ай узгач, нинди ай килә? 7 ай узгач? 10 ай узгач?

2) Ел башыннан алып 1 июльгә кадәр ничә ай узган? 1 сентябрьгә кадәр? 1 декабрьгә кадәр?

796. Пионерлар лагерен 1 июньдә ачтылар, 2 ай 28 көннән соң яптылар. Пионерлар лагерен кайчан яптылар?

797. Жәйге каникуллар 1 июньдә башландылар, 31 августта беттеләр. Жәйге каникуллар күпме вакыт дәвам итте?

798. Москва өлкәсендә урман тавыгы һәм божырлар аулау 15 августтан 1 ноябрьга кадәр рөхсәт ителә. Бу кошларны аулау ничә көнгә рөхсәт ителә?

799. Кышкы каникуллар 12 көн дәвам иттеләр һәм 10 январьда беттеләр. Каникуллар кайчан башланган?

800. Терлекләрне кышлату 6 ай дәвам итте һәм 15 апрельдә бетте. Терлекләрне кышлату кайчан башланган?

801. Сабан бодаен жыю 10 июльдә башланды. Әгәр чәчүдән урып-жыюга кадәр 3 ай вакыт узган булса, бодайны кайчан чәчкәннәр?

802. Елга 10 апрельдә боздан әрчелде һәм 17 ноябрьда боз белән капланды. Елганың ачылуы белән катуы арасында күпме вакыт узган?

803. 1) Без ничәнче йөздә яшибез?

2) Ел саный башлаганнан алып, хәзерге көнгә кадәр ничә йөз узган?

3) Бу йөзнең азагына кадәр ничә ел кала?

4) Ел саный башлаганнан алып 1954 тулы ел узды. Нинди ел башланды.

804. 1) Москва 1147 елда салынган. Куликов сугышы 1380 елда булды. Декабристлар восстаниесе 1825 елда булды. Бу вакыйгаларның һәрберсе кайсы гасырда (йөздә) булган?

2) Бөек Октябрь социалистик революциясе кайсы елны булды? Ел саный башлаганнан алып, Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр ничә йөз ел (гасыр) узган?

805. А. М. Горький 1868 елда туган һәм 68 ел яшәгән. А. М. Горький кайсы елны үлгән?

806. Л. Н. Толстой 1828 елны туган һәм 82 ел яшәгән. Л. Н. Толстой кайсы елны үлгән?

807. Атаклы рус уйлап табучысы А. С. Попов 1895 елда радиотелеграфны уйлап тапкан. Бу уйлап табудан соң ничә ел вакыт узган?

808. А. С. Пушкин 1799 елда туган, 1837 елда үлгән. А. С. Пушкин ничә ел яшәгән?

809. Укучы 10 ел укып, урта мәктәпне 1955 елда тәмамлады. Ул мәктәпкә ничәнче елны кергән?

810. Иван Владимирович Мичурин, 80 ел яшәп, 1935 елда үлде И. В. Мичурин кайсы елда туган?

811. Мин ... елда тудым. Хәзер ... нче ел бара. Миңа ничә яшь?

812. Безнең шәһәр (авыл) ... елда салынган. Безнең шәһәр (авыл) ничә ел яши?

813. Тәүлек азагына кадәр калган вакытка караганда, тәүлек башыннан алып өч тапкыр артыграк вакыт узган булса, хәзер ничә сәгать?

814. Төш вакытыннан алып узган вакыт, төн уртасына кадәр калган вакыттан 2 тапкыр артыграк булса, хәзер ничә сәгать?

815. 1) Башлану һәм бетү вакытлары буенча вакыйганың дәвамын, 2) башлану һәм вакыйганың дәвамы буенча вакыйганың бетү вакытын, 3) вакыйганың дәвамы һәм бетү вакыты буенча вакыйганың башлану вакытын белү соралган мәсьәләләр төзергә.

Телдән исәпләүләрнең аерым алымнары.

Эзлекле тапкырлау һәм бүлү.

816. 1) Тигезлекләрне тикшерергә:

$$75 \times 4 = 70 \times 4 + 5 \times 4 = 280 + 20 = 300$$
$$75 \times 4 = 75 \times 2 \times 2 = 150 \times 2 = 300$$

$65 \times 4 = 65 \times 2 \times 2$	$15 \times 16 = 15 \times 4 \times 4$
$35 \times 8 = 35 \times 2 \times 4$	$45 \times 12 = 45 \times 2 \times 6$
$24 \times 6 = 24 \times 3 \times 2$	$48 \times 15 = 48 \times 5 \times 3$

2) 4, 6, 8, 12, 15, 18, 16 саннары нинди тапкырлашучылардан торалар?

3) Бирелгән санны нинди юл белән 8 гә тапкырлап була? 12 гә? 15 кә? 18 гә?

817. Түбәндәге мисалларда тапкырлауны ике юл белән эшләргә:

$$75 \times 6 = 70 \times 6 + 5 \times 6 = 420 + 30 = 450$$
$$75 \times 6 = 75 \times 2 \times 3 = 150 \times 3 = 450$$

65×4	12×35	125×6	12×12
45×8	27×15	450×6	17×15
54×8	35×16	350×6	18×16
18×6	25×14	154×4	13×18
75×8	25×12	221×4	12×16

818. 1) Тигезлекләрнең дөреслеген тикшерергә:

$$680 : 4 = 600 : 4 + 80 : 4 = 150 + 20 = 170$$
$$680 : 4 = 680 : 2 : 2 = 340 : 2 = 170$$

$300 : 4 = 300 : 2 : 2$	$450 : 6 = 450 : 3 : 2$
$260 : 4 = 260 : 2 : 2$	$1\,000 : 8 = 1\,000 : 2 : 2 : 2$
$315 : 9 = 315 : 3 : 3$	$180 : 12 = 180 : 6 : 2$

2) 4, 9, 6, 8, 12 саннары нинди тапкырлашучылардан торалар?

3) Бирелгән санны нинди юл белән 4 кә бүләргә мөмкин? 8 гә? 16 га? 6 га? 9 га? 12 гә?

819. Түбәндәге мисалларда бүлүне ике юл белән эшләргә:

128 : 4	390 : 6	210 : 14	375 : 15
224 : 8	750 : 6	400 : 16	144 : 12
272 : 8	200 : 8	690 : 15	225 : 15
204 : 6	600 : 4	360 : 24	270 : 18
210 : 6	700 : 4	540 : 36	1 800 : 15

5 кә, 50 гә, 25 кә тапкырлау алымнары.

820. Тигезлекләрнең дөреслеген тикшерергә:

$38 \times 5 = 30 \times 5 + 8 \times 5 = 150 + 40 = 190$
$38 \times 5 = 38 \times 10 : 2 = 380 : 2 = 190$

$67 \times 5 = 67 \times 10 : 2$ $\qquad$ $89 \times 5 = 89 \times 10 : 2$
$56 \times 5 = 56 : 2 \times 10$ $\qquad$ $48 \times 5 = 48 : 2 \times 10$

5 кә тапкырлауны 10 га тапкырлау һәм килеп чыккан тапкырчыгышны 2 гә бүлү белән алмаштырырга мөмкин. Әгәр тапкырланучы 2 гә бүленсә, ул вакытта башта аны 2 гә бүлү һәм килеп чыккан өлешне 10 га тапкырлау уңайрак.

821.

36×5	67×5	64×5	77×5	96×5
52×5	43×5	86×5	65×5	93×5
84×5	39×5	58×5	78×5	76×5

822. Тигезлекләрнең дөреслеген тикшерергә:

$18 \times 50 = 10 \times 50 + 8 \times 50 = 500 + 400 = 900$
$18 \times 50 = 18 \times 100 : 2 = 18 : 2 \times 100 = 900$

$85 \times 50 = 85 \times 100 : 2$ $\qquad$ $63 \times 50 = 63 \times 100 : 2$
$72 \times 50 = 72 : 2 \times 100$ $\qquad$ $48 \times 50 = 48 : 2 \times 100$

50 гә тапкырлауны 100 гә тапкырлау һәм килеп чыккан тапкырчыгышны 2 гә бүлү белән алмаштырырга мөмкин. Әгәр тапкырланучы 2 гә бүленсә, башта аны 2 гә бүлү һәм килеп чыккан өлешне 100 гә тапкырлау уңайрак.

823.

44×50	32×50	27×50	96×50
62×50	56×50	43×50	87×50
48×50	24×50	75×50	58×50
74×50	98×50	83×50	64×50

824. Тигезлекләрнең дөреслеген тикшерергә:

$$24 \times 25 = 20 \times 25 + 4 \times 25 = 500 + 100 = 600$$
$$24 \times 25 = 24 \times 100 : 4 = 24 : 4 \times 100 = 600$$

$38 \times 25 = 38 \times 100 : 4$ $\qquad$ $26 \times 25 = 26 \times 100 : 4$

$32 \times 25 = 32 : 4 \times 100$ $\qquad$ $64 \times 25 = 64 : 4 \times 100$

25 кә тапкырлауны 100 гә тапкырлау һәм килеп чыккан тапкырчыгышны 4 кә бүлү белән алмаштырырга мөмкин. Әгәр тапкырланучы 4 кә бүленсә, башта аны 4 кә бүлү һәм килеп чыккан өлешне 100 гә тапкырлау уңайрак.

825.

125×25	24×25	60×25	23×25
20×25	36×25	84×25	75×25
40×25	48×25	76×25	63×25
80×25	28×25	96×25	39×25

Иң простой вакланмалар.

Вакланмаларның ясалуы һәм аларның рәвешен үзгәртү.

826. Беренче түгәрәк ничә тигез кисәккә бүленгән? икенче түгәрәк? өченче түгәрәк? (46 нчы рәсем.)

Түгәрәкнең яртысын күрсәтергә. Бөтен түгәрәктә ничә ярты бар?



46 нчы рәсем.

Түгәрәкнең чирегең күрсәтергә: ике чиреген; өч чиреген; дүрт чиреген. Бөтен түгәрәктә ничә дүртенче өлеш бар? ярты түгәрәктә?

Бөтен түгәрәктә сигезенче өлешләр ничә? ярты түгәрәктә? чирек түгәрәктә?

827. 12 *см* озынлыкта туры сызык кисемтәсе сызыгыз. Аны ике тигез кисәккә бүлегез һәм икенче өлешләрен күрсәтегез; дүрт тигез кисәккә бүлегез (һәр яртысын урталай бүлеп) һәм кисемтәнең бер чирегең, ике чиреген, өч чиреген, дүрт чиреген күрсәтегез; сигез тигез кисәккә бүлегез (һәр чирекне урталай бүлеп) һәм сигездән бер өлешен, сигездән ике өлешен, сигездән сигез өлешен күрсәтегез.

828. Әгәр алманы ике тигез кисәккә бүлеп, аннан соң килеп чыккан һәр кисәкне яңадан ике тигез кисәккә бүлсәң, аннан соң тагы һәр кисәкне ике тигез кисәккә бүлсәң, килеп чыккан һәр кисәк ничек аталыр?

829. Кәгазь тасманы дүрт кисәккә, ә аннан соң сигез тигез кисәккә бүләргә. Бу бүлүне ничек эшләргә?

830. Бер берәмлектә ничә ярты бар? ничә чирек? ничә сигезенче өлеш?

831. Туры сызык кисемтәсе (47 нче рәсем) дүрт тигез кисәккә бүленгән. Шундый ике кисәк кисемтәнең нинди өлешен тәзи? өч шундый кисәк?



47 нче рәсем.

832. Туры сызык кисемтәсе (48 нче рәсем) сигез тигез кисәккә бүленгән. Шундый биш кисәк барлык кисемтәнең нинди өлешен тәзи? шундый җиде кисәк?



48 нче рәсем.

833. Һәр көн бер үк сандагы битләрне укып барып, укучы китапны 4 көндә укып чыккан. 1 көндә укучы китапның нинди өлешен укыган? 2 көндә? 3 көндә?

834. Самолёт бер үк тизлек белән барып, бер араны 8 сәгатьтә узган. 1 сәгатьтә самолёт барлык араның нинди өлешен очкан? 3 сәгатьтә? 5 сәгатьтә? 7 сәгатьтә?

835. Көн саен бер үк микъдарда тота барып, столовой бәрәңгене 8 көндә тотып бетергән. Бер көндә ул бәрәңгенең нинди өлешен тоткан? 3 көндә? 5 көндә? 7 көндә?

Вакланма шулай язылa: башта вакланмада ничә өлеш бар икәнен күрсәткән санны язалар; аның астына сызык сызалар; сызык астына берәмлекнең ничә тигез кисәккә бүленгәнен күрсәткән санны язалар. Мәсәлән, сигездән өч: $\frac{3}{8}$ рәвешендә язылa.

Сызык өстендә торган сан вакланманың санаучысы дип атала.

Сызык астында торган сан вакланманың ваклаучысы дип атала.

836. Түбәндәге вакланмаларның санаучысын һәм ваклаучысын әйтегез:

$$\frac{3}{4};\ \frac{1}{4};\ \frac{3}{8};\ \frac{7}{8};\ \frac{5}{8};\ \frac{1}{2}.$$

Бу вакланмаларның һәрберсендә санаучы нәрсәне күрсәтә һәм ваклаучы нәрсәне күрсәтә?

837. Вакланмаларны укып чыгарга:

$$\frac{1}{2};\ \frac{1}{4};\ \frac{1}{8};\ \frac{3}{4};\ \frac{5}{8};\ \frac{7}{8};\ \frac{3}{8}.$$

838. Түбәндәге вакланмаларны язарга: икедән бер; өч чирек; сигездән биш; дүрттән бер; сигездән өч; ике чирек; сигездән бер; сигездән җиде.

839. Туры сызык кисемтәсе (49 нчы рәсем) биш тигез кисәккә бүленгән. Биш тигез кисәкнең һәрберсе бөтен кисемтә озынлыгының нинди өлешен тәзи?

49 нчы рәсем.

840. Туры сызык кисемтәсе (50 нче рәсем) ун тигез кисәккә бүленгән. Ун тигез кисәкнең һәрберсе бөтен кисемтә озынлыгының нинди өлешен тәзи?

50 нче рәсем

841. 1) 1 *см* дециметрның нинди өлешен төзи? 2 *см*? 4 *см*? 8 *см*? 6 *см*? 9 *см*?

2) 1 *дм* метрның нинди өлешен төзи? 3 *дм*? 5 *дм*? 9 *дм*?

3) 3 *мм* сантиметрның нинди өлешен төзи? 8 *мм*? 6 *мм*?

842. Туры сызык кисемтәсе сызарга, аны 5 тигез кисәккә бүләргә. Шундый өч кисәкне алырга. Нинди вакланма килеп чыкты? Шундый дүрт кисәк алырга. Нинди вакланма килеп чыкты?

843. Биредә кисемтәнең нинди өлешләре дугалар белән аерып алынган? (51 нче рәсем.)



51 нче рәсем.

844. 1) Вакланмаларны укып чыгарга:

$$\frac{1}{5};\ \frac{1}{10};\ \frac{3}{5};\ \frac{3}{10};\ \frac{4}{5};\ \frac{7}{10};\ \frac{5}{8};\ \frac{3}{4}.$$

Бу вакланмаларның һәрберсенең санаучысы һәм ваклаучысы нәрсәне күрсәтә?

2) Вакланмаларны язарга: биштән ике; уннан җиде; сигездән өч; биштән дүрт; уннан тугыз; биштән бер; уннан өч:

845. Берәмлектә бишенче өлешләр ничә? унынчы өлешләр?

846. Бер туры сызык кисемтәсе өстендә $\frac{3}{5}$ һәм $\frac{7}{10}$ вакланмаларын, ә икенче кисемтә өстендә $\frac{3}{4}$ һәм $\frac{5}{8}$ вакланмаларын күрсәтергә.

847. 1) Бер килограмм печеньене 5 пакетка бүлеп салганнар. Һәр пакетка килограммның нинди өлеше салынган?

2) Икенче бер килограмм печеньене 10 пакетка бүлеп салганнар. Һәр пакетка килограммның нинди өлеше салынган?

848. Метрның чирегендә ничә сантиметр? метрның биштән бер өлешендә? метрның уннан бер өлешендә?

849. Килограммның яртысында ничә грамм? килограммның биштән бер өлешендә? килограммның уннан бер өлешендә?

850. Поезд бер үк тизлек белән барып, 450 *км* ны 10 сәг. тә узган. 4 сәгатьтә ул ничә километр узган? 5 сәгатьтә? 7 сәгатьтә? 9 сәгатьтә?

4 сәгатьтә ул юлның нинди өлешен узган? 5 сәгатьтә? 7 сәгатьтә? 9 сәгатьтә?

851. Яшелчә бакчасының мәйданы 600 *кв. м*. Бакча 5 тигез участокка бүленгән һәм 2 участокка бәрәңге, 2 участокка кәбестә һәм 1 участокка кишер утыртылган. Һәр культура бакчаның нинди өлешен алып тора? Һәр культурага ничә квадрат метр мәйдан бүленеп бирелгән?

852. 52 нче рәсемдә күрсәтелгәнчә, бертигез озынлыкта турыпочмаклы 4 полоска сызыгыз.



52 нче рәсем.

Беренче полоска бер берәмлекне күрсәтә. Икенче полоска ике тигез кисәккә — ике яртыга бүленгән. Өченче полоска дүрт тигез кисәккә — дүрт чиреккә бүленгән. Дүртенче полоска сигез тигез кисәккә — сигез сигездән бер кисәккә бүленгән.

Бу рәсем ярдәмендә түбәндәге сорауларга җавап бирегез:

1) Бәрәмлектә ничә ярты? Яртыда ничә чирек? Бер чиректә сигездән бер өлешләр ничә?

2) Түбәндәге җөмләләрне тутырып әйтегез:

Ике ярты . . . . төзи.
Ике чирек . . . . төзи.
Ике сигездән бер . . . . төзи.
Дүрт сигездән бер . . . . төзи.

853. Бертигез өч кисемтәнең берсе ике тигез кисәккә, икенчесе дүрт тигез кисәккә, өченчесе сигез тигез кисәккә бүленгән (53 нче рәсем). $\frac{1}{2}$; $\frac{2}{4}$; $\frac{4}{8}$ вакланмаларын зурлыклары буенча чагыштырыгыз.



53 нче рәсем.

854. Түбәндәге вакланмалар турында нәрсә әйтергә мөмкин:
$\frac{1}{2}$ һәм $\frac{4}{8}$; $\frac{1}{4}$ һәм $\frac{2}{8}$; $\frac{3}{4}$ һәм $\frac{6}{8}$; $\frac{2}{4}$ һәм $\frac{4}{8}$?

855. Сигезенче өлешләр белән аңлатырга:

$\frac{1}{2}$; $\frac{1}{4}$; $\frac{3}{4}$

856. Төшерелеп калдырылган санаучыларны язарга:

$1=\frac{2}{2}$; $1=\frac{4}{4}$; $1=\frac{8}{8}$; $\frac{1}{2}=\frac{2}{4}$; $\frac{1}{2}=\frac{4}{8}$; $\frac{1}{4}=\frac{2}{8}$;
$\frac{2}{4}=\frac{4}{8}$; $\frac{3}{4}=\frac{6}{8}$; $\frac{2}{4}=\frac{1}{2}$; $\frac{2}{8}=\frac{1}{4}$; $\frac{4}{8}=\frac{2}{4}$;
$\frac{4}{8}=\frac{1}{2}$; $\frac{6}{8}=\frac{3}{4}$.

857. Бертигез озынлыкта турыпочмаклы өч полоска сызыгыз (54 нче рәсем). Икенче полосканы 5 тигез кисәккә, ә өченче полосканы 10 тигез кисәккә бүлегез.

1									
$\frac{1}{5}$		$\frac{1}{5}$		$\frac{1}{5}$		$\frac{1}{5}$		$\frac{1}{5}$	
$\frac{1}{10}$	$\frac{1}{10}$	$\frac{1}{10}$	$\frac{1}{10}$	$\frac{1}{10}$	$\frac{1}{10}$	$\frac{1}{10}$	$\frac{1}{10}$	$\frac{1}{10}$	$\frac{1}{10}$

54 нче рәсем.

Сызымны тикшереп карагыз һәм түбәндәгеләрне ачыкла гыз: берәмлектә ничә бишенче өлеш бар? Берәмлектә ничә унынчы өлеш бар? $\frac{2}{10}$ дә ничә бишенче өлеш бар? $\frac{6}{10}$ да? $\frac{8}{10}$ дә?

858. Төшерелеп калдырылган санаучыларны язарга:

$$1=\frac{\ }{5};\quad 1=\frac{\ }{10};\quad \frac{1}{5}=\frac{\ }{10};\quad \frac{2}{5}=\frac{\ }{10};\quad \frac{3}{5}=\frac{\ }{10};\quad \frac{4}{5}=\frac{\ }{10};$$

$$\frac{2}{10}=\frac{\ }{5};\quad \frac{4}{10}=\frac{\ }{5};\quad \frac{6}{10}=\frac{\ }{5};\quad \frac{8}{10}=\frac{\ }{5}.$$

859. Үзара тигез ике кисемтәнең берсе 5 тигез кисәккә, икенчесе 10 тигез кисәккә бүленгән (55 нче рәсем). Вакланмаларны чагыштырыгыз:

$$\frac{2}{5}\text{ һәм }\frac{4}{10};\quad \frac{4}{5}\text{ һәм }\frac{8}{10};\quad \frac{3}{5}\text{ һәм }\frac{6}{10}.$$



55 нче рәсем.

860. Үзара тигез ике кисемтәнең берсе 2 тигез кисәккә, икенчесе 10 тигез кисәккә бүленгән (56 нчы рәсем). Вакланмаларны чагыштырыгыз:

$$\frac{1}{2}\text{ һәм }\frac{5}{10}.$$



56 нчы рәсем.

861. Метр өстендә $\frac{1}{2}$ *м* ның $\frac{5}{10}$ *м* га тигез икәнен; $\frac{1}{5}$ *м* ның $\frac{2}{10}$ *м* га тигез икәнен күрсәтегез.

862. Түбәндәге вакланмалар арасыннан зурлыклары буенча үзара тигез вакланмаларны сайлап алырга һәм парлап язарга:

$$\frac{1}{5};\ \frac{1}{2};\ \frac{3}{5};\ \frac{3}{4};\ \frac{4}{8};\ \frac{6}{10};\ \frac{1}{4};\ \frac{2}{10};\ \frac{6}{8};\ \frac{2}{8}.$$

Мәсәлән: $\frac{1}{5}=\frac{2}{10}$.

863. 1) $\frac{1}{4}$, $\frac{1}{10}$, $\frac{1}{2}$, $\frac{1}{8}$, $\frac{1}{5}$ вакланмаларын иң кечкенәсеннән башлап иң зурысына кадәр тәртип белән урнаштырырга.

2) $\frac{3}{4}$, $\frac{3}{8}$, $\frac{3}{10}$, $\frac{3}{5}$ вакланмаларын иң зурысыннан башлап иң кечкенәсенә кадәр тәртип белән урнаштырырга.

3) $\frac{3}{10}$, $\frac{5}{10}$, $\frac{2}{10}$, $\frac{9}{10}$, $\frac{7}{10}$ вакланмаларын иң кечкенәсеннән башлап иң зурысына кадәр тәртип белән урнаштырырга.

864. Һәрбер фигураның нинди өлеше штрихланган? (57 нче рәсем.)



57 нче рәсем.

Вакланмаларны кушу һәм алу.

865. Лото ясау өчен, балалар зур карточкаларга картонның $\frac{5}{8}$ табагын, кечкенә карточкаларга $\frac{1}{8}$ табагын кисеп алдылар. Зур һәм кечкенә карточкалар өчен бергә табакның нинди өлеше кисеп алынган? Сызым ясарга.

866. Мәктәп участогының $\frac{2}{5}$ сен яшелчә бакчасы һәм $\frac{2}{5}$ сен җимеш бакчасы алып тора. Бакчалар икесе бергә участокның нинди өлешен алып торалар?

867. Җил двигателе моделе өчен ике кучәр ясарга дип 1 *м* озынлыгындагы рейкадан башта $\frac{7}{10}$ *м*, соңыннан тагы $\frac{1}{10}$ *м* кисеп алдылар. Ике кучәр ясау өчен метрның нинди өлешен кисеп алганнар?

868. $\frac{1}{2}$ *м* + $\frac{1}{2}$ *м* $\frac{1}{5}$ *км* + $\frac{1}{5}$ *км* $\frac{2}{5}+\frac{3}{5}$ $\frac{3}{8}+\frac{1}{8}$

$\frac{1}{4}$ *кг* + $\frac{1}{4}$ *кг* $\frac{1}{10}$ *т* + $\frac{1}{10}$ *т* $\frac{7}{8}+\frac{1}{8}$ $\frac{3}{10}+\frac{3}{10}$

$\frac{1}{8}$ *л* + $\frac{1}{8}$ *л* $\frac{3}{4}$ *ц* + $\frac{1}{4}$ *ц* $\frac{9}{10}+\frac{1}{10}$ $\frac{5}{8}+\frac{2}{8}$

869. $\frac{7}{10}+\frac{3}{10}$ $\frac{1}{4}+\frac{3}{4}$ $\frac{3}{5}+\frac{2}{5}$ $\frac{1}{2}+\frac{1}{2}$

$\frac{7}{10}+\frac{1}{10}$ $\frac{1}{8}+\frac{5}{8}$ $\frac{2}{5}+\frac{2}{5}$ $\frac{1}{8}+\frac{7}{8}$

$\frac{3}{8}+\frac{5}{8}$ $\frac{5}{10}+\frac{5}{10}$ $\frac{1}{8}+\frac{3}{8}$ $\frac{1}{10}+\frac{7}{10}$

870. Бакчада җимеш агачлары $\frac{5}{8}$ *га*, җиләк куаклары $\frac{1}{8}$ *га* мәйданны алып торалар. Агачлар һәм куаклар икесе бергә гектарның нинди өлешен алып торалар? Сызымын ясарга.

871. Сарай күләменең $\frac{7}{10}$ се болын печәне белән, ә $\frac{2}{10}$ се клевер печәне белән тутырылган. Болын һәм клевер печәне бергә сарайның нинди өлешен алып торалар?

---

872. $\frac{7}{8}$ *га* зурлыктагы яшелчә бакчасында $\frac{5}{8}$ *га* мәйданга бәрәңге, калган мәйданга яшелчәләр утыртылган. Яшелчәләр нинди мәйданны алып торалар?

873. 1 *л* су 1 *кг* килә, ә 1 *л* бензин $\frac{7}{10}$ *кг*. Бер литр су бер литр бензиннан күпмегә авыррак?

874. Беренче көнне барлык басуның $\frac{3}{8}$ өлешен, икенче көнне $\frac{1}{8}$ гә кимрәк, ә өченче көнне калган өлешен сөрделәр. Өченче көнне басуның нинди өлешен сөргәннәр?

875. $1\ м - \frac{1}{2}\ м$. $\quad \frac{3}{4}\ км - \frac{1}{4}\ км \quad \frac{4}{5} - \frac{2}{5} \quad \frac{9}{10} - \frac{1}{10} + \frac{2}{10}$

$1\ л - \frac{1}{4}\ л \quad \frac{4}{5}\ ц - \frac{1}{5}\ ц \quad \frac{3}{8} - \frac{1}{8} \quad \frac{5}{8} - \frac{3}{8} + \frac{5}{8}$

$1\ кг - \frac{1}{8}\ кг \quad \frac{7}{8}\ га - \frac{3}{8}\ га \quad \frac{7}{10} - \frac{3}{10} \quad \frac{4}{5} - \frac{3}{5} + \frac{2}{5}$

876. $1\ т - \frac{1}{10}\ т \quad \frac{3}{4}$ сәг. $- \frac{1}{4}$ сәг.

$1\ км - \frac{1}{5}\ км \quad \frac{9}{10}$ секунд $- \frac{7}{10}$ секунд

$\frac{7}{8} - \frac{5}{8} + \frac{6}{8} \quad \frac{1}{5} + \frac{3}{5} - \frac{2}{5}$

$\frac{7}{10} - \frac{3}{10} + \frac{1}{10} \quad \frac{3}{4} + \frac{1}{4} - \frac{1}{4}$

877. Семьяда бер көндә $\frac{7}{10}$ *кг* шикәр тотканнар. Иртә белән $\frac{3}{10}$ *кг*, көндез $\frac{1}{10}$ *кг* кимрәк тотканнар. Кичен күпме шикәр тотканнар?

878. $\frac{1}{2}+\frac{1}{4}$ $\quad$ $\frac{1}{8}+\frac{3}{4}$

$\frac{1}{4}+\frac{1}{8}$ $\quad$ $\frac{1}{5}+\frac{3}{10}$

$\frac{1}{10}+\frac{1}{5}$ $\quad$ $\frac{1}{2}+\frac{3}{8}$

$\frac{1}{2}+\frac{1}{8}$ $\quad$ $\frac{1}{4}+\frac{5}{8}$



58 нче рәсем.

Чишелеш (58 нче рәсем). $\frac{1}{2}+\frac{1}{4}=\frac{2}{4}+\frac{1}{4}=\frac{3}{4}$

879. Укучы $\frac{1}{2}$ сәг. язу белән һәм $\frac{1}{4}$ сәг. уку белән шөгыльләнде. Укучы уку һәм язу белән барысы күпме вакыт шөгыльләнде?

880. Мәктәп участогының мәйданы 1 *га*. Яшелчә бакчасы $\frac{3}{8}$ *га* ны, җимеш бакчасы $\frac{1}{4}$ *га* ны алып тора, ә калган мәйданда каралтылар һәм мәйданчыклар. Каралтылар һәм мәйданчыклар күпме җирне алып торалар?

881. Үзегезнең мәктәп участогы турында узган мәсьәләгә охшатып мәсьәлә төзергә.

882. $\frac{1}{2}$ сәг. — $\frac{1}{4}$ сәг. $\quad$ $\frac{1}{5}$ *м* — $\frac{1}{10}$ *м* $\quad$ $\frac{4}{5}-\frac{7}{10}$ $\quad$ $1-\frac{3}{8}$

$\frac{1}{4}$ *кг* — $\frac{1}{8}$ *кг* $\quad$ $\frac{4}{5}$ *км* — $\frac{1}{10}$ *км* $\quad$ $\frac{3}{5}-\frac{3}{10}$ $\quad$ $1-\frac{1}{4}$

883. $\frac{1}{2}+\frac{1}{4}-\frac{3}{8}$ $\quad$ $1-\frac{7}{8}+\frac{1}{4}$ $\quad$ $\frac{3}{10}+\frac{1}{5}-\frac{1}{10}$

$\frac{1}{8}+\frac{3}{4}-\frac{1}{2}$ $\quad$ $1-\frac{3}{4}+\frac{1}{8}$ $\quad$ $\frac{2}{5}+\frac{1}{10}-\frac{3}{10}$

$\frac{7}{8}+\frac{1}{8}-\frac{3}{4}$ $\quad$ $1-\frac{3}{8}+\frac{1}{4}$ $\quad$ $\frac{7}{10}+\frac{1}{5}-\frac{2}{5}$

884. Флюгер ясау өчен балалар тимер чыбыкның $\frac{1}{5}$ өлешен, аннан соң $\frac{3}{10}$ өлешен кисеп алганнар. Чыбыкның нинди өлеше калган?

885. Җир казучы машина канауны өч көндә казыды: беренче көнне барлык канауның $\frac{1}{4}$ ен, икенче көнне $\frac{1}{2}$ ен. Машина өченче көнне канауның нинди өлешен казыган?

886. Трактор бригадасы беренче көнне барлык басуның $\frac{1}{4}$ ен, икенче көнне $\frac{1}{8}$ гә артыграк сөрде. Ике көн эчендә басуның нинди өлеше сөрелгән?

887. Комбайн белән беренче көнне басуның $\frac{1}{5}$ өлешен, икенче көнне, беренче көндәгегә караганда, $\frac{1}{10}$ өлешкә артыграк урып җыйдылар. Беренче ике көн эшләгәннән соң басуның нинди өлешен урып җыясы калган?

888. 1) Ике вакланманың суммасы 1 гә тигез; аларның берсе $\frac{3}{10}$. Икенче вакланма күпмегә тигез?

2) Ике санның суммасы $\frac{5}{8}$, бер кушылучы $\frac{1}{4}$ гә тигез. Икенче кушылучыны табарга.

3) Кимүче $\frac{9}{10}$, киметүче $\frac{3}{5}$. Аерманы табарга.

4) Кимүче $\frac{7}{8}$, аерма $\frac{3}{4}$. Киметүчене табарга.

5) Киметүче $\frac{2}{5}$, аерма $\frac{6}{10}$. Кимүче күпмегә тигез?

889. Түбәндәгечә чишелә торган мәсьәлә уйлап табарга:

$$1)\ \frac{3}{8}\text{ л} + \frac{1}{4}\text{ л} = \frac{5}{8}\text{ л}$$

$$2)\ \frac{3}{8}\text{ л} + \frac{5}{8}\text{ л} = \frac{8}{8}\text{ л} = 1\text{ л}$$

Җавап. Ике бутылкада 1 л көнбагыш мае бар.

Санның бер яки берничә өлешен табуга мәсьәләләр.

890. Өстәлгә 16 кубик куярга һәм бу кубикларның $\frac{1}{4}$ ен алырга. Бу кубикларның $\frac{1}{4}$ ен ничек табарга?

891. 1) 12 шакмак озынлыгындагы полоска (59 нчы рәсем) 4 тигез өлешкә бүленгән һәм аның $\frac{1}{4}$ өлеше штрихланган. Ничә шакмак штрихланган?



59 нчы рәсем.

2) 16 шакмак озынлыгында полоска сызарга; аның $\frac{1}{4}$ өлешен кызыл төскә, аннан соңгы $\frac{1}{4}$ ен зәңгәр төскә һәм тагы $\frac{1}{4}$ өлешен сары төскә буярга. Полосканың нинди өлеше буялган? Ничә шакмак буялган?

892. 1) Тартмага 20 кубик салырга һәм бу кубикларның $\frac{2}{5}$ сен алырга. Кубикларның $\frac{2}{5}$ сен ничек табарга? 20 кубикның $\frac{2}{5}$ се ничә кубикны төзи?

2) 12 *см* озынлыгында туры сызык кисемтәсе сызарга. Башта кисемтәнең $\frac{1}{4}$ ен, ә аннан соң $\frac{3}{4}$ ен табарга.

893. 24 *см* озынлыгында кәгазь полоска хәзерләргә. Бу полоскадан аның $\frac{5}{8}$ енә тигез булган өлешен кисеп алырга.

894. 60 нчы рәсемдә һәр дуга белән кисемтәнең нинди өлеше тамгаланган?

60 нчы рәсем.

895. $\frac{1}{4}$ *м* да ничә сантиметр? $\frac{1}{5}$ *м* да? $\frac{1}{10}$ *м* да? $\frac{3}{4}$ *м* да? $\frac{2}{5}$ *м* да? $\frac{7}{10}$ *м* да? Моны метр өстендә күрсәтергә.

896. Һәрберсе 40 *см* озынлыгындагы өч кәгазь полоска хәзерләргә. Беренче полоскада озынлыгының $\frac{3}{4}$ ен, икенчесендә $\frac{5}{8}$ ен, өченчесендә $\frac{9}{10}$ ын тамгаларга.

897. Китапта 128 бит. Беренче көнне укучы китапның $\frac{1}{2}$ ен укыган. Беренче көнне укучы ничә бит укыган?

898. Тартмада 200 каләм бар иде. Бер ай эчендә каләмнәрнең $\frac{3}{5}$ е укучыларга бирелгән. Бер айда ничә каләм бирелгән?

899. 1) $\frac{1}{2}$ *кг* да ничә грамм? $\frac{1}{4}$ *кг* да? $\frac{2}{5}$ *кг* да? $\frac{3}{4}$ *кг* да? $\frac{1}{10}$ *кг* да? $\frac{3}{10}$ *кг* да?

2) $\frac{1}{2}$ *т* да ничә килограмм? $\frac{1}{5}$ *т* да? $\frac{3}{4}$ *т* да? $\frac{3}{5}$ *т* да? $\frac{1}{10}$ *т* да? $\frac{7}{10}$ *т* да?

3) $\frac{1}{2}$ *км* да ничә метр? $\frac{1}{4}$ *км* да? $\frac{1}{8}$ *км* да? $\frac{5}{8}$ *км* да? $\frac{3}{5}$ *км* да?

900. Басуның буе 600 *м*, ә иңе буеның $\frac{3}{5}$ е кадәр. Басуның мәйданын исәпләргә.

901. Бинаның буе 32 *м*, иңе буеның $\frac{1}{2}$ е кадәр, ә биеклеге буеның $\frac{1}{8}$ ен тәзи. Бу бинаның күләме күпмегә тигез?

902. Пионерлар лагеренда балалар бер көндә 2 *кг* 620 *г* ромашка җыйдылар. Киптергәндә авырлыгының $\frac{4}{5}$ е югалса, бу ромашкадан күпме кипкән ромашка чыгар?

903. Мәктәп укучыларга аена 370 дәфтәр бирде: дәфтәрләрнең $\frac{3}{10}$ е бер юллы, $\frac{3}{5}$ е шакмаклы, ә калганнары ике юллы дәфтәрләр. Ничә ике юллы дәфтәр бирелгән?

904. 1) $\frac{1}{2}$ *т* да ничә центнер? $\frac{1}{5}$ *т* да? $\frac{3}{5}$ *т* да? $\frac{4}{5}$ *т* да?

2) $\frac{1}{2}$ сумда ничә тиен? $\frac{1}{4}$ сумда? $\frac{1}{5}$ сумда? $\frac{3}{4}$ сумда? $\frac{2}{5}$ сумда? $\frac{7}{10}$ сумда?

905. Заводта 3 600 эшче бар. Барлык эшчеләрнең $\frac{3}{5}$ е ирләр, ә калганы хатын-кызлар. Заводта ничә хатын-кыз булган?

906. Ике поезд аралары 1 840 *км* булган ике шәһәрдән бер-беренә каршы чыктылар. Беренче поезд барлык араның $\frac{5}{8}$ ен, икенче поезд $\frac{3}{10}$ ен узды. Поездлар бер-береннән нинди ераклыкта булып калганнар?

907. Колхоз бакчасында 1 120 төп агач бар; бу агачларның $\frac{3}{8}$ е алмагачлар, $\frac{2}{5}$ се груша, калганнары чия агачлары. Бакчада ничә төп чия агачы булган?

908. Чәчүлек, урман һәм болын 1 520 *га* мәйданны алып торалар. Алардан чәчүлек җир барлык мәйданның $\frac{3}{5}$ ен, болын $\frac{3}{10}$ ен алып тора, ә калган мәйдан — урман. Урман нинди мәйданны алып тора? (61 нче рәсем.)

61 нче рәсем.

909. 45 150 350 санының $\frac{4}{5}$ ен, 38 *га* 8 200 *кв. м* ның $\frac{3}{4}$ ен табарга.

910. (Телдән.) 1) Укучылар урманнан утырту өчен юкә һәм каен агачлары китерделәр. Юкә агачлары 40 төп, ә каен агачлары юкә агачлары санының $\frac{5}{8}$ е кадәр булган. Укучылар ничә төп каен китергәннәр?

2) Икенче тапкыр укучылар урманнан каен, юкә һәм тополь агачлары китерделәр. Тополь 60 төп, юкә тополь санының $\frac{3}{5}$ е кадәр, ә каен юкә санының $\frac{3}{4}$ е кадәр булган. Балалар ничә төп юкә һәм ничә төп каен китергәннәр?

911. Бакчада 1440 төп фрукт агачлары булган. Алмагачлар барлык агачларның $\frac{1}{2}$ ен, груша агачлары алмагачлар санының $\frac{3}{5}$ ен тәзиләр, калганнары слива агачлары. Бакчада ничә төп слива агачы булган?

912. Турыпочмаклы участокның буе 175 *м*, иңе буеннан 35 *м* га кимрәк. Бу участокның $\frac{3}{4}$ енә бәрәңге, $\frac{1}{5}$ енә кәбестә утыртылган. Калган мәйданны чөгендер алып тора. Чөгендер нинди мәйданны алып тора?

913. Магазинда төрле сорттан 640 *кг* ярма булган: барлык ярманың $\frac{3}{5}$ е дөге, $\frac{1}{8}$ е тары, ә калганы карабодай ярмасы. Магазинда ничә килограмм карабодай ярмасы булган? Мәсьәлә чишелешенең дөреслеген тикшерергә.

914. 1) 3080 һәм 406 саннары тапкырчыгышының $\frac{3}{4}$ ен табарга.

2) 26 *кг* 86 *г* һәм 40 *кг* 98 *г* саннары суммасының $\frac{5}{8}$ ен табарга.

915. 1) 10 *см* озынлыктагы полосканың (62 нче рәсем) $\frac{3}{5}$ ен сары төскә, ә калганның яртысын кызыл төскә буягыз. Нинди озынлыктагы полосканы кызыл төскә буярга кирәк?



62 нче рәсем.

2) Укучының 2 сум 40 тиен акчасы бар иде. Бу акчаның $\frac{1}{4}$ ен ул язу әйберләре алырга, ә калдыкның $\frac{1}{2}$ ен кайнар аш өчен түләгән. Кайнар аш күпме торган?

(3) Бер кешенең 1 200 сум акчасы булган. Бу акчаның $\frac{1}{4}$ ен ул патефон, ә калдыкның $\frac{1}{5}$ ен пластинкалар сатып алуга тоткан. Пластинкалар күпме тора?

916. Базада 24 *т* 800 *кг* яшелчә булган. Беренче көнне бу яшелчәнең $\frac{3}{10}$ е, икенче көнне калдыкның $\frac{4}{5}$ е магазиннарга җибәрелгән. Беренче көнне магазиннарга күпме яшелчә җибәрелгән? икенче көнне?

917. Колхозда 1 248 *га* сөрелә торган җир бар. Бу мәйданның $\frac{3}{8}$ енә колхоз арыш, калдыкның $\frac{1}{4}$ енә солы, ә калган җиргә бодай чәчкән. Бодай ничә гектарга чәчелгән?

918. Яшь туристлар 1 880 *км* юл үткәннәр. Бу юлның $\frac{5}{8}$ ен алар пароходта, калдыкның $\frac{3}{5}$ ен поездда, калган юлны җәяү узганнар. Туристлар җәяүләп ничә километр юл узганнар?

919. 1) $\frac{1}{2}$ *а* да ничә квадрат метр? $\frac{1}{4}$ *а* да? $\frac{1}{5}$ *а* да? $\frac{3}{4}$ *а* да? $\frac{2}{5}$ *а* да? $\frac{7}{10}$ *а* да?

2) $\frac{1}{2}$ *га* да ничә квадрат метр? $\frac{1}{4}$ *га* да? $\frac{4}{5}$ *га* да? $\frac{1}{10}$ *га* да? $\frac{3}{8}$ *га* да?

3) $\frac{1}{2}$ *куб м* да ничә куб дециметр? $\frac{1}{4}$ *куб м* да? $\frac{1}{5}$ *куб м* да? $\frac{1}{10}$ *куб м* да?

4) $\frac{1}{2}$ *куб дм* да ничә куб сантиметр? $\frac{1}{4}$ *куб дм* да? $\frac{1}{8}$ *куб дм* да? $\frac{3}{5}$ *куб дм* да?

920. 1 050 100 һәм 950 125 саннары аермасының $\frac{3}{5}$ ен табарга.

921. Магазин 2980 сумга 640 *кг* ике сорт алма сатты. Алманың $\frac{5}{8}$ ен ул килограммын 5 сум 50 шәр тиеннән сатты. Магазин калган алманы нинди бәядән саткан?

922. Бер колхозда өч атна эчендә 180 йортны радиолаштырдылар. Беренче атнада барлык йортларның $\frac{1}{5}$ е, икенче атнада $\frac{3}{10}$ е радиолаштырылган. Өченче атнада ничә йорт радиолаштырылган?

923. Колхозда өч атнада 240 йортны электрлаштырдылар: беренче атнада барлык йортларның $\frac{2}{5}$ сен, икенче атнада беренче атнада электрлаштырылган йортларның $\frac{1}{\text{[illegible]}}$ е кадәр йортны электрлаштырганнар. Өченче атнада ничә йортка электр кертелгән?

924. Ике шәһәрдән бер үк вакытта бер-беренә каршы ике поезд чыккан. Бер поезд сәгатькә 50 *км* тизлек белән барган; икенче поездның тизлеге беренче поезд тизлегенең $\frac{9}{10}$ ы кадәр. Поездлар чыгудан 12 сәгать узгач очрашканнар. Ике шәһәр арасын табарга. Чишелешне санлы формула белән язарга.

925. Нинди дә булса санның берничә өлешен табу соралган мәсьәлә төзегез.

926. Түбәндәгечә чишелә торган мәсьәлә төзергә:

$$80 \text{ кг} : 4 = 20 \text{ кг}$$
$$20 \text{ кг} \times 3 = 60 \text{ кг}$$

Җавап. Икенче капчыкта 60 *кг* он булган.

927. Кайсы зуррак һәм күпмегә: 2 820 360 санының $\frac{3}{4}$ еме яки 6 416 024 санының $\frac{5}{8}$ еме?

Кабатлау бүлеге.

Телдән һәм язма нумерация.

928. 1) 10 берәмлекне, 10 дистәне, 10 йөзне бер сүз белән ничек әйтергә?

2) Йөз миллиардларга кадәр разряд берәмлекләрен әйтеп чыгарга.

3) Беренче классның, икенче классның, өченче классның, дүртенче классның разряд берәмлекләрен әйтергә.

4) Өченче классның 50 берәмлегеннән торган санны, икенче классның 340 берәмлегеннән торган санны, дүртенче классның 8 берәмлегеннән торган санны, беренче классның 508 берәмлегеннән торган санны әйтергә.

5) Саннарны тамгалау өчен ничә цифра бар? Төрле өч цифра белән төрле алты сан язарга.

6) Меңнәрнең берәмлекләре уң кулдан ничәнче урында тора? миллионнарның берәмлекләре? миллиардларның берәмлекләре? меңнәрнең дистәләре? миллионнарның дистәләре? миллиардларның дистәләре? меңнәрнең йөзләре? миллионнарның йөзләре? миллиардларның йөзләре?

929. 1) Түбәндәге саннарны укып чыгарга һәм аларда нинди классларның нинди разряд берәмлекләре бар икәнен әйтергә: 8 756; 76 005; 420 108; 35 080 059; 308 760 652; 1 389 726 198.

2) Түбәндәге саннарны укып чыгарга һәм аларда нинди классларның нинди разряд берәмлекләре юк икәнен әйтергә: 4 000 125; 20 014 008; 109 060 906; 28 000 354 008; 10 000 554 000; 200 080 050.

3) Миллионда ничә мең? Миллиардта ничә миллион?

930. Түбәндәге саннарның һәрберсендә барысы ничә дистә бар: 42 720; 350 000; 250 785; 7 008 000; 50 370 208; 785 000; 3 754 075; 3 007 537; 24 030 008; 100 000 000?

Бу саннарның һәрберсендә барысы ничә йөз?

931. Түбәндәге саннарның һәрберсендә барысы ничә дистә мең: 6 230 000; 21 400 000; 30 527 032; 120 428 000; 800 000 000?

932. Бер мең өч йөз илле дистәдән торган санны язарга; сиксән ике дистә меңнән торган санны; бер мең илле өч йөздән торган санны; җиде йөз илле җиде йөз меңнән торган санны.

933. Укып чыгарга һәм счётта салырга: 7 825; 62 000; 37 500; 17 030; 40 020; 720 350; 500 025; 45 сум 30 тиен; 20 сум 17 тиен; 60 сум 7 тиен; 204 сум 2 тиен; 360 сум 75 тиен; 2 008 сум 70 тиен; 36 075 сум 9 тиен.

Телдән исәпләү өчен мисаллар.

934. Түгәрәкләү алымын файдаланып исәпләргә:

1) $399+264$ $\quad 199+426$ $\quad 546+298$ $\quad 48+39$
$698+185$ $\quad 735+198$ $\quad 297+82$ $\quad 62+29$

2) $101-75$ $\quad 803-78$ $\quad 165-98$ $\quad 580-198$
$502-64$ $\quad 604-35$ $\quad 465-97$ $\quad 762-299$

935. Иң җайлы юл белән исәпләргә:

1) $42+29+58$ $\quad 49+26+51$ $\quad 37+32+13+28$
$26+18+24$ $\quad 36+68+64$ $\quad 68+14+32+86$
$17+83+26$ $\quad 88+12+44$ $\quad 11+42+89+58$

2) $15\times9\times6$ $\quad 2\times17\times25$ $\quad 6\times12\times2\times5$
$50\times7\times2$ $\quad 8\times2\times25$ $\quad 2\times18\times5\times3$
$15\times7\times4$ $\quad 4\times13\times25$ $\quad 2\times17\times4\times5$

936. Эзлекле тапкырлау һәм бүлү алымын файдаланып исәпләргә:

1) 25×16 $\quad 15\times16$ $\quad 62\times15$ $\quad 15\times36$ $\quad 25\times40$
55×14 $\quad 75\times12$ $\quad 48\times15$ $\quad 25\times36$ $\quad 25\times64$
45×12 $\quad 35\times16$ $\quad 35\times24$ $\quad 18\times15$ $\quad 25\times80$

2) $270:6$ $\quad 350:14$ $\quad 400:16$ $\quad 690:15$ $\quad 1\,000:20$
$315:9$ $\quad 270:18$ $\quad 240:16$ $\quad 315:15$ $\quad 1\,000:25$
$288:8$ $\quad 360:24$ $\quad 210:15$ $\quad 540:36$ $\quad 1\,000:50$

937. 1) 54×10 $\quad 378\times10$ $\quad 15\times100$ $\quad 408\times1\,000$
68×10 $\quad 264\times10$ $\quad 36\times100$ $\quad 350\times1\,000$
90×10 $\quad 111\times10$ $\quad 64\times100$ $\quad 100\times1\,000$

2) 38×5 $\quad 32\times50$ $\quad 27\times50$ $\quad 12\times25$ $\quad 76\times25$
72×5 $\quad 54\times50$ $\quad 43\times50$ $\quad 84\times25$ $\quad 68\times25$
49×5 $\quad 62\times50$ $\quad 57\times50$ $\quad 40\times25$ $\quad 56\times25$

938. 1)

$260 : 10$	$1\,700 : 100$	$520 : 5$	$160 : 5$
$390 : 10$	$3\,600 : 100$	$460 : 5$	$230 : 5$
$2\,820 : 10$	$5\,000 : 100$	$670 : 5$	$300 : 5$

2)

$630 : 7$	$520 : 4$	$729 : 3$	$560 : 80$	$360 : 18$
$810 : 9$	$850 : 5$	$486 : 6$	$720 : 60$	$460 : 23$
$540 : 6$	$910 : 7$	$819 : 9$	$850 : 50$	$960 : 48$

939. x **ны табарга:**

1)

$85 + x = 200$	$x + 70 = 150$	$x - 70 = 90$
$60 + x = 190$	$x + 90 = 240$	$x - 30 = 86$
$25 + x = 400$	$x + 60 = 320$	$x - 90 = 75$

2)

$120 - x = 60$	$1\,000 - x = 120$	$x - 260 = 520$
$460 - x = 80$	$1\,000 - x = 640$	$x - 370 = 620$

3)

$x \times 12 = 144$	$30 \times x = 900$	$x : 13 = 12$
$x \times 15 = 180$	$40 \times x = 800$	$x : 18 = 20$

4)

$196 : x = 14$	$169 : x = 13$	$x \times 16 = 256$
$225 : x = 15$	$121 : x = 11$	$x : 16 = 16$

Язып исәпләү өчен мисаллар.

940.
$645 \times 144 + 880 \times 125 - 7\,120$
$512 \times 625 - 250 \times 128 + 8\,002$
$95\,056 : 457 + 326\,886 : 543$
$88\,271 : 103 - 228\,480 : 640$

941.

$902 : 3$	$7\,485 : 9$	$9\,614 : 16$	$5\,706 : 15$
$803 : 4$	$4\,208 : 7$	$5\,425 : 27$	$8\,325 : 26$

942.
$(1\,000\,000 - 999\,584) \times (27\,000 : 36)$
$(1\,000\,024 - 327\,256) : 96 \times 125$
$(1\,098\,900 - 592\,407) : (168\,831 : 507)$
$194\,400 : 288 \times (327\,524 - 326\,788)$

943.
$1\,000 - 31\,518 : 153 + 571\,154 : 809$
$6\,005 + 168\,140 : 28 - 844\,008 : 264$
$(143\,620 : 172 + 247\,445 : 409) : 720$
$(600\,357 : 683 - 300\,202 : 523) \times 204$

944.
$(101 \times 101 - 652\,864 : 808) : 303 \times 205$
$25\,000 : (428\,442 : 707 - 255\,000 : 625 + 302)$
$345\,465 : 853 + 2\,000\,070 : 639 - 150\,000 : 625$
$205 \times (1\,000\,000 : 3\,125 \times 609 : 480) : 2\,030$

945. $(64\,000 : 128 - 3\,280 : 164 \times 15) \times 700 - 192\,000 : 800$
$10\,908 - 174\,528 : 16 + 3\,852\,600 : 300 - 12\,842$
$(48 \times 125 + 36 \times 175) : 50 \times 400 - 12\,060$
$(162\,000 - 216 \times 750) \times 816 - 4 + 1\,000$

946 $(31\,460 + 1\,040 : 150 - 2\,400 : 120) \times 20 : 125 + 100$
$(78\,213 - 75\,209) \times 207 - (315\,123 - 314\,716) \times 308$
$71\,370 - 234 \times 234 + 695 \times 50 - 280\,084 : 28$
$2\,786 - 970\,710 : 1\,235 + 408 \times 2\,700$

947. 1) $32\,408 + x = 70\,000$ $\qquad x - 9\,482 = 72\,400$
$42\,680 - x = 29\,490$ $\qquad x + 4\,806 = 17\,006$

2) $x \times 420 = 2\,553\,600$ $\qquad 541\,350 : x = 450$
$x : 360 = 145\,000$ $\qquad 2\,300 \times x = 92\,000$

948. 1) 13 789, 4 906, 90 768 саннарының суммасын табарга һәм килеп чыккан нәтиҗәнең дөреслеген тикшерергә.

2) Ике санның суммасы 60 100. Аларның берсе 9 532. Икенче санны табарга.

3) Өч кушылучының суммасы 17 086. Әгәр беренче һәм икенче кушылучыларны кушсаң, 9 838 чыга; әгәр беренче һәм өченче кушылучыларны кушсаң, 12 340 чыга. Һәр кушылучыны табарга.

949. 1) 50 102 һәм 9 165 саннарының аермасын табарга. Килеп чыккан нәтиҗәнең дөреслеген ике юл белән тикшерергә.

2) Кимүче 100 100. Аерма 39 204. Киметүчене табарга.

3) Киметүче 3 704. Аерма 6 306. Кимүчене табарга.

4) 82 308 һәм 16 976 саннарының суммасын аларның аермасы кадәр арттырырга; аермасы кадәр киметергә.

950. 1) 720 һәм 308 саннарының тапкырчыгышын табарга. Табылган нәтиҗәнең дөреслеген ике юл белән тикшерергә.

2) Ике санның тапкырчыгышы 18 600. Тапкырлашучыларның берсе 120. Икенче тапкырлашучыны табарга.

3) 80 һәм 75 саннары суммасының аларның аермасына тапкырчыгышын табарга.

951. 1) 750 125 не 250 гә бүлүдән чыккан өлешне һәм калдыкны табарга. Килеп чыккан нәтиҗәнең дөреслеген тикшерергә.

2) 41 607 саны 69 дан ничә тапкыр зуррак?

3) Бүленүче 1 456, өлеш 7. Бүлүчене табарга.

4) Бүлүче 308, өлеш 406. Бүленүчене табарга.

5) Бүлүче 504, өлеш 7 һәм калдык 103. Бүленүчене табарга.

6) Бүлүче 500, өлеш 20 һәм калдык 200. Бүленүчене табарга.

952. 1) 12 036 санының $\frac{1}{4}$ ен, 1 005 санының $\frac{4}{5}$ ен табарга.

2) 1 250 саны бирелгән. Әлек бу санның $\frac{2}{5}$ сен, аннан соң калдыкның $\frac{3}{10}$ ен табу сорала.

953. Гамәлләрне эшләргә һәм дөреслеген счётта тикшерергә.

1) 18 сум 50 тиен + 20 сум 84 тиен
26 сум 75 тиен + 39 сум 25 тиен
38 сум + 45 сум 99 тиен
124 сум 35 тиен + 85 сум 65 тиен
300 сум 70 тиен + 56 сум 80 тиен
408 сум 45 тиен + 879 сум

2) 725 сум — 568 сум
860 сум — 382 сум
600 сум — 276 сум
16 сум 86 тиен — 12 сум 35 тиен
75 сум 62 тиен — 40 сум 28 тиен
62 сум 15 тиен — 16 сум 67 тиен

954. 86 *м* 75 *см* + 28 *м* 25 *см*
14 *м* 8 *см* + 56 *м* 9 *см*
16 *ц* 57 *кг* + 36 *ц* 58 *кг*
45 *км* 472 *м* + 36 *км* 865 *м*
90 *км* 76 *м* + 32 *км* 89 *м*
72 *т* 493 *кг* + 84 *т* 758 *кг*

955. 24 *м* 25 *см* — 16 *м* 75 *см*
35 *ц* 60 *кг* — 28 *ц* 80 *кг*
84 *ц* 6 *кг* — 29 *ц* 8 *кг*
5 *км* 246 *м* — 2 *км* 456 *м*
9 *т* 30 *кг* — 5 *т* 72 *кг*
8 *кг* 75 *г* — 3 *кг* 90 *г*

956.

8 сум 76 тиен × 38
7 сум 5 тиен × 19
5 *дм* 3 *см* × 89
18 *см* 7 *мм* × 68
5 *кг* 800 *г* × 700
3 *кг* 608 *г* × 56
7 *т* 38 *кг* × 95
7 *ц* 9 *кг* × 46
5 *ц* 64 *кг* × 80

957. 1) 94 *м* 8 *см* : 42
8 *м* 76 *см* : 12
9 *ц* : 15
4 *дм* : 8
5 *т* 576 *кг* : 68
4 *км* 662 *м* : 74

2) 18 *т* : 4 *т* 500 *кг*
30 *км* : 3 *км* 750 *м*
59 *кг* 827 *г* : 2 *кг* 63 *г*
246 *м* 60 *см* : 6 *м* 85 *см*

958. 1) 35 мин. 58 секунд + 50 мин. 28 секунд
18 сәг. 34 мин. + 12 сәг. 26 мин.
20 сәг. 16 мин. — 6 сәг. 38 мин.
12 ел 6 ай — 5 ел 8 ай

2) 2 мин. 30 секунд × 28 — 61 сәг. 12 мин. : 54
5 сәг. 40 мин. × 60 — 19 мин. 12 секунд : 1 мин. 12 секунд
20 сәг. 18 мин. : 14 — 28 тәүл. 12 сәг. : 1 тәүл. 14 сәг.

959. 1) 1 865 *см* ничә метр һәм сантиметрны төзи? 3 050 *см*? 1 005 *см*? 10 020 *см*?

2) 15 758 *кг* ничә тонна һәм килограммны төзи? 26 074 *кг*?

3) 14 786 *кг* ны эрерәк үлчәүлекләргә әйләндерергә.

4) 6 *т* 8 *ц* да ничә килограмм? 15 *т* да? 12 *т* 8 *ц* да?

5) 7 *м* 6 *дм* ны сантиметрларга вакларга; 18 *км* 5 *м* ны метрларга вакларга.

960. 1) 2 *га* да ничә квадрат метр? 3 *га* 5 000 *кв. м* да?

2) 1 *а* да ничә квадрат метр? 5 *а* да? 8 *а* 75 *кв. м* да?

3) 1 *кв. м* 1 *кв. дм* дан ничә тапкыр зуррак? 1 *кв. м* 1 *кв. см* дан? 1 *кв. дм* 1 *кв. см* дан?

4) 1 *куб м* 1 *куб дм* дан ничә тапкыр зуррак? 1 *куб дм* 1 *куб см* дан? 1 *куб м* 1 *куб см* дан?

Телдән исәпләү өчен мәсьәләләр.

961. Халыкара ярышларда совет атучысы 381 очко алды (мөмкин булган 400 дән); аның нәтиҗәсе бөтендөнья рекордыннан 6 очкога артыграк. Бөтендөнья рекорды ничә очко булган?

962. Водолаз өч ел эчендә 800 сәг. су астында эшләгән: беренче елны 290 сәг., икенче елны 40 сәгать артыграк. Өченче елны водолаз ничә сәгать су астында булган?

963. Полярникларга илтү өчен самолётларга һәрберсе 720 *кг* авырлыкта килә торган 10 җылы йорт төягәннәр. Бу йортлар барысы бергә нинди авырлыкта булган?

964. Москва университеты бинасы өстенә урнаштырылган йолдыз 13 *т* авырлыкта килә. Аны 4 тигез кисәккә бүлеп, кисәкләп күтәргәннәр. Һәр кисәк нинди авырлыкта булган? (63 нче рәсем).



63 нче рәсем

965. Элек каймактан май эшләү 5 сәг. вакыт алган. Яңа машиналарда бу эш бары тик 25 мин. вакыт ала. Яңа машиналарда май эшләү өчен ничә тапкыр кимрәк вакыт кирәк?

966. Мәктәп укучылары җәй көне колхозга кошлар үстерергә булыштылар. Алар 200 баш үрдәк бәбкәсе, аннан 100 башка артыграк каз бәбкәләре, ә үрдәк бәбкәләренә караганда, 25 тапкыр артыграк чебиләр үстерделәр. Укучылар барысы күпме кош үстерделәр?

967. Бер мәктәпнең пионерлары җәй буена 4 000 йомран тоттылар. Әгәр бер йомран җәй буена 12 *кг* бөртек ашаса, пионерлар күпме ашлыкны саклап калганнар?

968. Бер малай сабы 2 *м* 50 *см*, ә җебе аннан ике тапкыр озынрак булган кармак белән балык тота. Бу малай кармакка кидерелгән җимне ярдан 6 *м* ераклыкка ыргыта аламы?

969. Яшь натуралистлар кедр, нарат һәм карагай агачы орлыклары чәчтеләр. 5 елдан соң кедр 25 *см* га, нарат 75 *см* га, ә карагай 225 *см* га үсте. Карагай, наратка караганда, ничә тапкыр тизрәк үскән? Кедрга караганда? Һәр агач елга уртача ничә сантиметрга үскән?

970. Балыкчылар колхозга 5 *га* мәйданлы буадан 200 *ц* балык тоттылар. Бу, гадәттәгегә караганда, 8 тапкыр артыграк. Бер гектар буадан гадәттә күпме балык тотылганын исәпләргә.

971. Йөзүче агым унаена 10 минутта 1 *км* 200 *м* йөзде. Әгәр минутка 90 *м* кимрәк йөзсә, ул шул араны агымга каршы күпме вакытта йөзәр?

972. Пароходка 250 *км* араны узарга кирәк иде. Беренче 3 сәгатьтә ул 75 *км* юл узды. Шундый ук тизлек белән барса, калган юлны ул ничә сәгатьтә узар?

973. 200 *г* конфет 3 сум 20 тиен тора. Бу конфетның килограммы күпме тора?

974. Балалар 400 данә борчак утырттылар. Һәр йөздән 2 се тишелмәде. Ничә орлык тишелеп чыккан?

975. Һавага күтәрелгәндә, һәр 500 *м* биеклеккә күтәрелгән саен температура 3 градуска төшә. Әгәр җир өстендә 18 градус җылылык булса, бу вакытта 3 *км* биеклектә нинди температура булуын көтәргә мөмкин?

976. 16 көрәк өчен 96 сум түләделәр. Шундый 32 көрәк өчен күпме түләргә кирәк? (Ике юл белән чишәргә.)

977. Бер укучы кыз 10 секундта үзенең пульсы 14 тапкыр тибүен санады. Пульс минутка ничә тапкыр тибә?

978. Бер сорт ике кисәк материя 500 сум тора. Бер кисәктә 27 *м*, икенчесендә 4 метрга кимрәк. Һәр кисәк күпме торган?

979. Ике кисәктә бер сорт 28 *м* сатин бар. Беренче кисәк 160 сум, икенчесе 40 сумга кимрәк тора. Һәр кисәктә ничә метр сатин бар?

980. Ике поезд иртән 11 сәгатьтә ике шәһәрдән бер-беренә каршы чыгалар һәм шул ук көнне 14 сәгатьтә очрашалар. Беренче поезд сәгатькә 45 *км*, икенчесе 50 *км* бара. Ике шәһәр арасындагы ераклыкны табарга. Ике юл белән чишәргә.

981. Магазинда обедка кадәр 6 капчык, обедтан соң 4 капчык шикәр саттылар. Көн буена барысы 1 *т* шикәр сатылган. Обедка кадәр һәм обедтан соң ничә килограмм шикәр сатканнар?

982. Ике йөзүче бер-беренә каршы йөзәләр. Берсе минутка 80 *м*, ә икенчесе 60 *м* йөзә. Башта болар арасындагы ераклык 1400 *м* булган. Алар ничә минуттан соң очрашырлар?

983. Түбәндәге биремнәр буенча кара-каршы хәрәкәткә ике шәһәр арасындагы ераклыкны табу соралган мәсьәлә төзергә: хәрәкәт вакыты ... сәг., бер автомобильнең сәгатьлек тизлеге ... *км*, икенчесенеке ... *км*.

984. Аяк киемнәре тутырылган ящикларны ике йөк машинасында магазиннарга җибәрделәр: бер машинада 50 ящик, икенчесендә шундый ук 40 ящик булган. Беренче машинадагы барлык ящикларның авырлыгы, икенче машинадагыга караганда, 400 *кг* га артыграк. Ике машинадагы ящиклар күпме авырлыкта булган?

985. Бер мәктәп өчен 5 глобус, икенче мәктәп өчен шундый ук 2 глобус сатып алганнар. Беренче мәктәп, икенчесенә караганда, 120 сум артыграк түләгән. Һәр мәктәп глобус өчен күпме түләгән?

986. Мәктәп беренче тапкыр 15, икенче тапкыр 8 тырма сатып алган, икенче тапкыр ул 42 сумга кимрәк түләгән. Барлык тырмалар күпме тора?

987. Әгәр мәктәп буфеты өчен 4 *кг* печенье алсалар, 54 сум акча артып кала. Шул ук бәядән 6 *кг* печенье сатып алганнар һәм 30 сум акча артып калган. 1 *кг* печенье күпме торган?

988. Укучы, әгәр 5 дәфтәр сатып алса, 80 тиен акчасы кала, әгәр 8 дәфтәр алса, бары 38 тиен генә акчасы кала дип исәпләгән. Укучының күпме акчасы булган?

989. Депутатлар сайлаганда, бер сайлау участогында беренче сәгатьтә 250 сайлаучы, икенче сәгатьтә 203, өченче һәм дүртенче сәгатьләрдә 180 шәр сайлаучы һәм бишенче сәгатьтә калган 137 сайлаучы тавыш биргән. Бер сәгатьтә уртача ничә сайлаучы тавыш биргән?

990. Бер участокта бер ардан 18 *кг*, икенчесендә 22 *кг*, өченчесендә 19 *кг* һәм дүртенчесендә 21 *кг* уңыш алган булсалар, 1 *а* дан алынган уртача уңышны табарга.

991. Кассир йомшак һәм каты вагоннарга 150 билет саткан. Тагы 10 билет саткач, каты вагоннарга, йомшакларга караганда, 4 тапкыр артыграк билет сатылганы билгеле булган. Каты һәм йомшак вагоннарга аерым-аерым ничәшәр билет сатылган?

992. Эретмәдә 5 өлеш бакырга 3 өлеш кургаш туры килә. Әгәр кургаш 120 *кг* алынган булса, барлык эретмәнең авырлыгы нинди булыр?

993. Эретмәдә 5 өлеш бакырга 2 өлеш аккургаш туры килә. Әгәр эретмәдә бакыр, аккургашка караганда, 45 *кг* га артыграк булса, эретмәнең авырлыгын табарга.

994. Мәктәптә барысы 210 пионер һәм комсомолецлар бар, шуның белән бергә комсомолецлар, пионерларга караганда, 2 тапкыр кимрәк. Мәктәптә ничә пионер һәм ничә комсомолец бар?



64 нче рәсем.

995. 64 нче рәсем буенча ике велосипедистның кара-каршы хәрәкәтенә мәсьәлә төзергә һәм чишәргә.

996. Комбайнер 3 көндә 80 *га* мәйданның ашлыгын урып җыйды. Беренче көнне ул бу мәйданның $\frac{1}{5}$ ен, икенче көнне $\frac{1}{4}$ ен урып җыйды. Өченче көнне ничә гектарның ашлыгы урып җыелган?

997. Мәктәп янында турыпочмаклык формасында җимеш бакчасы һәм яшелчә бакчасы бар. Җимеш бакчасының буе 50 *м*, иңе 30 *м*. Яшелчә бакчасы ың мәйданы җимеш бакчасы мәйданыннан 600 *кв. м* га зуррак. Яшелчә бакчасының мәйданы күпмегә тигез?

998. Буе 40 *см*, иңе 30 *см* лы картонга балалар 8 данә кипкән яфрак беркеттеләр. Һәр яфракка уртача ничә квадрат сантиметр картон киткән?

999. Мәйданы 1000 *кв. м* лы тәҗрибә участогыннан 36 *ц* бәрәңге алдылар. Уңыш шулай булганда 1 *га* дан күпме бәрәңге алырлар?

1000. Спорт мәктәбендә, йөзү өчен, буе 20 *м*, иңе 10 *м* лы бассейн төзеделәр. Бассейндагы суның тирәнлеге 2 *м*. Бассейнда ничә куб метр су бар?

1001. Кабыргасы 12 *см* лы кубның күләмен исәпләргә; 8 *м* лы кубның.

1002. Түбәндәге бирелмәләр буенча әйберләрнең күләмнәрен исәпләргә:

Буй	Иң	Биеклек
3 *м*	6 *м*	3 *м*
3 *дм*	1 *дм* 5 *см*	1 *дм*
4 *дм*	2 *дм* 5 *см*	1 *дм*

1003. Өч ящикта 100 *кг* конфет бар. Беренче һәм икенче ящикларда бергә 55 *кг*, икенче һәм өченче ящикларда бергә 75 *кг*. Һәр ящикта ничә килограмм конфет бар?

1004. Әгәр сыерга көн саен 10 *кг* печән бирсәң, хәзерләнгән печән 120 көнгә җитә. Әгәр көнгә 2 *кг* артыграк бирсәң, бу печән ничә көнгә җитәр?

1005. 600 *км* га тигез булган ике шәһәр арасын поезд 11 сәгатьтә үтте. Барлык юлның яртысын ул сәгатькә 50 *км*. тизлек белән барды. Калган юлны ул нинди тизлек белән барган?

1006. Яшь натуралистлар тәҗрибә участогыннан 1 000 данә кукуруза чәкәне җыеп алдылар. Аларның $\frac{9}{10}$ ын орлыкка сайлап куйдылар, болар арасында дымлы чәкәннәр, корыларга караганда, 2 тапкыр артыграк. Дымлы чәкәннәрне киптерү өчен, һәрберсен, 20 шәр данә итеп, бәйләмнәргә бәйләделәр. Ничә бәйләм чыкты?

1007. Ике корзинкада 120 алма булган. Бер корзинкадан 28 алманы алгач, һәр ике корзинкада алмалар саны бертигез булып калган. Башта һәр корзинкада ничәшәр алма булган?

1008. Ике капчыкта 108 *кг* бәрәңге бар иде. Бер капчыктан 23 *кг*, ә икенче капчыктан 19 *кг* тоткач, һәр ике капчыкта бертигез бәрәңге калган. Башта һәр капчыкта ничәшәр килограмм бәрәңге булган?

1009. Өч класста 120 укучы булган. Беренче класска яңадан 3 укучы, икенче класска 2 һәм өченче класска бер укучы алгач, барлык классларда укучылар саны бертигез булган. Башта һәр класста ничәшәр укучы булган?

1010. Бер эшче сәгатькә 8 деталь, икенчесе 7 деталь эшли. Бер үк вакыт эшләп, күпме вакытта ике эшче бергә 150 деталь эшләрләр?

1011. Ике ящикта 130 апельсин бар иде. Аларның берсенә тагы 30 апельсин өстәгәч, анда, икенчесенә караганда, 3 тапкыр артыграк апельсин булды. Башта һәр ящикта ничәшәр апельсин булган?

1012. Дәфтәрләрдә кызыклы квадратлар сызыгыз (65 нче рәсем) һәм аларның буш шакмакларын тутырыгыз.

	300	
360		480

Сумма 900

240	440	
	280	

Сумма 840

125		
200		175

Сумма 450

65 нче рәсем.

Язып чишү өчен мәсьәләләр.

1013. Бөтен җир шарында авыл хуҗалыгы өчен яраклы 10 600 000 000 *га* чамасы җир бар. Хәзерге вакытта бу җирләрнең бары 1 000 000 000 гектары гына үзләштерелгән. Әгәр үзләштерелмәгән җирләрнең $\frac{3}{4}$ енә бөртекле культуралар чәчелсә һәм 1 *га* дан уртача 15 *ц* уңыш алынса, өстәмә рәвештә күпме ашлык җыеп алып булыр иде?

1014. СССРда 1956 елга 30 000 000 га чирәм җирләрне үзләштерү билгеләнгән. Бу мәйданның $\frac{3}{4}$ енә бөртекле культу-

ралар чәчеләчәк. Әгәр 1 *га* дан уртача 15 *ц* уңыш алынса һәм бер кешегә елга 200 *кг* икмәк китсә, бу мәйданнан җыелган икмәк ничә кешегә җитәр?

1015. Турыпочмаклы басуның буе 875 *м*, ә иңе 640 *м*. Бу басуның $\frac{7}{8}$ сенә гектарга 1 *ц* 50 *кг* нан бодай чәчкәннәр. Чәчү өчен күпме бодай кирәк булган?

1016. Комбайн сәгатькә 9 *км* тизлек белән хәрәкәт итә. Комбайнның алым киңлеге 4 *м*. Көнгә 10 сәгать эшләгәндә, шундый комбайн 5 көндә ничә гектар мәйданның ашлыгын урып җыяр?

1017. Турыпочмаклы басуның буе 1 *км* 500 *м*, иңе 1 *км* 200 *м*. Бу басуның өчтән берен колхоз көнгә 30 ар гектардан, ә калганын көнгә 40 ар гектардан сөргән. Барлык басуны колхоз ничә көндә сөргән?

1018. Турыпочмаклы басуның буе 1 500 *м*, иңе 600 *м*. Бер трактор бу басуны 15 көндә, икенчесе 10 көндә сөрә ала. Бу ике трактор, бергә эшләп, 8 көндә ничә гектар җир сөрә алырлар?

1019. 720 деталь хәзерләргә кирәк. Бер эшче үзе генә барлык детальне 10 сәгатьтә, икенчесе 12 сәгатьтә, өченчесе 15 сәгатьтә хәзерли ала. Бер үк вакытта эшләсәләр, бу 3 эшче барлык детальләрне ничә сәгатьтә хәзерләрләр?

1020. Әгәр 20 миллион укучының һәрберсе берәр генә төп фрукт агачы утыртсалар һәм үстерсәләр, укучылар үстергән бакчалар нинди мәйданны капларлар иде?

Белешмә. Бер агач өчен буе 8 *м*, иңе 6 *м* лы участок кирәк.

1021. Беренче участок 340 *га*, икенчесе беренчесенең $\frac{2}{5}$ се кадәр, ә өченче участок беренче һәм икенче участокның икесенең $\frac{3}{4}$ е кадәр мәйданны алып тора. Өч участокның барлык мәйданын табарга.

1022. Печән кибәненең күләме 600 *куб м*. 1 *куб м* печән 52 *кг* килә. Әгәр һәр сыерга көнгә 10 *кг* бирсәләр, бу печән 156 сыерга ничә көнгә җитәр?

1023. Бәрәңге саклагычның буе 20 *м*, иңе 10 *м*, биеклеге 5 *м*. Әгәр 1 *куб м* бәрәңге 675 *кг* килсә, шундый саклагычка ничә тонна бәрәңге сыяр?

1024. Автомобиль беренче көнне 480 *км*, икенче көнне 510 *км*, өченче көнне 420 *км* юл узды. Бу йөрүгә ул 176 *кг* 250 *г* бензин бетерде. Һәр көнне күпме бензин тотылган? Чишелешнең дөреслеген тикшерергә.

1025. Уңышлары бер үк төрле өч участоктан 5 170 *ц* арыш җыеп алдылар. Бер участокның мәйданы 72 *га*, икенчесенеке 68 *га*, өченчесенеке 80 *га* булса, һәр участоктан күпме арыш җыеп алганнар?

1026. Кош фабрикасында инкубаторлар һәр рәттә 6 шар булып ике рәткә тезелеп торалар. Чеби чыгару өчен һәр инкубаторга 42 000 йомырка куйдылар. Һәр 100 йомыркадан уртача 86 чеби чыга. Инкубаторларга салынган йомыркалардан ничә чеби чыгуын көтәргә мөмкин?

1027. Элек бер вагонга һәрберсе 80 шәр килограмм авырлыктагы 140 кип мамык тукыма төйиләр иде. Хәзер яңача төяп, бер вагонга шундый 220 кип тукыма сыйдыралар. Фабрикадан 9 856 *т* тукыма җибәрәсе бар. Яңача төягәндә ничә вагон кимрәк кирәк булачак?

1028. 1955 елда колхоз 670 *га* мәйданга мамык чәчте һәм һәр гектардан 32 *ц* 60 *кг* уңыш җыеп алды. 1960 елга колхоз мамык чәчү мәйданын 550 *га* га, ә бер гектардан алына торган уңышны 18 *ц* га арттырырга карар бирде. 1960 елда, 1955 елдагыга караганда, күпмегә артыграк мамык алырга уйлана?

1029. Совхозда гектарга 21 әр центнердан 22 512 *ц* бөртекле ашлык җыеп алдылар. Икенче елны совхозның чәчү мәйданы элекке мәйданның дүрттән бере кадәр, ә бер гектардан алынган уңыш 3 *ц* га артты. Икенче елны совхоз күпмегә артыграк ашлык җыеп алган?

1030. Бер тонна яңгыр суы тулысынча кипкәндә 50 *г*, ә бер тонна диңгез суы 35 *кг* тоз бирә. Әгәр 200 *кг* диңгез суыннан алган кадәр тоз алырга теләсәләр, ничә тонна яңгыр суын киптерергә кирәк булыр иде?

1031. Совхозда 46 000 сарыкның һәрберсеннән 4 *кг* 800 *г* йон алдылар. 100 *г* йоннан 36 *г* саф сүс чыга. Әгәр 1 костюмга 3 *м* йон материя китсә, бу йоннан ничә костюм тегеп булыр?

Белешмә. 1 *м* материягә 300 *г* саф сүс китә.

1032. Бер пристаньнан сәгатькә 25 *км* тизлек белән баручы пароход кузгалып китә. 2 сәгатьтән соң икенче пристаньнан

аңа каршы икенче пароход чыга. 10 сәгатьтән соң пароходлар очрашалар. Әгәр бу пристаньнар арасы 500 *км* булса, икенче пароход нинди тизлек белән барган?

1033. Москвадан Киевка кадәр 860 *км*. Иртән 10 сәгатьтә Киевтан Москвага таба сәгатькә 40 *км* тизлек белән баручы поезд чыга. Киев поезды чыгудан 8 сәгать вакыт узгач, аңа каршы Москвадан сәгатькә 50 *км* тизлек белән баручы поезд чыга. Бу поездлар сәгать ничәдә һәм Москвадан нинди ераклыкта очрашырлар?

1034. Москвадан Бакуга кадәр 2 542 *км*. Бу шәһәрләрдән бер үк вакытта бер-беренә каршы ике поезд чыга. 12 сәгатьтән соң поездлар бер-береннән 1 462 *км* ераклыкта булдылар. Әгәр Баку поездының тизлеге сәгатькә 47 *км* булса, Москвадан килүче поезд нинди тизлек белән хәрәкәт иткән?

1035. Ике гавань арасы 1 530 *км*. Бу гаваньнардан бер үк вакытта бер-беренә каршы ике корабль чыга. Бер корабль сәгатькә 24 *км*, икенчесе аның $\frac{7}{8}$ се кадәр араны уза. Очрашканга кадәр аларның һәрберсе ничә километр юл узган?

1036. Казаннан Москвага кадәр 796 *км*. Иртән 3 сәгатьтә Казаннан Москвага таба, сәгатькә 36 *км* тизлек белән баручы почта поезды чыга; 13 сәгатьтән соң Москвадан аңа каршы сәгатькә 46 *км* тизлек белән баручы поезд чыга. Бу поездлар сәгать ничәдә һәм Казаннан нинди ераклыкта очрашырлар? Чишелешнең сызымын ясарга.

1037. Эшчеләр бригадасы, экскаваторда эшләп, һәр куб метр грунтны казып чыгару хакын киметергә карар бирде. Бригада үзенең карарын түбәндәгечә үтәде: ул хезмәт житештерүчәнлеген күтәрү нәтиҗәсендә 11 тиен, материалны саклык белән тотудан 15 тиен, инструментларны саклык белән тотудан 2 тиен, ремонттан 3 тиен һәм майлау материалын саклык белән тотудан 1 тиен экономия ясады. Ярты елда бригада 365 125 *куб м* грунт казыды. Бу бригаданың ничә мең сум экономия бирүен исәпләгез.

1038. „Тиен сумны саклый“ икәнен күрсәткән мәсьәлә уйлап табыгыз.

1039. Автомобиль башта 160 *км*, аннан соң бу араның яртысы, соңыннан бу араның чиреге кадәр ераклыкны узды. Узган юл, барасы юлга караганда, 3 тапкыр кимрәк булды. Автомобильнең уртача тизлеге 30 минутка 20 *км*; тукталыш

ларда ул 4 сәг. торган. Автомобиль барлык юлны ничә сәгатьтә узган?

1040. Машиналарда һәм олауларда сарайга 180 *т* печән китерделәр, барлык печәннең өчтән бере олауларда китерелде. Һәр олауга 300 *кг*, ә һәр машинага аннан 5 тапкыр артыграк төяделәр. Һәр олау 5, ә һәр машина 10 рейс ясады. Ничә олау һәм ничә машина булган?

1041. Кирпеч заводыннан төзелешкә 266 400 кирпеч китерделәр. Беренче 4 сәгатьтә кирпечне һәр машинага 1 200 данә төяп һәм һәр баруга 1 сәг. вакыт уздырып, 18 машинада ташыдылар. Соңыннан тагы шундый 7 машина өстәделәр. Барлык кирпечне ничә сәгатьтә ташып бетерделәр?

1042. Буе 2 *км*, ине 400 *м* лы басудан шикәр чөгендере уңышы җыеп алдылар. Барлык мәйданның $\frac{3}{10}$ еннән гектарга 480 *ц*, ә басуның калган өлешеннән гектарга 390 *ц* уңыш алдылар. Шикәр заводында эшкәрткәндә чөгендернең алтыдан бере кадәр шикәр чыкты. Бу чөгендердән күпме шикәр алганнар?

1043. Ленинградта М. Е. Салтыков-Щедрин исемендәге китапханәдә почта маркасы зурлыгында бик кечкенә бер китап (Крылов баснялары) бар. Бу китапның буе 22 *мм*, иңе 13 *мм*. Бу китапның тышлыгын сызыгыз.

Бу китап битенең мәйданы сезнең арифметика китабы битенең мәйданыннан ничә тапкыр кечкенәрәк?

1044. Бер кисәк сукно 3 360 сум, икенче кисәк аннан 840 сумга кыйбатрак тора. Икенче кисәктә, беренчегә караганда, 15 *м* артыграк. Барлык сукноны ике мастерскойга шулай итеп бүлделәр: беренче мастерскойга барлык сукноның өчтән бере, икенчесенә калганы тиде. Әгәр 10 *м* сукнодан 4 пальто чыкса, икенче мастерской ничә пальто теккән?

1045. Ике баржада 12 000 карбыз китерделәр. Беренче баржадан 3 560, икенче баржадан 2 500 карбызны бушаткач, беренче баржада, икенчедәгегә караганда, 3 тапкыр кимрәк карбыз калды. Һәр баржада ничә карбыз китергәннәр?

1046. Магазин ике кисәк бертөрле материя сатты. Бер кисәге 1 500 сум, икенче кисәге 420 сумга артыграк тора. Беренче көнне 1 236 сумлык, икенче көнне 1 128 сумлык, ә өченче көнне калган 88 *м* материяне саттылар. Беренче ике көндә ничә метр материя сатканнар?

1047. Колхоз бакчасы квадрат формасында; аның барлык яклары бергә 720 *м*. Бакча мәйданының $\frac{3}{4}$ ен алмагачлар алып тора; һәр алмагачка 36 *кв. м* җир туры килә. Мәйданның $\frac{1}{5}$ ен чия алып тора; һәр чия агачына 12 *кв. м* җир туры килә. Бакчада алмагачлар, чиягә караганда, ничә төпкә артыграк?

1048. Бер яшелчә бакчасы квадрат формасында, аның бер ягы 100 *м* га тигез. Икенче бакча турыпочмаклык формасында, аның буе 250 *м*, иңе 40 *м*. Һәр бакчаны киртә белән әйләндереп алганнар. Кайсы бакчаның киртәсе озынрак һәм күпмегә озын? Ике бакчаның мәйданнарын чагыштырырга.

1049. Китапханә өчен 2 880 китап төплисе бар. Эш өч мастерскойга тапшырылган. Аларның берсе үзе генә барлык китапларны 60 көндә, икенчесе 90 көндә, өченчесе 180 көндә төпли ала. Өч мастерской бергә эшләп, барлык китапларны ничә көндә төпли алырлар?

4 320 китап төплисе бар дип исәпләп, мәсьәләне яңадан эшләргә.

1050. Тегү мастерское өчен 90 *м* йон материя һәм берничә метр ефәк материя сатып алдылар. Барлык материя 30 000 сум тора, шуның белән бергә йон материя, барлык ефәккә караганда, 3 тапкыр артыграк тора. Әгәр 1 *м* йон материя, 1 *м* ефәк материягә караганда, 100 сумга кыйбатрак торса, ничә метр ефәк материя сатып алынган?

1051. Колхозда барлык җирнең яртысы чәчүлек җир, калган мәйданны болын, урман һәм яшелчә бакчасы алып тора. Яшелчә бакчасының мәйданы 50 *га*, ул болын мәйданыннан 16 тапкыр кимрәк, ә болын мәйданы урман мәйданыннан 4 тапкыр артыграк. Колхоздагы барлык җирнең мәйданын табарга

1052. Ике шәһәр арасындагы ераклык 2 800 *км*. Беренче көнне поезд барлык юлның $\frac{1}{4}$ ен, икенче көнне, беренчегә караганда, барлык юлның $\frac{1}{10}$ е кадәр артыграк, ә калган юлны ул өченче һәм дүртенче көннәрдә бертигез үтте. Поезд һәр көнне ничә километр узган?

1053. Бер тукучы 8 сәгатьтә 2 096 *м*, икенчесе шул ук вакытта 1 712 *м* тукыма эшләп чыгара. Ике тукучы ничә

сәгатьтә 121 856 *м* тукыма эшләп чыгарырлар? Ике юл белән чишәргә.

1054. Типографиядә бер наборщик 7 сәгатьтә 13 720 тамга, әгикенчесе 8 сәгатьтә 15 760 тамга жыя. 196 500 тамганы жыю өчен бу ике наборщик ничә сәгать эшләргә тиешләр?

1055. Аралары 1 200 *км* булган ике шәһәрдән бер үк вакытта бер-беренә каршы ике поезд чыга. Аларның берсе бу араны 20 сәгатьтә, ә икенчесе 30 сәгатьтә уза. Бу поездлар ничә сәгатьтән соң очрашырлар?

1056. Фарфор хәзерләү өчен 25 өлеш балчык, 2 өлеш ком һәм 1 өлеш гипс алалар. 5 880 *кг* фарфор хәзерләү өчен күпме балчык, күпме ком һәм гипс алырга кирәк?

1057. Бетон хәзерләү өчен 1 өлеш цемент, 2 өлеш ком һәм 4 өлеш вак таш алалар. 6 244 *т* бетон хәзерләү өчен күпме цемент, күпме ком һәм вак таш кирәк булыр?

1058. Складка 1 704 *т* яшелчә китерделәр. Кишер һәм суган бертигез, ә чөгендер, кишергә караганда, 4 тапкыр артыграк. Складка ничә тонна кишер, ничә тонна суган һәм чөгендер китергәннәр?

1059. Пионерлар звеносы имән һәм өрәңге орлыклары жыйдылар. Имән орлыгын 10 *кг* 500 *г* жыйдылар. Бу, өрәңге орлыгына караганда, 7 300 *г* га артыграк. Барлык имән орлыгының $\frac{2}{5}$ сен һәм өрәңге орлыгының $\frac{3}{10}$ ен пионерлар колхозга, ә калганын лесничествога тапшырдылар. Пионерлар лесничествога күпме орлык тапшырганнар?

1060. Өч ящикның һәрберсендә бертигез санда апельсиннар бар. Өч ящикка тагы 117 апельсин өстәгәч, беренче ящикта 120, икенче ящикта 136 һәм өченче ящикта 140 данә апельсин булган. Һәр ящикка ничә апельсин өстәгәннәр? Чишелешнең дөреслеген тикшерергә.

1061. Бердәй өч мичкәгә су тутырганнар. Алардан барысы 28 чиләк су алгач, беренче мичкәдә 32 чиләк, икенчесендә 29 чиләк, өченчедә 31 чиләк су калган. Һәр мичкәдән ничә чиләк су алганнар?

1062. Колхоз элеваторга бодай жибәргән. Беренче көнне һәрберсенә 2 *т* 5 *ц* төяп, 16 машина белән, икенче көнне, беренче көндә илткәннең $\frac{3}{4}$ е кадәр, өченче көнне, беренче һәм икенче көндә илткәннең $\frac{1}{4}$ е кадәр бодай илткәннәр. Шун-

нан соң, илткәнгә караганда, өч тапкыр артыграк ашлык җибәрәсе калган. Колхоз элеваторга барысы күпме бодай җибәргә тиеш булган?

1063. Пионерлар лагеренда 3 бүлмә 165 *кв. м* мәйданны алып тора. Бер бүлмәгә 18, икенче бүлмәгә 16, өченче бүлмәгә 21 пионер урнаштырдылар. Әгәр һәр пионерга уртача бердәй квадрат метр мәйдан туры килсә, һәр бүлмәнең мәйданын исәпләргә.

1064. Ике пекарня бер үк авырлыктагы капчыкларда 60 *т* он алды. Беренче пекарня 14 *т*, ә икенчесе 20 *т* он тоткач, беренче пекарняда 125 капчык, икенчесендә 200 капчык он калды. Беренче пекарня ничә тонна он алган?

1065. Өч завод өчен 2 140 *т* күмер төяп җибәрделәр. Бер заводка 32 вагон, икенчесенә 35 вагон, ә өченчесенә 40 вагон. Һәр заводка ничә тонна күмер җибәрделәр?

1066. Севастопольдәге бер мәктәп укучылары үзләренең Якутскидагы дусларына, 96 сум 50 тиен расход тотып, фрукт посылкасы җибәрделәр. Посылкага килограммы 3 сум 40 тиенлек 9 *кг* алма һәм һәрберсе 2 сумлык берничә данә лимон керде. Ящик ясау өчен киткән материалга алар алма хакының алтыдан бере кадәр, ә посылканы җибәрү өчен ящик бәясеннән 8 тапкыр артыграк түләделәр. Посылкага ничә данә лимон кергән?

1067. Пароход пристаньнан 5 сәг. 15 минутта кузгалып китте һәм икенче пристаньга 16 сәгатьтә килеп җитте. Икенче пристань беренчедән 176 *км* ераклыкта. Юлда пароход 25 әр минутлы 3 тукталыш һәм 45 әр минутлы 2 тукталыш ясый. Пароход нинди тизлек белән барган?

1068. Ике ящикта 1 280 мандарин булган. Аларның берсенә тагы 250 данә мандарин салгач, анда, икенчесенә караганда, 2 тапкыр артыграк мандарин булган. Башта һәр ящикта ничә мандарин булган? Чишелешнең дөреслеген тикшерергә.

66 нчы рәсем.

1069. Мәктәп участогы (66 нчы рәсем) планда 1 *см* да — 40 *м* масштабында күрсәтелгән. Участокка төрле куль-

туралар утыртылган. Һәр культура алып торган мәйданны табарга.

1070. Узган ел колхоз 10 000 *ц* бөртекле ашлык җыеп алды. Моның чиреген гектарга уртача 50 *ц* уңыш биргән кукуруза алып тора. Киләсе елга колхоз кукуруза чәчү мәйданын ике тапкыр, ә 1 *га* дан алыначак уңышны 4 *ц* га арттырырга карар итте. Киләсе елга кукурузаны, узган елга караганда, күпмегә артыграк җыярга уйланыла?

1071. Бәрәңге саклагычта һаваның температурасы күтәрелү белән (4° тан югары) бәрәңге үрә башлый һәм үз авырлыгының $\frac{1}{10}$ ен югалта. Әгәр температура 4° тан югары булса, буе 20 *м*, иңе 10 *м* һәм биеклеге 5 *м* лы саклагыч күләменең $\frac{3}{4}$ ен алып торган бәрәңге күпме авырлыгын җуярга мөмкин?

Белешмә. 1 *куб м* бәрәңге 675 *кг* килә.

1072. Завод 26 көн буена көн саен 200 автомобиль эшләп чыгара барды. Барлык автомобильләрнең $\frac{1}{4}$ ен Киевка, калганының $\frac{1}{2}$ ен Одессага, аннан калганнарын Ленинградка җибәрделәр. Лининградка җибәрелгән автомобильләр арасында йөк машиналары, җиңел машиналарга караганда, 5 тапкыр артыграк. Ленинградка ничә йөк автомобиле җибәрелгән?

1073. Бер сәяхәтче, чүлләрне тикшереп, 240 000 *км* юл йөргән. Җәяүләп ул 3 700 *км*, ат өстендә һәм дөяләргә утырып аннан ике тапкыр артыграк йөргән. Калган юлны ул автомобильдә һәм самолётта узган, шуның белән бергә самолётта, автомобильгә караганда, 4 тапкыр артыграк юл үткән. Сәяхәтче ничә километр автомобильдә йөргән һәм ничә километр самолётта очкан?

1074. Ике куакта 37 сыерчык утыра иде. 6 сыерчык беренче куактан икенчесенә күчкәч, ә икенче куактагы 9 сыерчык очып киткәч, беренче куакта, икенчегә караганда, өч тапкыр артыграк кош калды. Башта һәр куакта ничә сыерчык булган?

1075. Өч вагонда 90 пассажир бар. Әгәр беренче вагоннан икенче вагонга 12 кеше, ә икенче вагоннан өченчегә 9 кеше күчсә, ул вакытта пассажирлар саны һәр вагонда бертигез булып калыр иде. Башта һәр вагонда ничә пассажир булган?

1076. Колхозчы ике кыз 400 данә үренте утырттылар. Берсе минутка 3 данә, икенчесе 2 данә утыртты. Икенче кыз, беренчегә караганда, 25 мин. озаграк эшләде. Һәр кыз күпме вакыт эшләгән?

1077. Фигураны (67 нче рәсем) 5 кисәккә кисегез һәм алардан квадрат төзегез.



67 нче рәсем.

1078. Кәгазьдән квадрат дециметр кисеп алыгыз. Аннан ягы 8 *см* лы квадрат кисегез. Калган өлешен, яңа квадрат төзергә мөмкин булырлык итеп, кисәкләргә кискәләгез. Яңа квадратның ягын һәм мәйданын табыгыз.

1079. Илдус һәм Наилгә буе 48 *см* һәм иңе 44 *см* лы бер табак картоннан буе 16 *см*, иңе 12 *см* лы кисәкләр кисеп алырга кушканнар. Илдус 11 кисәк кисеп алган, ә Наил 9 кисәк кискән һәм тагы калдык килеп чыккан.

Сызым ясагыз һәм аның өстендә Илдусның һәм Наилнең картонны ничек кисүләрен күрсәтегез.

1080. Кушу жиңел эшләнерлек тәртиптә куша барып, 1 дән 19 га кадәрге (19 да керә) барлык так саннарның суммасын табарга.

1081. Түбәндәге мисалларны чишегез һәм аларны чишкәндә килеп чыккан нәтиҗәләрнең нәрсәсе белән кызыклы икәнен әйтегез.

$12 \times 9 + 3$	$9 \times 9 + 7$	$1 \times 8 + 1$
$123 \times 9 + 4$	$98 \times 9 + 6$	$12 \times 8 + 2$
$1\,234 \times 9 + 5$	$987 \times 9 + 5$	$123 \times 8 + 3$
$12\,345 \times 9 + 6$	$9\,876 \times 9 + 4$	$1\,234 \times 8 + 4$

Кайбер мисалларның җавапларын шунда ук яза алмассызмы?

1082. Түбәндәге мисалларда йолдызчык белән тамгаланган цифраларны табарга. Язуны дәфтәрләрдә эшләргә.

$$1)\ \begin{array}{r} 4*7* \\ +\ 76*3 \\ \hline 1*568 \end{array} \qquad 2)\ \begin{array}{r} 1*6*8 \\ -\ 5*4* \\ \hline 6896 \end{array} \qquad 3)\ \begin{array}{r} 63* \\ \times\ 7 \\ \hline 4*38 \end{array} \qquad 4)\ \begin{array}{r} 48* \\ \times\ *5 \\ \hline **35 \\ +\ **4* \\ \hline 2191* \end{array}$$

$$5)\ \begin{array}{r|l} 98* & 38 \\ \hline -\ 76 & *6 \\ \hline 22* & \\ -\ *** & \\ \hline 0 & \end{array} \qquad 6)\ \begin{array}{r|l} 4042 & 8* \\ \hline -\ 344 & 4* \\ \hline 602 & \\ -\ 602 & \\ \hline 0 & \end{array}$$

Мәсьәләләр-расчётлар.

1083. Яз житү белән тәҗрибә участогында бәрәңге утыртасы бар. Моның өчен күпме орлыклык бәрәңге кирәк булыр?

Расчёт өчен бирелмәләр.

Түтәлләр саны . . . .
Бер түтәлдәге рәтләр саны . . . .
Бер рәттә . . . данә урнаша.

1084. Жәй көне безнең мәктәптә ремонт уздырылачак. Әгәр стеналарны һәм түшәмне агартасы, идәнне буйыйсы булса, безнең классны ремонтлау купмегә төшәр?

Расчёт өчен бирелмәләр.

Класс бүлмәсенең буе ... *м*, ине ... *м*, биеклеге ... *м*.
1 *кв. м* стенаны агарту бәясе ....
1 *кв. м* идәнне буяу бәясе ....

1085. Мәктәп, бакчага утырту өчен, данәсе 6 сум 15 әр тиеннән 18 төп алмагач, 4 сум 80 шәр тиеннән 22 төп чия, 2 сум 8 әр тиеннән 16 төп крыжовник, 1 сум 10 ар тиеннән 26 төп карлыган һәм данәсе 20 шәр тиеннән 60 төп кара җиләге куагы сатып алды.

Сатып алынган әйберләргә түбәндәге үрнәк буенча счёт языгыз:

Тәртип №№	Фрукт агачлары исеме	Саны	Бәясе		Гомуми бәясе	
			сум	тиен	сум	тиен

1086. Уку елы бетү белән безнең класс ... (урынын күрсәтергә) экскурсия ясаячак.

Экскурсиягә бәйләнешле расходларны исәпләргә.

Расчёт өчен бирелмәләр.

Укучылар саны... .
Экскурсиянең дәвамлылыгы... .
Юл расходы... .
Туклану өчен көндәлек расход... .
Башка расходлар... .

1087. Уку елы бетү белән укучылар пионерлар лагерена баралар. Түбәндә бирелгән план-маршрут буенча мәктәптән пионерлар лагерена кадәрге ераклыкны исәпләргә.



68 нче рәсем

Әгәр сәгатькә 3 *км* тизлек белән барылса һәм юлда утыз минутлык ял ясалса, мәктәптән җәяүләп лагерьга бару өчен күпме вакыт кирәк?

Телдән исәпләү өчен таблица.

	I	II	III	IV	V	VI	VII	VIII	IX	X
А	60	130	290	400	420	580	700	710	870	940
Б	10	150	220	370	460	540	630	780	850	990
В	40	190	250	330	480	520	670	750	810	960
Г	70	110	260	350	500	600	650	740	890	930
Д	20	170	280	360	490	510	640	720	830	980
Е	50	120	230	310	430	570	690	770	880	950
Ж	100	160	210	390	450	550	610	790	840	1000
З	30	140	270	320	410	590	680	730	860	970
И	90	180	300	340	470	530	660	800	820	910
К	80	200	240	380	440	560	620	760	900	920

ҖАВАПЛАР.

III класста узганнарны кабатлау.

6. 4 334 *т*.
7. 9 173 *км*.
8. 40 092 *ц*.
15. 84 310 кеше; 64 536 кеше.
21. 3 930 *кг*.
22. 50 250 сум.
26. 320 000 сум.
27. 16 265 *кг*.
32. 200 урын.
39. 90 йөк машинасы һәм 25 җиңел машина.
40. 9 000 чүлмәк.
44. 780 *км*.
45. 1 276 китап.
61. 2) 176 *м*; 3) 210 *м*.
64. 1 590 *км*.
65. 12 сәгатьтә.
66. 3 000 бала.
67. 60 *кг*; 90 *кг*.
68. 425 сум; 340 сум.
69. 2 475 *км*; 2 200 *км*; 3025 *км*.
70. 12 костюм; 9 костюм.
71. 3 952 *кг*.
72. 21 мичкә; 15 мичкә.
73. 650 *км*.
74. 616 *км*.
75. 6 сәгатьтән соң.
76. 4 сәгатьтән соң.
77. Сәгатькә 14 *км*.
78. 70 *м*.
79. 7 машина.
80. 2 053 китап.
81. 4 көндә.

Күбурынлы саннар өстендә нумерация һәм дүрт гамәл

123. 2 538 000 000 кеше.
124. 24 014 990 сум.
130. 9 364 *ц*.
131. 4 047 *ц*.
132. 936 840 сум.
139. 1 400 *ц*; 600 *ц*; 400 *ц*.
140. Амур — 4 354 *км*; Обь — 4 016 *км*; Лена — 4 264 *км*.
151. 173 960 сумга.
152. Нарат такталар 1 832 гә.
157. 1 930 *ц*.
158. Икенче — 8 агачка.
166. 2 017 табак.
172. 14 424 *м*.
173. 375 *ц*; 455 *ц*.
174. Днепр — 2 285 *км*; Волга — 3 688 *км*.
179. 65 төп.
180. 81 *т*.
191. 128 укучы.
192. 18 225 кирпеч.
194. Сәгатькә 48 *км*.
195. Сәгатькә 42 *км*.
196. 22 *ц*.
197. 3 612 *л*.
198. 1) 80 адым; 60 *см*; 2) 123 *м*.
210. 216 000 гусеница.

211. 37 496 *кг.*
216. 644 160 *м.*
217. 24 800 *кг.*
223. 1) 425 *кг*; 2) 448 *кг.*
224. 1 600 *кг*; 2 000 *кг*; 2 800 *кг.*
228. 90 000 *т.*
229. 1) 8 160 *кг*; 2) 15 *кг.*
236. 82 тиен.
237. Икенче звенода 1 китапка.
239. 390 000 гә.
248. 500 урындык; 438 урындык.
249. 70 кровать; 95 кровать.
252. Икенче түтәлдә — 6 тапкыр.
254. 440 данә.
260. 300 капчык.
261. 2) 6 көнгә.
266. 118 трактор; 96 трактор.
267. 850 күлмәк; 625 күлмәк.
273. 4 040 күлмәк.
274. 45 сәгатьтә.
281. 1 239 *т.*
290. 386 хезмәт көне; 420 хезмәт көне.
291. 85 *га*; 65 *га.*
296. 13 200 автомобиль.
330. 1 715 агач.
331. Пароходның тизлеге — сәгатькә 25 *км*; реактив самолётның тизлеге сәгатькә 975 *км.*
332. 3 030 кош.
333. 2 202 сум.
334. 864 *т.*
335. 33 480 сум.
336. Сәгатькә 335 *км.*
337. 900 сарык.
339. 5 сум 25 тиен.
340. 3 көнгә.
341. 237 *т.*
342. 20 *м* га.
343. 24 капчык.
344. 15 бригада.
345. 2) 6 көндә
346. 12 сәгатьтә.
359. 420 хезмәт көне.
360. 648 *кг.*
362. 78 900 *т.*
363. Икенчесе — 15 490 *г* га.
364. 1 620 пальто.
365. 24 786 *кг.*

Исемле саннар.

382. 560 хезмәт көне.
383. 738 хезмәт көне.
388. 73 *км* 800 *м.*
389. 89 148 сум 42 тиен.
394. 60 *км.*
395. 20 *т* 50 *кг.*
398. 7 *км* 439 *м.*
399. 13 *км* 60 *м.*
400. Сәгатькә 45 *км.*
408. 340 *кг*; 337 *кг* 500 *г.*
410. 5 *км* 200 *м.*
411. 8 *кг* 900 *г* га.
416. 4 *кг* 400 *г*; 3 *кг* 500 *г*; 3 *кг* 100 *г.*
417. 3 *т* 80 *кг*; 2 *т* 500 *кг*; 3 *т* 90 *кг.*
418. Беренчедән — 1 *т* 590 *кг* га.
424. 84 *км.*
428. 12 сум 40 тиен.
430. Икенчедән — 400 *кг* га.
436. 20 *кг.*
437. 274 сум 20 тиен.
443. 3 024 000 сарык.
445. 45 *кг.*
451. Икмәк — 2 *т* 400 *кг*; фруктлар — 1 *т* 440 *кг.*
452. 28 *см* 8 *мм.*
453. 44 *м* 40 *см* га.
454. 664 тапкыр.
460. 97 *м* 50 *см.*
461. 88 *кг.*
471. 3 *кг* 825 *г.*
472. 1 108 *т* 800 *кг.*
473. 30 *кг.*
474. 1 сум 41 тиен.

478. 275 *м.*
479. 178 балага.
480. 4 *т.*
485. 12 күлмәк.
486. 20 пальто.
488. 800 тапкыр.
490. 100 *л.*
492. 2 100 *кг* яшелчә; 1 008 *кг* бодай.
495. 17 кисәк.
496. 3 тапкыр.
498. 12 костюм.
499. 15 тапкыр.
501. 161 640 000 *т.*
502. 30 *т*; 15 *т*; 2 400 000 сум.
503. 75 *м*; 25 костюм.
504. 901 сум 50 тиен.
505. 1) 3 *т* 600 *кг.*
506. 498 *м.*
507. 36 *т* 890 *кг.*
508. 283 сум 50 тиен.
509. 247 сум 95 тиен.
510. 5 *ц* 50 *кг.*
511. 3 360 *кг*; 3 040 *кг*; 2 800 *кг.*
512. Икенче совхозда — 285 *га.*
513. Сәгатькә 25 *км.*
515. 10 *м* 50 *см* га.
516. 3 300 кешегә.
517. 14 сүз.
518. 8 хат.
519. 116 *т* 2 *ц*; 98 *т* 1 *ц*; 99 *т* 2 *ц.*
520. 1) 100 *кг*; 140 *кг*; 2) 17 *м*; 19 *м.*
521. 35 250 сум.

Квадрат үлчәүлекләр.

546. 2 тапкыр.
548. 4 320 *кв. м.*
549. 14 *га* 1750 *кв. м.*
550. 18 *ц.*
554. 9 375 *кв. м.*
557. 7 400 *кв. м.*
558. 357 *кв. м.*
565. 96 *кг*; 3 *т* 200 *кг.*
566. 840 *кг.*
571. 24 *га*; 2 000 *м.*
572. 10 *т* 80 *кг.*
582. 120 *т.*
583. 765 *т.*
584. 1 170 *т.*
585. 2 500 плитка.
588. 292 *т* 5 *ц.*
589. 3 *кг* 840 *г.*
590. 9 кисәк.
602. 78 *г*; 39 *г.*
603. 50 *г.*
605. 500 *т.*
606. 1 400 *т.*
608. 150 юкә; 750 каен.
612. 4 *т*; 1 *т.*
614. 3 375 *кв. м*; 1 125 *кв. м.*
615. 640 *ц.*
616. 2 680 пар; 2 860 пар.

Кубик үлчәүлекләр.

632. 1) 6 *куб м.*
633. 45 *куб м.*
634. 10 *т* 800 *кг.*
645. 18 машина.
646. 2 *т* 800 *кг.*
647. 86 400 кирпеч; 28 *куб м* 800 *куб дм* эремә.
651. 8 тапкыр.
652. 30 тапкыр.
653. 16 000 пачка.
655. 10 080 *куб м*; 14 112 *т.*
656. 1 728 эшче.
661. 396 сум.
663. 1) 72 сум.
664. 90 000 кирпеч; 30 000 кирпеч.

Кабатлау.

669. 495 *км.*
670. 378 *км.*
671. Сәгатькә 310 *км.*
672. 37 *ц.*
673. 2 400 *га.*
674. 40 *т.*
675. 35 *кг* 100 *г*; 11 *кг* 700 *г.*
676. 1 251 путёвка; 608 путёвка.
678. 459 *т* 2 *ц.*
679. 2 көнгә.
680. Сәгатькә 288 *км.*
681. 8 тапкыр.
683. 96 тапкыр.
684. 57 500 вагон.

Вакыт үлчәүлекләре.

697. 144 сәг.
703. 18 *куб м.*
707. 12 сәг. 5 минутта.
712. 2 сәгать.
725. 2 сәг. 35 мин.; 3 сәг. 20 мин.; 3 сәг. 45 мин.
726. 14 сәг. 40 мин.
748. 3 сәг. 20 мин.
750. 55 минутка.
752. 17 сәг. 4 минутка.
761. 1 сәг. 15 мин.; 2 сәг. 30 минутка.
762. 3 мин. 30 секунд.
763. Сәгатькә 43 *км* 200 *м.*
774. 3 поезд.
776. 3 мин. 10 секунд.
782. 3 тапкыр.
788. Агым уңаена — 45 мин. Агымга каршы 1 сәг. 30 мин.
789. 22 сәг. 30 мин.; 7 сәг. 30 мин.
790. 1 сәг. 30 мин.
791. 9 *га.*
792. 300 сәгать.
813. 18 сәгать.
814. 20 сәгать.

Иң простой вакланмалар.

900. 21 *га* 6 000 *кв. м.*
901. 2 048 *куб м.*
903. 37 дәфтәр.
906. 138 *км.*
907. 252 чия агачы.
908. 152 *га.*
911. 288 төп слива агачы.
912. 1 225 *кв. м.*
913. 176 *кг.*
916. 7 *т* 440 *кг*; 13 *т* 888 *кг.*
917. 585 *га.*
918. 282 *км.*
921. 3 сум 25 тиен.
922. 90 йорт.
923. 96 йорт.
924. 1 140 *км.*

Кабатлау бүлеге.

1013. 10 800 000 000 *т.*
1014. 168 750 000 кеше.
1015. 73 *ц* 50 *кг.*
1016. 180 *га.*
1017. 5 көндә.
1018. 120 *га.*
1019. 4 сәгатьтә.
1021. 833 *га.*
1022. 20 көнгә.
1023. 2025 *т.*
1024. 60 *кг*; 63 *кг* 750 *г*; 52 *кг* 500 *г.*
1025. 169 *т* 2 *ц*; 159 *т* 8 *ц*; 188 *т.*
1026. 433 440 чеби.
1027. 320 вагонга.

1028. 3 989 *т*.
1029. 9 648 *ц*.
1030. 140 *т*.
1031. 88 320 костюм.
1032. Сәгатькә 20 *км*.
1033. 24 сәгатьтә; 300 *км*.
1034. Сәгатькә 43 *км*.
1035. 816 *км*; 714 *км*.
1036. 20 сәгатьтә; 612 *км*.
1037. 116 840 сум.
1039. 32 сәгатьтә.
1040. 40 олау; 8 машина.
1041. 10 сәгатьтә.
1042. 556 *т*.
1044. 36 пальто.
1045. 5 045 карбыз; 6 955 карбыз.
1046. 197 *м*.
1047. 135 агач.
1048. Икенче бакчаныкы 180 *м* га озынрак.
1049. 30 көндә.
1050. 50 *м*.
1051. 2 100 *га*.
1052. 700 *км*; 980 *км*; 560 *км*; 560 *км*.
1053. 256 сәгатьтә.
1054. 50 сәг.
1055. 12 сәгатьтән соң.
1056. 5 250 *кг*, 420 *кг*, 210 *кг*.
1057. 892 *т*, 1 784 *т*, 3 568 *т*.
1058. 284 *т*, 284 *т*, 1 136 *т*.
1059. 8 *кг* 540 *г*.
1060. 27 апельсин, 43 апельсин, 47 апельсин.
1061. 8 чиләк, 11 чиләк, 9 чиләк.
1062. 350 *т*.
1063. 54 *кв. м*; 48 *кв. м*; 63 *кв. м*.
1064. 24 *т*.
1065. 640 *т*; 700 *т*; 800 *т*.
1066. 10 лимон.
1067. Сәгатькә 22 *км*.
1068. 770 данә; 510 данә.
1070. 2 900 *ц*.
1071. 50 *т* 625 *кг*.
1072. 1 625 автомобиль.
1073. 45 780 *км*; 183 120 *км*.
1074. 27 сыерчык; 10 сыерчык.
1075. 42 пассажир; 27 пассажир; 21 пассажир.
1076. 1 сәг. 10 мин.; 1 сәг. 35 мин.

ЭЧТӘЛЕК

III классста узганнарны кабатлау 3
Күбурынлы саннар өстендә нумерация һәм дүрт гамәл . 13
Исемле саннар 59
Квадрат үлчәүлекләр 84
Кубик үлчәүлекләр 98
Кабатлау 106
Вакыт үлчәүлекләре 109
Телдән исәпләүләрнең аерым алымнары 125
Ин простой вакланмалар 128
Кабатлау бүлеге 144
Телдән исәпләү өчен таблица 166
Җаваплар 167

А. С. Пчёлко и Г. Б. Поляк

АРИФМЕТИКА

для 4 класса

(на татарском языке)

Тәрҗемәчесе *М. К. Рахматуллин*

Редакторы *А. З. Лотфуллина*

Техник редакторы *Р. С. Нәбиуллина*

Корректоры *Ә. Х. Хәлилова*

Наборга бирелде 23VIII-1955 ел. Басарга кул куелды 26|X-1955 ел. ПФ 04766.
Кәгазь форматы 60 × 92¹/₁₆. Учет-изд. 8,26 таб. Басма табак 10,75.
Табакта 49200 хәреф. Заказ № 0318. Тираж 36.000. Бәясе 1 сум 35 тиен.

ТАССР Культура Министрлыгының Татполиграф типографиясе.
Казан, Миславский ур., йорт № 9.

Бәясе 1 сум 35 тиен